Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 23 (1388) 17 июнь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



8

Татарстанда һәм аннан читтә психотерапевт буларак билгеле Рамил Гарифуллин чынлыкта мөгаллим дә, галим, режиссер, язучы да...

12

Удмуртиядәге Байсар авылы белән Татарстанның көнчыгыш чигендәге Байсар арасында тарих сәхифәләрендә бәйләнеш бармы?

14

Казан ханлыгының болгавыр чорында бик күп газаплар күргән, күп сынаулар узган Сөембикә-ханбикәне татар һичкайчан онытмый.

Сабан туен уйлап тапкан халык Көрәш дәртен җуймас һичкайчан!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры Гөлзада Руденко әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Россия Дәүләт премиясе лауреаты булды.

- Г.Кариев театры артисты Булат Гатауллин «Гөлчәчәк» татар халык әкиятенә нигезләнгән, спектакль итеп үстереп бетерү мөмкинлеге булган эскиз тәкъдим итте.

- М.Гафури исемендәге Башкорт драма театры Россия Герое Миңнегали Шәйморатовка багышланган. «Ат уйнатып алдан бара» документаль спектакле белән Башкортстан районнарына гастрольләргә чыга.

- Истанбулда узган Халыкара журналлар ярминкәсендә Татарстаннан 10 журнал тәкъдим ителде.

- Язучы, филология фәннәре кандидаты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Факил Сафин Бөтендөнья татар конгрессының Чаллы бүлеге җитәкчесе итеп сайланды.

- Казанның Мусин урамындагы «Болгар» мәчетен капиталь төзекләндерүгә 35 миллион сумнан артык акча тотылачак.

- Тубыл шәһәрендәге Себер-татар мәдәнияте үзәгендә шәҗәрәләр фестивале оештырылды.

- Башкортстанның Үрге Кыйгы мәктәп лицеенда Бөек Ватан сугышы ветераны, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры, шагыйрь-трибун Хәниф Кәрим улы Кәримов истәлегенә мемориаль такта куелды.

- Казан аэропортында илебездәге халыкларның милли бәйрәменә багышланган фотокүргәзмә ачылды.

- 23-31 июльдә Болгарда Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узачак.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Руслан АЙСИН, сәясәт белгече:

«Казанның тарихи урынында күңел ачу паркы булуы каршылык уятмый, шәһәр архитектурасын бозмый, ә матур мәчет, имеш, килешми. Үзләре «Кырлай» паркы янында зур йортлар салуга каршы чыкмадылар, ә мәчет аларга никтер комачаулый... Бездә чиркәүләр дә төзелә. Бер ел элек кенә шәһәрнең тарихи үзәгендә зур чиркәү - Казан соборы торгызылды. Ул чакта беркем каршы чыкмады».

СЫНАМЫШЛАР

18 июньдә җылы һәм аяз булса, бодай һәм арыш бөртекләре эре була ● 21 июньдә чык мул төшсә, киндер һәм җитен уңа ● Гадәттә, 22 июньдә каен җиләге өлгерә ● Кичтән томан төшсә, көн аяза һәм җылыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **2 сәгать 57 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 31 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 34 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **1 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **24 июньдә 17 сәгать 33 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

19-21 июнь – 30 ел элек I Бөтендөнья татар конгрессы булды (1992).

20 июнь – гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Вильсун Минниян улы Хәкимовка 75 яшь (1947);

– Бөтендөнья качаклар көне.

22 июнь – драматург, мөгаллим Фазыл Кәрим улы Туйкинның тууына 140 ел (1887–1938);

– шагыйрь Мәсгут Нәбиулла улы Галиуллинның тууына 120 ел (1907–1944).

23 июнь – Халыкара Олимпия көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(14-21 июнь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 18 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Римзил ВӘЛИЕВ,
журналист һәм җәмәгать эшлеклесе

ТЕЛГӘ теләк кирәк!

Татар конгрессының корылтай мөнбәренә

Заманалар тыныч түгел. Илләр арасындагы мөнәсәбәтләр, матди тормыш катлаулана. Әмма мондый чакта да туган телләр темасы көн кадагыннан төшми. Чөнки туган тел – туй көнендә киеп чыга торган матур күлмәк кенә түгел. Туган тел милләтнең йөзен, рухи тәҗрибәсен чагылдыра. Туган телләрнең саклануы милләтнең барлыгын, халыкларның бер-берсенә ихтирамын күрсәтә. Хәлбуки, кайбер кардәшләребезнең үз тамырыннан, рухыннан аерылып, чирканып йөрүе дә ачык. Әгәр нәселең, милләтең, телең чүплеккә ташлана икән, нишләп үзең башкаларның аягы астында һаман буталасың?

Милләт һәм тел өстенлеген таләп итү – бик яман чир. Милли радикалларның хакимияте сугышлар тудыра. Башка милләтләр, телләр инкарь ителгән очраклар гадәттән тыш вакыйга, фаҗига буларак тарихка керә. Үз милләтен башкалардан өстен куйган Адольф Гитлер талантлы Моцарт-Бетховеннарны, Гете, Маркс-Энгельсларны биргән немец халкын хурлыкка батырды, соңыннан үкенеп, тәүбә кылып яшәргә мәҗбүр итте.

Иң яхшысы – һәркемнең үз телен, мәдәниятен саклау мөмкинлеге. Үзең булып калуга, яшьләрне тәрбияләү өчен шартлар булдыруга, халыкара хокук нормалары, федератив дәүләт кануннары нигезендә яшәүгә ни җитә! Милләттәшләрең үзләре туган телне, рухи байлыкларны кадерләсә, әлбәттә...

Менә шундый фикерләрне татар конгрессы порталына яздык. Мәгълүмати сәбәп – Татарстан Президентының татар телен саклау буенча комиссиясе утырышында 2021 елда башкарылган эшләргә йомгак ясау. Комиссия рәисе, Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов чыгышында, комиссия әгъзалары ясаган нотыкларда татар телен яшәтү өчен дәүләт оешмалары башкарган эшләр күзалланды. Узган гасырның 80-90 нчы елларында мондый эшләр кыю хыял булып күренер иде. Иярченле телевидение, берничә радиоканал, дәүләт ярдәмендә эшләүче мәгълүмат системасы, өч-дүрт телне тигез укыта торган полилингваль мәктәпләр, халыкара олимпиадалар, зур призлы конкурслар! Рәсми оешмаларда, интернет сәхифәләрендә татар телен куллану. Элмә такталардагы татарча язмаларның хаталарын төзәтү...

Узган ел йомгаклары турында саллы гына мәкаләләрдә әйтелде. Intertat.tatar порталында «Боз кузгалды», яки Марат Әхмәтов комиссиясе утырышында министрлар ничек сөенделәр?» дигән язма чыкты. Бөтендөнья татар конгрессының интернет порталында шул темага багышланган мәкалә дөнья күрде. Анда комиссия җитәкчесе, өч министр, «Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе, Казан шәһәре хакимияте вәкиле ясаган тирән эчтәлекле докладлар бирелгән иде.

Сүзебез М.Әхмәтов җитәкләгән комиссиягә бәя бирү түгел. Хикмәт хакимият белән халыкның бу эшкә бергәләшеп тотынуында. Барып чыгамы бу эшләр? Татарстан Президенты Р.Миңнеханов меңнән артык мәктәп, югары уку йортлары, Фәннәр академиясе, мәдәният һәм мәгълүмат системасы булган республикабызда дәүләт оешмаларының татар теленә мөнәсәбәтен тикшереп, эшләрне тагын да камилләштерә торган комиссия төзегән. Анда барлык җаваплы затлар да бер урынга тупланган. Нәтиҗәләр күренәме, алга китеш бармы?

Сөйләшүне дәвам итү өчен, Бөтендөнья татар конгрессы интернет порталында чыккан мәкаләне искә төшерик. Аның бүлекләре менә ничек аталган: «Татар теле кайгысы юк!» димиләр», «Татарстан Президенты комиссиясе ниләр белән шөгыльләнә?», «Татар телен саклау дәүләтнең һәм зыялыларның уртак гаме», «Узган ел йомгаклары: үзгәрешләр бар», «Мәгариф һәм мәдәният тармаклары зур проектлар, күп санлы чаралар белән хисап тота», «Укыгыз: министрлар, Казан хакимияте вәкиле татар теле турында хисап тота», «Дәүләт оешмалары чаралар күргәндә, татарлар кая карый?»

Менә шул рәвештәге «мәгълүмат бомбасы» туган тел өчен җан атучыларга сенсация булып күренгән дип уйласагыз, ялгышасыз! Татар җәмәгатьчелеге бу мәгълүматлар басылып чыккач та, җәйге кичтәге тыныч күл кебек хәлдә калды. Әлеге тема уңаеннан шатланучылар да, борчылучылар да юк. Гаҗәп хәл!..

Югыйсә, 30 елдан артык җиң сызганып милли аң үстерәбез, республиканы ныгытабыз, туган тел, мәдәният, милләт, гореф-гадәт терелтү юлыннан барабыз. Үзгәрешләр дә бар кебек. Әмма үзегез яшәгән шәһәрдә, районда, мәхәлләдә татарларның күпме өлеше туган телдә сөйләшүен, күпмесе татар тарихы белән кызыксынуын, радио тыңлавын, телевизор, интернет каравын беләсезме? Моны сезгә кемнәр генә әйтер икән? Андый статистиканы белүче юк диярлек.

> ***«Барыгыз да мулла булып, атка печән салуны комиссия рәисенә генә калдыра күрмәгез берүк... Татар укучылары, укытучыларының нинди телдә аралашуына, оешмаларның бизәлешендә миллилеккә игътибар итегез. Һәр районда 50-60ар мәгариф, мәдәният учреждениесе бар. Аларның телгә хезмәт итү буенча һәрберсенең нәтиҗәсе мөһим, шуңа күрә чыгарга, йөрергә, аралашырга кирәк».***
>
> **Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов комиссия әгъзаларына мөрәҗәгатеннән.**

Кайбер төбәкләрдә социологик тикшерүләр булгандыр, ләкин аерым өлкә, район, яшәү урыны турында өздереп әйтүче табылмый. Шәһәрдәге татар яшьләренең яртысыннан артыгы үзебезчә сөйләшми, укымый, язмый, диләр. Татарстан, Башкортстан кебек төбәкләрдән гайре якларда туган телне онытучылар тагын да күбрәк. Хәтта авылларда да татар балаларының күбрәк русча аралашуы, язышуы күзгә ташлана. Глобализация тегермәне менә шулай «он тартып» тора.

Дәлилләүче саннар кирәкме? Статистика бик таралмаса да, күрсәткечләр бар. Милли тел кулланууның мөһим индикаторлары – ул театр, концерт, интернет, милли ТВ карау, газета-журнал, китап уку, яздыру, сатып алу. Шуларга карап та районга, шәһәргә «диагноз» куеп була. Ләкин саннар эшнең алга бармавын күрсәтә. «Татмедиа» оешмасы газета-журнал таратырга, китап сәүдәсен тергезергә бик тырыша, тиражларны саклау өчен мөһим чаралар күрелә. Әмма китап кибетләре Казанның 2-3 урынында ачылса да, нәшрияттан чыккан басмалар китапханәләргә генә тарала. Милли матбугатны сатып алучы, язылучы сирәк. Ярый әле дәүләт һәм иганәчеләр ярдәм итә.

Мәктәптә тел өйрәнү, мәдәниятка яшьләрне җәлеп итү киеренке хәлдә. Хәзер туган телне белгән өлкән буынга алмашка үзләре дә сөйләшә белмәгән ата-аналар килә. Балаларга, оныкларга милли гыйлемне мәктәп кенә бирә ала, дип саналса да, милли мәгарифнең хәле авыр. Соңгы елларда туган тел укыту иләк аша үткәрелә. Әле ярый Татарстандагы 3 меңгә якын татар теле укытучысы зур кыенлыклар белән хәзерге тайгак кичүне чыгу өчен тырыша. Алар да олыгая. Фәннәрне туган телдә укыту бетеп бара.

Милли мәгарифне үстергән хәлдә дә, укучыларда, ата-аналарда теләк-тырышлыклар уяту җиңел түгел. Татар теле атнага 4-5 дәрес кертелсә, татар ата-аналары үзләре үк күтәрелеп чыгачак. «Болай да нагрузка зур! БДИ бирәсе бар. Нигә кирәк артык мәшәкать?» – диячәк алар. Аларның хәтсезе татарча белеп тә, эштә һәм өйдә туган телдә юньләп сөйләшми. Балалар, әгәр «полилингваль» гимназиядә укымаса, «двуязычный» була алмый. Анда да милли тел мохите җитми. Чөнки татарча белгән татарларның үзара татарча сөйләшүе, тел мохитендә катнашуы сирәк очрый!

Татар телен саклау комиссиясе утырышында мәсьәләнең бу якларына кагылу мөмкин түгел иде. Шартлар тудырыламы? Тудырыла. Туган телдә әсәрләр иҗат итү конкурслары бар. Сан ягыннан карасаң, узган елда 1470 әдәби әсәр конкурста катнашкан. Элек язылганнары, классиклар әсәрләре дә бихисап. Укучысы, фильмнарга төшерүчеләре генә булсын. «Яңа гасыр» телеканалында кызыклы сериаллар күрсәтәләр. Тормыштагы кебек русча-татарча җөмләләрне кушып сөйләшүчеләр турында төшерелгән «Бер-бер хәл» сериалы туган тел темасын күтәргән. Карадыгызмы? «Шаян ТВ» каналын татар бала-чагалары көн саен караймы? Чит ил мультиклары кызыграк диючеләр булса, рәхим итеп, карагыз әле үзебезнең тамашаларны да!..

(Дәвамы 4 нче биттә).

җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Дөньяны "тәртипкә" кертү этаплары

Кешелек тарихында төрле чорлар булган. Анда яманы да, яхшысы да җитәрлек. Әмма бүген урнаштырыла торган «яңа дөньяви тәртип», бигрәк тә аның заманча ысуллары, ничек кенә фаҗигале тоелмасын, тарихта сәяси, хәрби һәм әхлакый яктан яңалык түгел. Төрле чорларда андый «тәртип» ничек урнаштырылган соң? Тарих чоңгылларына бик тирәнгә кермәстән, XX гасырны гына алыйк. Бу гасырга ике бөтендөнья сугышы (БДС) туры килә. Алар икесе дә Европада башланып китә һәм төп уенчылары да шул ук. Дөрес, Икенче БДС (II БДС) Азиядә тәмамлана һәм моның үз сәбәпләре бар. Ике сугышта да иң зур югалтулар Россия өлешенә туры килә. Күрәсең, моның да сәбәпләре бар. Тарихта бу сугышларның башлануын да ниндидер сәер сәбәпләр белән аңлаталар. Имеш, алар очраклы гына башланып киткән дә, тиңе булмаган ул сугышлардан соң инде халыкара мөнәсәбәтләрнең яңа системасын булдырырга туры килгән. Тик бөтендөнья сугышлары Сараевода эрцгерцог Фердинандны хатыны белән бергә атып үтергәннән генә (һәм хәтта Алманиянең Польшага һөҗүменнән генә дә) башланып китә алмый. Андый сугышлар, асылда, дөнья тотучылар тарафыннан куелган геостратегик максатларны гамәлгә ашыру механизмы буларак, алдан ук әзерләнә.

Сәясәтне хәрби, икътисади һ.б. чаралар белән дәвам итү ниятендә геосәяси каршылык вә сәбәпләр системасы булдырыла, яңа идеологияләр (коммунизм, фашизм һ.б.) һәм хәтта соң чиктәге сәяси алымнар да (террорчылык, экстремизм) гамәлгә куела. Әлбәттә, хәрби һәм икътисади яктан да җитди әзерлек бара. БДС максатлары исә дөнья тотучыларның геостратегик планнарына һәм конкрет геосәяси вәзгыятькә туры китереп, алдан билгеләнә. Тик аларның сәяси вә гамәли асылын соңыннан гына чамаларга була. Ә әүвәл гавам колагына, әлбәттә инде, аңа аңлаешлырак сәбәпләр «бәян ителә». Әйтелгәннәргә таянып, БДСларның да чын максат вә нәтиҗәләрен ачыклап карыйк. Белүебезчә, I БДС җиңүчеләр солых төзү ниятендә җыйган Париж конференциясе (1919-1920) белән тәгәлләнә. Формаль яктан аның нәтиҗәләре булып та шул нигездә Алмания белән төзелгән Версаль килешүе (1919), Австрия, Болгария, Венгрия һәм Госманлы империясе белән төзелгән килешүләр санала. Ул Россиядә – ике, Алманиядә – бер революциягә һәм 4 империянең таркалуына да китерә. Ә бәгъзеләр өчен төп нәтиҗә – Урталык җирләрендә коммунистик идеология урнашуы. Диннәргә алмашка һәм шул ук принципларда кертелгән идеология буларак, ул чакта әле глобальләштерү сәясәтен дөньякүләм революция рәвешендә гамәлгә ашыру күздә тотыла.

Шундый ук ысул белән II БДСның да чын максат вә нәтиҗәләрен ачыкларга була. Ул капма-каршы ике идеология (фашизм һәм коммунизм) көрәше рәвешендә барса да, төп максат һәм нәтиҗәләр дөнья тотучыларныкы булып чыкты: коммунистик идеология аша Кытайга үтеп керү; мәҗбүри глобальләштерүнең сәяси (БМО), хокукый (Гаага суды), хәрби (НАТО), финанс (МВФ) һ.б. механизмнарын булдыру; дөнья тотучылар өчен геосәяси иммунитет формалаштыру; гарәп җирләрендә Израиль дәүләтен торгызу һ.б. Әлбәттә, Алмания җиңелгәч, Гитлерга каршы коалициянең «зур өчлек» (СССР, АКШ һәм Бөекбритания) лидерлары Потсдам конференциясендә (июль – август, 1945 ел) бу ил һәм аның сателлитлары белән тыныч мөнәсәбәтләргә күчү, шулай ук Европада тынычлык вә иминлек урнаштыруның демократик принципларын билгели. Ә җиңүчеләрнең дөньяны бүлү һәм яңа мөнәсәбәтләр урнаштыру мәсьәләсе әле Ялтада ук (февраль, 1945 ел) хәл ителә, Азат Европа турында декларация имзалана, БМО идеясе дә күтәрелә.

I һәм II БДСлары тарихына кыскача мондый экскурс гибрид алымнар белән бүген алып барыла торган бүгенге вакыйгалар хакында да кайбер нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге бирә. Әлбәттә, аның төп максаты – дөнья тотучыларга кирәкле яңа дөньяви тәртип урнаштыру өчен күпкырлы глобаль кризис аша җирлек әзерләү. Ә андый «тәртип»не солых турында тыныч сөйләшүләр һәм яңа конференцияләр ярдәмендә генә урнаштырып булачак.

Фоат УРАЗАЙ.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Казан Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов РФ һәм ТР дәүләт бүләкләрен тапшырды.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе **Айдар Сәлимгәрәев** РФ Президенты Рәхмәтенә лаек булды. Татарстан һәм Россия Композиторлары берлеге рәисе **Рәшит Кәлимуллинга** «Дуслык» ордены тапшырылды.«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән Россия Федерациясе сенаторы – Федерация Советының халыкара эшләр буенча комитет рәисе урынбасары **Фәрит Мөхәммәтшин,** Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни җитәкчесе **Рафаил Хәкимов** бүләкләнде. «Татарстан» ДТРК радиотапшырулар хезмәте башлыгы **Тәүфикъ Сәгыйтов** президент кулыннан «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орден медален кабул итеп алды.



Төркия Сабан туен бәйрәм итте

Төркиядәге татар авылы Османиянең Сабан туенда татар сәнгать әһелләре Резеда Төхфәтуллина, Ярамир Низаметдинов һәм «Сәйдәш» төркеме биючеләре чыгыш ясады. «Татар-информ»ның Төркиядәге хәбәрчесе бәйрәмне махсус күреп кайтты.

Искешәһәр төбәгендәге Османия (Куруһөюк) татар авылында үткән Сабан туена меңгә якын кеше җыелды. Анда Анкара, Искешәһәр, Истанбул, Күтахья, Конья, Анталья, Аланья, Бурдур калаларында яшәүче милләттәшләр дә катнашты. Анкара, Искешәһәр, Истанбул татарлары Татарстанның Төркиядәге вәкиллеге тәэмин иткән махсус автобуслар белән килде.

Анадолудагы Сабан туе бәйрәме татар авылына нигез салучылар рухына укылган догалар белән башланып китте. Османия татар авылы Сабан туе Искешәһәр татар җәмгыяте тарафыннан оештырылды.

«Бу Сабан туеның үткәрелүенә авыл старостасы Микаил Сүзәр зур өлеш кертте. Сабан туе аланын бизәүне, кунакларны аш-су белән тәэмин итүне, сәнгать әһелләренә һәм уен-бәйгеләргә катнашучыларга бүләкләр әзерләүне, үзара акча җыеп, үзебез хәл иттек», – дип сөйләделәр оештыру комитеты җитәкчеләре.

Сабан туе сәхнәсендә кунаклар да, җирле татарлар да чыгыш ясады. Бәйрәм «Туган тел» җыры белән тәмамланды.

Истанбулдан килүче татарлар төркеме өчен Османия авылы буенча сәяхәт оештырылды, кайбер милләттәшләр зиратка барып, авылга нигез салучы әрвахлар рухына дога кылдылар. Шунысы да игътибарга лаек, авыл халкы зиратта 24 сәгать Коръән уку оештырган.

Төркиядәге Османия авылы – милләттәшләребез тарафыннан 1895 елда нигез салынган беренче татар авылы. Рәсми исеме Османия булса да, халык аны беренче исеме белән Куруһөюк дип йөртә.

Рушания АЛТАЙ.

Корбан бәйрәме анықланды

Татарстан мөфтиятенең Казыйлар һәм Голәмалар шуралары тарафыннан 2022 елда Корбан бәйрәмен һәм гает намазын үткәрү тәртипләре расланды. Корбан гаетенең беренче көне 9 июльгә (шимбә) туры килә (зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне). Гает намазын Татарстанның барлык мәчетләрендә дә кояш чыгып 30 минут узгач уку тәкъдим ителә. Башкала мәчетләрендә корбан гаете түбәндәге тәртиптә үтәчәк:

02.30 – иртәнге намаз;
02.35-03.10 – Коръән укылу;
03.10-03.40 – гает вәгазе укылу;
03.41 – гает намазын уку;
03.45 – гарәп телендә хөтбә, Коръән укып дога кылу.

Гает намазы укылганнан соң махсус билгеләнгән урыннарда корбан чалу башланачак һәм ул Казан шәһәрендә 11 июль 20.23 сәгатькә кадәр (кояш баеганчы) дәвам итәчәк. Корбан нисабы күләме – 32 мең сумны тәшкил итә.

Гарәфә көнендә (8 июльдә) иртәнге намаздан башлап, Зөлхиҗҗә аеның 13нче көнендәге икенде намазын да (12 июль) кертеп, егерме өч фарыз намазның һәркайсыннан соң сәлам биргәч, Аллаһы Тәгаләне олылап, Аны данлап, өч мәртәбә: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр. Лә иләһә илләллаһү вәллаһү әкбәр. Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд» дип тәкбир әйтү мәҗбүри була (хатын-кызлар тәкбирне эчтән әйтә). Бу – Тәшрикъ көннәре дип атала.

1 нче биттә – Чистай Сабан туеннан бер күренеш. **Рамил ГАЛИ** фотосы. «Татар-информ».

«Могҗиза» өмет бирә

Тинчурин театры каршында эшләп килүче мөмкинлекләре чикләнгән балаларның «Могҗиза» театр студиясе «Миһербанлык» спектакле белән үзенең дүртенче сезонын япты. «Әлеге фэнтези тормыш авырлыкларын җиңәргә, калыпларга буйсынмый үзең теләгәнчә эшләргә һәм хыялларны тормышка ашыру хакында», – дип сөйләде «Могҗиза» студиясе кураторы Зөлфия Бәшәрова.

Спектакльдә дүрт бала – Анель, Алсу, Айрат һәм Әмир интернет челтәрендә «Ялкынлы шәһәр» уенында танышып, якын дусларга әйләнәләр. Әмма, ни кызганыч, тормышта берсенең дә чын дусты юк. Төрле язмышлы, тормыш авырлыкларыннан интернет дөньясына чумган балаларны, кинәт кенә ут бетү яшәешкә чыгара.

Фантастик әкиятнең авторы – Илфак Хафизов, режиссеры – Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисов. Спектакль «Во благо вместе» инициатив төркеме җитәкчесе Альбина Сәлимгәрәева ярдәме белән әзерләнгән.

К.Тинчурин театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов инициативасы белән 2019 елның язында оешканда, студиягә 7 бала йөрергә теләк белдергән булса, бүген бу сан 15 кә җиткән. «Могҗиза»ның тагын бер үзенчәлекле ягы шунда: укытучылар балаларда татар теленә мәхәббәт тәрбияли.

Бельгия татарча бии

Бельгиядә Belgian ballerinas хореография мәктәбе үз репертуарына татар халык биюләрен керткән. Мәктәп укучылары уку елы тәмамлану уңаеннан оештырылган хисап концертында өч композиция тәкъдим итте. Бу хакта «Бельгия татарлары» берлеге рәисе Лилия Вәлиева белдерде.

Belgian ballerinas мәктәбендә шөгыльләнүчеләр татар мәдәнияте белән бер ел элек – аларның берсе, Амели Шмитц, «Шүрәле» балетыннан Сөембикә партиясен өйрәнеп, аны бер концертта тәкъдим иткәч танышкан. Бу эштә аңа Казан педагоглары ярдәм иткән.

Мәктәп вәкилләрендә татар биюләренә карата кызыксыну узган елның җәендә Татарстан башкаласының «Сәйдәш» театр-студиясе осталары Бельгиядә оештырылган Сабан туенда чыгыш ясагач уяна. Бию мәктәбе җитәкчесе Веерле де Шкрэйвер сүзләренчә, әлеге чыгыш аның өчен халык иҗатының бөтенләй яңа катламын ачу булган. Ул «Сәйдәш» театр-студиясе солистлары Гүзәл Әхмәтҗанова һәм Евгений Никитиннан мәктәп укучыларын төп элементларга өйрәтүен һәм аларны чыгышларга әзерләвен сораган.

Нәтиҗәдә, кызлар «Казан сөлгесе» композициясен һәм «Чишмә» биюен өйрәнгән. Belgian ballerinas мәктәбендә шөгыльләнүче кызларга бию костюмнарын «Бельгия татарлары» иҗтимагый оешмасы тәкъдим иткән.

Шәйморатовка бюст куелды

Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров Луганск Халык Республикасына эш сәфәре кысаларында Россия Герое, генерал-майор Миңнегали Шәйморатовка бюст ачу тантанасында катнашты. Легендар 112 нче Башкорт кавалерия дивизиясе командирына һәйкәлне Штеровка авылы янында, генералның фаҗигале үлеме урыныннан ерак түгел урнаштырдылар.

– Генерал-майор Миңнегали Шәйморатовның һәлак булган урынына беренче тапкыр гына килмибез. Комдивка бюст ачу тәкъдиме белән чыккан һәркемгә бик рәхмәтлебез, – диде Радий Хәбиров. – Хәзер Донбасс далаларына килеп, чәчәкләр салырга һәм үзебезнең генералны искә алырга мөмкин булган һәйкәл бар. Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы халкына, аеруча балаларга зур рәхмәт. Алар генерал Шәйморатов тарихын яхшы беләләр, аның батырлыгын хәтерли.

Бюст ачылганнан соң, Р.Хәбиров һәм Башкортстан делегациясе вәкилләре М.Шәйморатовның соңгы сугышкан урынына чәчәкләр салды. Легендар комдив дошман тылындагы рейдтан чыкканда 1943 елның февралендә һәлак була.

Телгә теләк кирәк!

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Шундый фикер туа: әллә шул бала-чагаларның, ата-аналарның, яшьләрнең дә тел һәм милләткә ихтыяҗ үстерүче аерым «комиссия»сен төзергә вакыт җитте микән? Гадәттән тыш вәкаләтләр биреп, матди чыгымнарына ярдәм табып? Андый җәмгыятьләр дә бар кебек.

Бөтендөнья татар конгрессының быел үтәчәк VIII корылтае – үзе дә шундый зур җыен, үзе аерым олуг «комиссия» булып тора түгелме? Төрле илләрдән, бигрәк тә татарларның тарихи Ватаны булган Россиядән сайланып килгән делегатлар туган телне, милләтне яшәтү өчен кирәк булган теләк-мотивациянең кайда тоткарланып торганын әйтә ала.

Хәзерге шартлар никадәр катлаулы булса да, глобализация ничек кенә якадан алса да, теләк барында максатларга ирешергә мөмкин. Татар дөньясының һәр тарафында мәдәни үзәкләр, эшкуарлар бар, милли җәмгыятьләрнең хакимият белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе тупланган. Узган гасыр башында классикларыбызның инкыйраз якынаюы, «татарлар үлгәнме, йоклаганнамы?» дип борчылып әйткән сорау-фаразлар әле дә искермәгән. Хәтта алар яңача һәм тагын да шомлырак яңгырый.

Татарлар арасында туып-үсеп, хәтта татар мәдәният-мәгърифәт мәркәзе булган Татарстанның үзендә яшәп тә, туган телне үзләштерә алмаган татарларга кем комачаулый? Җавап: ихлас теләк, чын игътибар җитмәү аяк чала. Патша заманында дәүләт милли телләргә, матбугатка түләмәгән дә, кыстамаган да. Ләкин татарлар мәдрәсә, матбугат, хәтта театр оештырган. Бөтен хикмәт шунда! Теләк туса, телләрне өйрәнү, куллану, милли үзаң саклау буенча дәүләт программаларына нинди проектлар кергүен, аларның ничек үтәлүен белеп, күрсәтеп, үзгәртеп тә була.

Теләк булса, Татарстанда яшәүче 2 миллион, Казан каласында торучы 500 мең татарның милли-мәдәни хәлен өйрәнеп, аларның башка төбәкләрдәге милләттәшләргә үрнәк булуына ирешергә мөмкин. Дәүләт ачкан фәнни-мәдәни үзәкләр белән татар җәмгыятьләре арасында даими аралашу көйләргә дә беркем тыя алмый, теләк кенә кирәк!

Конгрессның Уставында бу оешманың милли үсеш программаларын әзерләү бурычы күрсәтелгән. Бармы бездә андый планнар? Программалар үтәләме? Гражданлык җәмгыяте дигән заманча берәмлек (конгресс үзе дә шул ук күренеш) милли төеннәрне чишүдә катнашамы?

Теләк булса, татар телен ихтирам иткән, безнеңчә аңлаган төрле милләт вәкилләренә таяну, аларны идарә баскычларында күтәрү һич тә кыен эш түгел. РФ Конституциясе, кануннарыбыз нигезендә илдәге халыкларның милли үзенчәлекләрен, мәдәни мирасын саклауның гомумфедераль гамәл дәрәҗәсенә күтәреп булыр иде. Теләк булган хәлдә. Тыелмаган, киресенчә, хупланган милли эшләрне яклаучы идарәчеләр, депутатлар сайлап эшкә җигү дә үзебезнең хөкемдә! Бик күп эшләр башкарып идек. Телләгебез булса...

● Дөньяда барлыгы 50 миллионнан артык корт күче исәпләнә, алар елына миллион тоннадан артыграк бал җитештерә. Бер умарта күче сезонга уртача 27-45 килограмм бал туплый. Бер кашык балны 200 корт көн буе җыя. Умарта күчендә 15 меңнән 80 меңгә кадәр бал корты булырга мөмкин. Эшче кортлар җәен 3 атнадан 6 атнага кадәр яши һәм шул вакыт эчендә бер кашык бал җыеп өлгерә.

● Япон Такеру Кобаяши 2001 елда 12 минутта 50 хот-дог ашап үзенең беренче рекордын куйган; 2012 елда исә 2 минут 35 секунд эчендә 60 кумәчсез хот-догны кабып йотып, дөньяда иң тиз ашаучы кеше исемен кабат раслаган; 2015 елда Патрик Бертолетти, Кевин Стрэйл һәм Боб Шоудт белән бергә 40 фунтлы кәҗәне 13 минут 22 секундта ашап бетергәннәр.

● Кытайдагы Чанчжоу округы клиникасының урология бүлегендә 56 яшьлек хатынның бөерләреннән 2980 таш алганнар, алар диабет чиренә бәйле инфекция нәтиҗәсендә ясалган.

● Кеше тәнендәге иң куәтле мускул – тел.

● Нерв импульсы кешенең баш миеннән сәгатенә 274 километр тизлектә тарала.

● Кеше баш миенең куәте 4 терабайттан артыграк.

Район башлыгы эшеннән китәрме?

Актаныш башлыгы Энгель Фәттаховның бер юк-бар җәнҗал аркасында эшеннән китәргә әзер булуы турында хәбәрне ишеткәч, борынгы бер гыйбрәтле хәл искә килеп төште. Имеш, Борынгы Грециядәге императорның улы атасыннан «ничек идарә итәргә?» дип киңәш сораган, ди. Тегесе улын басуга алып китә. «Карап тор» ди дә, бер сүз әйтмичә, кулындагы таягы белән иң зур башакларны кыеп төшерә башлый. «Аңладым», дип туктата аны улы...

Актаныш башлыгы Энгель Фәттаховны эшеннән алу да мена шундый «зур башакны» кыеп төшерү кебек. Милләт өчен символ булырдай кешене юлдан алып ату.

Эшеннән китүенең сәбәбен – һаман да шул тәре вакыйгасына бәйләп аңлаталар. Тулысынча мөселман саналган Актаныш зиратына православ динендәге кешене җирләү вакыйгасы ярты ел элек зур шау-шу тудырган иде инде. Ул чакта да район башлыгы гаепле булып калды. Менә хәзер шул ук кабер өстенә куелган тәрене кисеп ташлаганнар һәм район башлыгы, үзен бу җитешсезлек, вандаллык өчен гаепле дип танып, шуның өчен җәзасын алырга да әзер булуын белдереп, эшеннән үк китәргә ризалыгын белдергән.

Башта ук әйтеп куйыйм – кабер туздыруга мөнәсәбәтем бик начар. Бу – актык эш. Район башлыгы да шул ук фикердәдер.

Әмма әлеге вандаллыкның «подстава» икәнен аңлау өчен даһи булу таләп ителми бит. «Подстава» һәм провокация бу. Әлеге сүзләрнең татарчага тәрҗемәсе дә юк, хәтта, чөнки татар милләтенә хас сыйфатлар түгел. Чынлап та, бик пычрак һәм ямьсез күренеш. Район башлыгының бу вакыйгага бернинди катнашы юк, әмма аны төп гаепле кеше итеп калдырырга маташалар. Ул бу кешенең Актаныштагы мөселман зиратында җирләвен оештырмаган, моңа күзәтчелек итмәгән, аның каберен килеп туздырмаган. Әмма вандаллыкка барган икейөзле кешеләр бу җинаятьнең район башлыгы Э.Фәттахов исемен пычратачагын һәм аның җавап тотачагын белеп эш иткән. Бу – аннан үч алу. Э.Фәттахов татар теленә һөҗүм барган 2017 елда үзенең принципиаль позициясен белдергән һәм шул сәбәпле татар телен – милләтне яклаучы буларак халык хәтеренә кергән шәхес. Шул рәвешчә, бу подстава һәм провокация татар милләтенә дә һөҗүм булачагын белеп эш иткән бу җинаятьчеләр.

Ничек кенә акланмыйк, бәяләмик, Э.Фәттахов беркайчан да татар телен яклавын яшермәде, шул юнәлештә туктаусыз эш йөртте. Туксанынчы елларда мәгариф министры булып эшләгән Васыйл Гайфуллиннан соң ул «татар теле» дип авыз ачып әйткән һәм татар мәктәпләрен бульдыру һәм камилләштерү өчен көч түккән бердәнбер түрә иде. Янәшә куеп чагыштыру өчен 2007 – чыгарылыш имтиханнарын фәкать рус телендә генә тапшыру турындагы канун кергән елны хәтергә төшерегез. Шул елда республика мәктәпләреннән берьюлы ике меңгә якын татар теле укытучысы тупса аръягына чыгарып ыргытылды...

Әмма Э.Фәттахов кебек фидаи түрәгә эшләргә ирек бирмәделәр, заманы да – якадан яки бугаздан эләктереп сөйләшүгә әверелгән, явыз замана, башка сәбәпләр дә булгандыр, әмма татар җәмәгатьчелеге аңа багышлап «Энгель-хранитель» дигән баннерлар чыгарган икән, димәк, аны кабул иткән һәм яратып өлгергән, үзенә өлге иткән дигән сүз бу. Без татар телен кемнәр яратмавын һәм аңа каршы кемнәр һөҗүм оештыруын да яхшы чамалыйбыз. Бу провокация ул эшләгән районда булган икән, димәк, кемнәр оештыруы да билгеле. Башкаручылары бер шешә хәмергә сатылырдай юньсезләр булырга да мөмкин, әмма менә оештыручылары – мәкерле, явыз һәм җанкыярга әзер...

> *«Дусларым күп дип әйтә алмыйм. Чөнки әнкәй мине кечкенәдән, улым, дус юк ул, беркемгә дә тәмам ышанып бетмә, иң якын дустым дип йөргән кеше дә сине сатарга мөмкин, дип тәрбияләде. Чыннан да, шулай икән. Тормыш бу сүзләрнең дөреслеген раслады. Шуңа күрә мин, аһ, дусларым, дип егылып китмим. Миңа каршы булганнар да аз түгел. Мин гомер буе гаделлек өчен көрәштем».*
>
> **Э.ФӘТТАХОВ белән әңгәмәдән.**

Әйе, юлда нинди генә очрак булса да, хәтта каршыңа көтмәгәндә нindидер җәнлек сикереп чыкса да, рульдәге кеше җаваплы булган кебек, районда нинди генә хәл тумаса да, ахыр чиктә барыбер беренче кеше җаваплы. Шуңа да мөселман зираты өчен бөтенләй чит-ят итеп куелган тәрене кисү кебек гайре табигый очрак туган икән, сәбәбе нинди булуга карамастан, район башлыгының гаепне ахыр чиктә үзенә алуы гаҗәп түгел. Ни өчен тикшерү органнары гаепләләрне ачыкламаган – анысы башка мәсьәлә. Ә менә район башлыгының үз эшеннән китәргә әзер торуы да - хуплауга лаек дип уйлыйм... Ләкин район башлыгының кәнәфие генә хәл ителми бит әле монда. Энгель Фәттаховны баш түбәсенә сугып урынга утыртырга җыеналар икән, димәк, бер үк вакытта татар телен, татар мәгарифен яклаган, татар зиратында милли йолаларны, чисталыкны, милләткә тугрылыкны алга сөргән татар зыялыларының, гомумән, зур бер милләтнең дә башына сугу бит бу!..

Э.Фәттаховтан ниндидер идеаль кеше образын ясарга җыенмыйбыз. Озак еллар район башлыгы булган кешене күп күрсәткечләр өчен тәнкыйтьләргә була, билгеле, аны ошатмаган кешеләр дә күптер. Әмма бер нәрсә бәхәссез – Э.Фәттахов татар милләтен ошатмаучылар өчен, Грециядәге риваятьтәгечә, җитлеккән һәм тулган башак иде. Шул башакны пычрак рәвештә, ямьсез итеп кыеп төшерү турында хыялланалар.

Минем фикеремчә, Энгель Фәттахов татар милләтенә хезмәт итүен дәвам итәргә тиеш. Аның моңа сәләте дә, тәҗрибәсе дә, бу юнәлеш өчен бик кирәкле дәрәҗәсе дә бар. Без пычрак куллар белән кыелган башакны «Бу – безнеке!» дип иелеп алырга һәм аңа яшәргә – орлыкларын үстереп халыкка бүләк итү өчен мөмкинлек бирергә бурычлы.

Бу – татар телен яклау аркасында вазифасын югалткан бер министрны яклау гына түгел. Бу – үзебезне, татар телен яклау. Бу – милләтне яклау.

Безнең кем икәнлегебезне сыныйлар. Без үзебезнекеләрне якларга әзер икәнлегебезне күрсәтергә тиеш.

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.
(Социаль челтәрдәге шәхси сәхифәдән).

Без булмасак, кем яклар?

Энгель Фәттаховны эшеннән китәргә мәҗбүр итүләре – план буенча корылган провокация. Әнә, алдарак Казанга Николай Патрушев ревизия белән – татарлар дәүләткә каршы эш алып бармыйлармы дип тикшерергә килеп җиткән иде. Мөселманнар арасында «яңа экстремистлар» эзлиләр, моның өчен «фәнни» рельсларга куелган методлар да бар, ди...

Әмма татар халкы әчке энергетикасы белән үз әдәбен сакларга барыбер көч таба. Әнә, экраннарда В.Пельшның татарларга багышланган фильмы да күрсәтелде. Шөкер, лаек, матур күрсәтелеләр, тик җанымда курку хисе генә тынгы бирми. Аны башка көчләр дә карап утыргандыр, яратмыйча кул күтәрүләренә дә ерак түгел. Аларда юк итү буенча планнар да бар бит. Яшьләргә безнең мәдәнияттән көлеп, үзләрен өстен итү тенденциясе, татар телен бугазыннан буу – моңа ачык мисал. Өстәгеләр хәтта татар дигән сүздән курка... Ләкин шунысы мәзәк һәм бик сәер: Россия кризис эчендәге сазлыкта интеккән чагында менеджерларны безнең җирлектә тәрбияләнгән кешеләрдән табалар, чөнки әле без милли характерны югалтмадык, туган илгә хезмәт итүдән тәм табып яшибез, тәртип тотабыз. Бездә РУХ үлмәгән... Соңгы елларда яшьләр арасына гел бер фикер сеңдерелә – чит илгә китү! Адым саен чагыштырулар – безнең файдага түгел... Ил турында кайгырып яшәгән, Ил белән горурланып яшәгән кешеләр Кызыл китапка кертерлек...

Илне бер йодрыкка җыйнардай хәвефле бер чорда Актаныштагы провокацияләр кебек вакыйгалар оештырыла. Бу максатчан шау-шу ике ел буе сузыла бит инде. Чөнки Э.Фәттахов милләт символына әйләнде. Ул – татарны, татарлыкны яклап чыккан кеше!..

Татарстанның 23 процент халкы авылда яши. Ә монда республиканың иң гөрләп яшәүче районның башлыгын юк итәргә җыеналар. Аяз абый Гыйләҗевча сорау бирми ничек түзәсең ди: Балта кем кулында? Кара көчләр кулында!

Зиратка камералар кую – динебезгә каршы эш. Ул халык арасына ут җибәрүгә тиң. Сак булырга кирәк!

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА.

Уфа каласында очрашулар

Язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова бу көннәрдә Уфада халык белән зур очрашулар уздырып кайтты. Төп очрашу Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиллегендә булды, биредә татар зыялылары, язучылар, галимнәр, төбәк тарихчылары, журналистлар, милли хәрәкәт вәкилләре җыелган иде.

Ф.Бәйрәмова тәүге тапкыр Уфага 1987 елда, «Болын» дип аталган беренче китабы басылып чыккач, педагогика институты студентлары белән очрашуга килгән булган. Шушы вакыт эчендә ул илледән артык китап язган, шуларның күпчелеген үз хисабына бастырып чыгарган. Башкортстанда яшәүче татарлар тарихын өйрәнеп, ул күп тапкырлар Иске Балтач районында булган, Батырша хәзрәт турында өч фәнни-популяр китап язган. Шулай ук Урал арьягындагы Бөрҗән, Учалы районнарында булып, үсмер балалар өчен «Нух пәйгамбәр көймәсе» дип аталган маҗаралы роман бастырган.

Язучы үзенең кырык еллык иҗаты турында сөйләде, аны чорларга бүлеп, фәнни бәясен бирде. Беренче чор иҗатын ул лирик-романтик, дип атады, аңа «Болын», «Күл балыгы», «Канатсыз акчарлаклар» повестьларын һәм кайбер драма әсәрләрен кертте. Бу чор иҗатында ул кеше күңеленең тирән кичерешләрен тасвирлый, моның өчен серле символ-тамгалар телен файдалана. Икенче чор – күчеш чоры, аңа «Кыңгырау», «Кара урман», «Соңгы намаз» әсәрләре керә, монда тема, өслүб үзгәрүе дә күзәтелә. Өченче чор – тарихи романнар чоры, монысы инде XXI гасырда язылган «Кырык сырт», «Караболак», «Күчем хан», «Һиҗрәт», «Гөлйза» әсәрләре. Ул шулай ук публицистика, фәнни-популяр жанрда да күп эшли, аның татар тарихына, милләт тормышына багышланган дистәләгән документаль китаплары бар. Ф.Бәйрәмова аерым шәхесләргә багышлап язган китаплары белән дә аерылып тора, аның Батырша, Күчем хан, Һади Такташ, Һади Атласи, Габдрәшит Ибраһим, Михаил Худяков һәм Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа турында да документаль китаплары бар.

Очрашуда татар-башкорт мөнәсәбәтләре турында да сүз булды. "Мин ил һәм дөнья буйлап күп йөрим, бу сорауны бары тик Башкортстанда гына бирәләр, – диде ул соңыннан журналистка. – Беркайда да татар-мари, татар-мордва, яки татар-чуаш мөнәсәбәте турында сораганнары юк. Мондагы төп проблема тел һәм тарих белән бәйле. Төп бәхәс шулар тирәсендә бара. Без тарихны, шәхесләрне һәм телне бүлешәбез… Әмма бүген безнең язмышлар ил читендә хәл ителә. Әле дөнья өр-яңадан бүленергә мөмкин. Әзрәк көтик, бу канлы вакыйгалар нәрсә белән бетәр, шуннан соң һәркем үзенең дәлилләре белән үз өлешен алырга тырышачак. Ә тарих кануннар белән хәл ителми, ул милли аңнан тора. Шәхесләр белән дә шулай ук. Башкортларның үз тарихлары, җырлары, менталитеты, холкы бар, аларда халыкчанлык көчле. Ә татарлар интеллектуаль, фәнни як белән алдыра. Башкортларга безнең белән бергәләп, уртак проектларда катнашып, үзләрен күрсәтү яхшы булыр иде. Тик аларның дөньяга үзләре генә чыгасы килә, ләкин бу мөмкин түгел. Башкорт зыялыларына бергә, бер-беребезне баетып яшик дип әйтер идем".

Татар һәм башкорт зыялылары белән чираттагы очрашу күренекле язучы Мәҗит Гафуриның музей-йортында булды. Очрашу алдыннан М.Гафури исемендәге иҗтимагый оешма рәисе Люция Камаева үзләренең нәсел йортында матур, эчтәлекле экскурсия уздырды. Люция ханым – М.Гафуриның оныгы Халитның хатыны, нәсел дәвамчысы Мирсәетнең әнисе, шуңа күрә ул һәр язучы турында белеп һәм яратып сөйли. М.Гафури бу йортта гаиләсе белән 1923-1934 елларда, ягъни, үлгәнче яши, аны язучыга совет хөкүмәте бүләк итеп бирә. Биредә татарның танылган шәхесләре Һ.Такташ, Г. Ибраһимов, С.Сәйдәшев һ.б. кунак була...

Ф.Бәйрәмова белән бу очрашуга, нигездә, төбәк тарихын өйрәнүчеләр килгән иде, ул Себер архивларында алып барган фәнни эзләнүләре турында сөйләде. Биредә көчләп чукындырулар, сөрген һәм репрессияләр темасы алга чыкты. Ф.Бәйрәмова Себер архивларында, бигрәк тә, Тубыл дәүләт архивында, XVIII гасырда көчләп чукындырганнан соң яңадан ислам диненә кайткан татар-башкортларның, кыргыз-кайсакларның хөкем ителү документлары барлыгын әйтте. Шулай ук Екатеринбург архивында, чукынмаган өчен 1739 елда тереләй утта яндырып үтерелгән 60 яшьлек мөселман хатыны Кисәнбикә (Хәснибикә) Байрасова турында документлар саклануын, күчермәләрен алуын сөйләде. Очрашуда тарихи шәхесләр турында да сүз күп булды, М.Гафури музей-йортының мөдире Гадилә Буләкова тәкъдиме белән, Идел-Уралдагы тарихи шәхесләргә багышлап уртак фәнни конференция уздырырга кирәк, дигән фикергә киленде.

Уфа – татар милләтенең тамгалы урыны. Ул Казан һәм Ырынбур белән бергә, татар халкының милли-мәдәни, дини вә гыйльми учакларның берсе булган. Шул данлы тарих эзләре буйлап йөреп, Ф.Бәйрәмова «Галия» мәдрәсәсенә сәфәр кылды, аның узганы һәм бүгенгесе белән танышты. Заманында Галимҗан Ибраһимов укыган һәм укыткан, М.Гафури, Ш.Бабич, Х.Туфан, С.Кудаш һәм тагын бик күп татар зыялылары белем алган мәдрәсә бит бу! Заманының иң алдынгы карашлы шәхесләрнең берсе – Зыя Камали җитәкчелек иткән белем йорты. Әлбәттә, мәдрәсәнең үзен дә, аның җитәкчелеген дә, «Галия»дә белем алган һәм укыткан шәхесләрне дә Сталин чорында юк итәләр. Мәдрәсә бинасы бары тик XXI гасыр башында гына яңадан дин әһелләренә кайтарып бирелә һәм яңадан үз бурычын үти. Ул хәзер «Россия ислам университеты» дип атала, ислам дөньясы университетлары федерациясендә әгъза булып тора, Мисыр, Иордания, Тунис, Болгар ислам академиясе кебек дәрәҗәле уку йортлары белән хезмәттәшлек итә.

Әйе, Зыя Камали нигез салган «Галия» мәдрәсәсе бүген дә милләткә хезмәт итә, ә менә ул үзе яшәгән йорт бүген ярым җимерек хәлендә. Ф.Бәйрәмова монысын да күрде. Заманында бөтен урамны биләп торган утар таланган, яндырылган, алма бакчалары юк ителгән, барысы да ташландык хәлгә килгән. Ә бит З.Камали инкыйлабка кадәр үз йортына М.Гафури һәм С.Кудаш гаиләләрен дә сыендырган булган! Дөрес, Уфада бу тарихи йортны саклап калырга тырышучылар булды, вәгъдәләр дә бирелде, әмма берни үзгәрмәгән булып чыкты. З.Камали шәхесе, аның бай мирасы әле өйрәнелмәгән, үз бәясен алмаган, халыкка кайтарылмаган...

Ф.Бәйрәмованың Уфадагы очрашуларының таҗы, әлбәттә, Дәрдемәндкә багышланган «Аһ, туган каумем газиз!» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Ул «Нур» татар дәүләт театрында узды, аны «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге оештырган иде. Җитәкчесе галим, Башкорт дәүләт университеты доценты, Башкорт дәүләт опера һәм балет театры солисты Марат Шәрипов булган бу үзәк – максатчан рәвештә, күп еллар буе Дәрдемәнд иҗатын пропагандалаучы бердәнбер иҗтимагый оешма. Зыялы, затлы милләттәшләребез җыелган үзәк даими рәвештә Дәрдемәнд иҗатына багышланган фәнни конференцияләр, әдәби-музыкаль кичәләр, күргәзмәләр, сәнгатьле уку бәйгеләре уздыра, Дәрдемәнд исемендәге татар балалар аланы эшли, сирәк ядкәрләрдән торган Дәрдемәнд музееН оештырганнар.

Кабатланмас талант иясе, шагыйрь, хәйрияче, алтын прискалары хуҗасы, шул алтынга Идел-Уралда йөзләгән мәчет-мәдрәсәләр салдыручы, үз хисабына Ырынбурда «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы чыгаручы, 1921 елда Орскида ачлыктан һәм тифтән үлгән, кабере хәрби завод астында калган Мөхәммәтзакир Рәмиев... Дөнья шигъриятенең таҗы булырлык шигырьләр иҗат иткән Дәрдемәнд... Уфада үткән бу кичә аның тууына 160 ел тулуга багышланган иде, пандемия сәбәпле, халык җыеп үткәрү хәзер генә мөмкин булды. Кичәдә татар һәм башкорт зыялылары, язучылар, галимнәр, Дәрдемәнд-Закир Рәмиевнең нәсел дәвамчылары, якташлары катнашты. Татарстаннан язучылар Р.Зәйдулла, Ф.Бәйрәмова, Г.Морат чыгыш ясады.

Дәрдемәнд кичәсендә Ф.Бәйрәмова тарихчы буларак нотык тотты, ул аның иҗаты һәм тормышы бик аз өйрәнелүен, эзләнүләр, нигездә, филологик юнәлештә генә алып барылуын әйтте. Дәрдемәнднең тормыш юлы, тарихчылар тарафыннан, архивларда утырып, өйрәнелмәгән, биографиясенең хронологиясе эшләнмәгән, тормышына ачыкланып бетмәгән, бәхәсле урыннар да шактый. Әйтик, моңа кадәр Җиргән авылында Дәрдемәнднең туган нигезе билгесез иде. Ф.Бәйрәмова 2007 елда Германиягә баргач, Мюнхен шәһәрендә яшәүче, тумышы белән Җиргән авылыннан булган Гариф Солтан аңа Рәмиевләр нигезенең планын сызып биргән, аларның ата-бабалары бер урамда, кара-каршы яшәгән. Германиядән кайткач, Ф.Бәйрәмова Җиргәнгә барып, сызым буенча Дәрдемәнднең нигезен эзләп таба, ул хәзерге С.Юлаев урамында булып чыга. Язучы бу хакта авыл имамына һәм татар зыялыларына да әйтеп калдыра.

Кичәдә Ф.Бәйрәмованың чыгышы Дәрдемәнднең Орск шәһәрендәге чоры турында иде. Бу калада шагыйрьнең үсмер һәм егет чагы үтә, ул биредә гаилә кора, 1918 елның башында, Ырынбур большевиклар кулына күчкәч, аны ташлап, гаиләсе белән янә Орскига кайта… Дәрдемәнд Орскида өч ел яши, шушы вакыт эчендә аның ишле гаиләсе өстеннән күп фаҗигаләр үтә. Улы Морадны аклар мәҗбүри үз гаскәрләренә ала, ул шунда тифтән үлә. Улы Җәгъфәрне кызыллар гаскәргә ала, ул сугыштан бер кулсыз кайта. 1919 елның көзендә олы улы Искәндәрнең авырлы хатыны Шәрифзадә тифтән үлә. 1921 елның көзендә Дәрдемәнднең олы кызы Өммегөлсем Ырынбурда тифтән җан бирә. Аны җирләп кайтканда, Дәрдемәнд үзе дә чирләп китә һәм 1921 елның 9 октябрендә вафат була. Орск янындагы Ильяс авылы зиратына җирләнгән Дәрдемәнд кабере, башкаларныкы белән бергә, сугыш вакытында хәрби завод астында кала һәм юкка чыга...

(Дәвамы 9 нчы биттә).

Мөхәммәт МИРЗА

Адәм баласы

(Цикл)

* * *
Теләге – үргәчә,
Карашы – тезендә...
Адәм баласының
Бәдәне, бөрешеп,
Карыша көзендә.

* * *
...Карама чанага,
Каен тәртәсенә...
Адәм баласының
Атлы ил-көнендә
Кирәк һәммәсе дә...

* * *
Каенлы – кайгырмас,
Тимерле – тилмермәс.
Адәм баласының
Кулы эш белгәне
Ач тормас, ким йөрмәс...

* * *
Йомшагын корт ашар,
Катысын кыш ярыр...
Адәм баласы
Шуларны күреп тә
Җирдә яраклашыр...

* * *
Санаулы тиз үтә.
Үлчәнгән тиз бетә...
Адәм баласын тик
Гомере буе бетмәс,
Төкәнмәс эш көтә.

* * *
Азы җитәр, хәтта
Җитми калыр күбе...
Адәм баласының
Аеруы кирәк
Орлыгыннан чүбен...

* * *
Эш кушсаң, коелыр
Укасы, серкәсе...
Адәм баласының
Итәгеннән төшмәс
Әнкәсе иркәсе...

* * *
Ташны оргач ташка,
Чәчрәп чыккан очкын...
Адәм баласының
Шул мәлдән кулында
Утлы уенчыгы...

* * *
Йорт-курасы таштан,
Шыплап тулган малы...
Адәм баласының
Бәхете чиктән ашкан, –
Сынау тоткан мәле...

* * *
Тукталып тын ала,
Атлап китә тагын...
Адәм баласының,
Ниһаять, таныйлар
Тузып картайганын…

* * *
Шәмдәй төз сынына
Туймыйлар сокланып...
Адәм баласының
Иңендә фәрештә:
Куйды нидер язып...

* * *
Шартлар чиккә җитеп,
Тәгәрәп көлгәне:
Адәм баласының
Бер хилафсыз үткән
Бәхетле көннәре...

* * *
Исеме – тугач ук,
Дан, шөһрәт – танылгач...
Адәм баласы, шәт,
Исем-шөһрәт алды,
Күп йөреп ялынгач...

* * *
Ат солтаны – юрга, –
Адаштырмас юлда.
Адәм баласының
Юлдан язганнары
Атсыз булуында...

* * *
Кунак сорар – табар,
Таңнан торып чабар...
Адәм баласына
Бабасыннан калган
Изге гадәт йогар...

* * *
Күршесендә күрер,
Уятып ниятен:
Адәм баласын ул
Җир читенә илтер,
Таптырып төятер.

* * *
Үткәреп мактаган, –
Мул салган зыянын.
Адәм баласы гел
Оныта башлаган
Нәфесен тыярын...

* * *
Сурәткә баткан тән –
Кем кайда, ни күргән?
Адәм баласының
Тәнгә талымсызы
Соңлап бик үкенгән.

* * *
Танымый үттеме? –
Тормагыз шаккатып.
Адәм баласының
Мантыган мәле бу,
Бәрәңгесен сатып.

* * *
Тышыннан танырлар
Чүлмәген, капкачын...
Адәм баласының
Җил-давыл кыймшатмас
Коймасын, капкасын.

* * *
Тирмәсе – киездән,
Ятагы – чыптадан...
Адәм баласы шул
Җәйләү-кышлавыннан
Ун гасыр чыкмаган.

* * *
Атын җуйган мәлдән,
Күрсәтмәс димәссең:
Адәм баласының
Ирдәүкәләр тотар
Ил-йорт дилбегәсен...

* * *
Матриархат чиккән:
– Кайтырмын, – дип янап.
Адәм баласының
Черкигә «чер» иткән
Ир дигәне яман...

* * *
Таш чокып искәрткән
Гасырлар катыннан:
Адәм баласының
Батырының әҗәле... –
Бер уйнаш хатыннан.

* * *
Тәхетле чагында
Җае – ясагыннан...
Адәм баласының
Кысылып чыгуы –
Урынбасарыннан...

* * *
– Күтәр, – дияр, – асар;
– Төшер, – дияр, – басар...
Адәм баласының
Тәхетлесенең колы –
Кансыз урынбасар...

* * *
Тапканы – таланган,
Хәрәмнән – капканы.
Адәм баласының
Аерып аямый
Яуга чапканы...

* * *
Коллыкка төшереп,
Качырганнар котын...
Адәм баласының
Кайчан күтәрелер
Кыйммәтләнгән поты...

* * *
Дөньялык – тоташтан
Могҗизалар кыры...
Адәм баласының
Бар рәхәтен татыр
Өлгере, тапкыры.

* * *
Барда – бергә, юкта –
Торыр югалып та.
Адәм баласының
Бердәм бөтенлеге –
Хак иманы ныкта!

* * *
– Кемгә кулай ил бу?
– Кем терәге – имән?
Адәм баласының
Тик әшнәлесенә
Хак өлеше тигән!

* * *
Арттан сүтеп алып,
Алга куя салып.
Адәм баласының
Алгарышына Күк
Тора хәйран калып...

* * *
Көзенә керүдә –
Тезенә өрүдә...
Адәм баласына
Киез итегенә
Ияреп йөрүдә...

* * *
Җилдә корган җилкән:
Диңгез, дәрья кичкән...
Адәм баласына
Ерак бабасыннан
Яраклашу күчкән.

* * *
Төрен бүлгән төргә,
Аерып башын башка.
Адәм баласына
Хас күнеп килешү
Хәтта ят карашка.

* * *
Аклы-кара төсне
Төссезлек диләр ник?
Адәм баласының
Җирдәге гомере
Көн-төннән тора бит.

* * *
Сәгать теле чаба,
Саный-саный, уңга.
Адәм баласының
Гомеркәе ага
Капма-каршы юлда.

* * *
Кемнеңдер салганын
Табып, өс ябынган
Адәм баласына
Кулдан-кулга күчеп
Йөрер яр ягылган...



* * *
Бурыч баткагына
Күрәләтә кергән
Адәм баласының
Калган гомере торыр
Гел йокысыз төннән...

* * *
Ялкыны – яндыра,
Күмере – кыздыра...
Адәм баласы үз
Гомерен учагы
Янында уздыра...

* * *
Галәмдә барысы
Кирегә әйләнә...
Адәм баласына
Алтыда – алтмышта
Күрере шәйләнә...

* * *
Өсте – өстәгегә,
Әйрәне – сатыла.
Адәм баласының
«Сөт кала – Ватан юк»
Дигәне ач тора.

* * *
Яланөс. Яланбаш –
Ялангач иркендә...
Адәм баласының
Кайнар йөрәклесе
Бик кирәк ил-көндә...

* * *
Таянганы – таяк,
Туктап калган арып...
Адәм баласы, үз
Үткәненә карап,
Китәр юлын табып...

* * *
Көлке куа килә,
Куып, ега сугып.
Адәм баласының
«Тоттырмыйм» дигәне –
Кабартылган куык.

* * *
Эт өреп торганда
Бүре кереп кырган.
Адәм баласының
Каравылдагысы
Бикләнеп утырган.

* * *
Түренә дә үтәр,
Тупсада да көтәр...
Адәм баласының
Соранып килгәне
Бер әҗерсез китәр.

* * *
Ниятенә кергән –
Морадына җиткән.
Адәм баласының
Үҗәт тәвәккәле
Арысланны җиккән.

* * *
Бер чумып чыкканнан
«Чукынды» димәсләр.
...Адәм баласының,
Иманын имгәткәч,
Малына тимәсләр.

* * *
Биш бармак – биш балдак, –
Күзне камаштыра.
Адәм баласын шул
Көяз купшылыгы
Хатыншалаштыра...

* * *
Кем ни язмас – кемнең
Каләме кулында.
Адәм баласы – Мин,
Язган-сызганнарым
Тик үзем турында.

Атнаның сәяси мизгелләре

СӨЙЛӘШҮЛӘРГӘ ҖАЙ ЮК

«Коммерсант» газетасы Украинада якларның анда һәлак булган сугышчылар җәсәден алыштырып алулары турында язып чыкты. Узган атнада Запорожьеда шундый операция нәтиҗәсендә 56 шар җәсәдне алыштырып алганнар. Украинага хәтта җирләү өчен «Азовсталь»дә һәлак булган 64 сугышчының мәетен кайтарып биргәннәр. Әлеге операция Женева конвенциясенә туры китереп башкарылган. Газета язуынча, җәсәдләрне шулай алыштырып алуның иң зурысы Запорожьеда моңа кадәр, «160 ка 160» схемасы буенча, 4 июньдә үткәрелгән. Ә Россия президенты В.Путинның халыкара эшләр буенча ярдәмчесе Ю.Ушаков узган атнада Украина ягының Донецк каласын 6 сәгать дәвамында, соңгы 8 елда күрелмәгәнчә тупка тотуы хакында да әйтте, моңа Көнбатышның реакциясе сүлпән булуы һәм БМОның моны анык кына шәрехләмәвенә дә зарланды. Ә анда тыныч халыктан 5 кеше һәлак булган һәм 39ы тән җәрәхәтләре алган. БМОда исә Донецкта гуманитар хәлнең соңгы атнада гадәттән тыш начар булуын гына әйтеп чикләнгәннәр. Ә ДНР бу җәһәттән, өстәмә көчләр белән ярдәм итүен сорап, Россиягә дә мөрәҗәгать иткән.

Әлбәттә, бәхәсләр БМО залларында да бара. Элегрәк БМО КШ утырышында Европа берлеге башлыгы Мәскәүне дөньяда азык-төлек кризисы китереп чыгаруда да гаепли башлагач, Россиянең оешмадагы вәкиле В.Небензя утырышлар залын ташлап та чыгып киткән иде. Кыскасы, Россияне нигәдер һәр җирдә бер гөнаһсызга рәнҗетергә тырышалар. Өстәвенә, әлегә сөйләшүләр үткәрергә дә җай юк икән. Ю.Ушаков сүзләренә караганда, Россия-Украина сөйләшүләрендә әлегә бар нәрсә дә туктаган. Күзгә-күз карап аңлашкан соңгы сөйләшү исә Истанбулда 15 апрельдә үткән булган. Ә ул арада Украинаның һаман яңадан-яңа көчләрен җәлеп итүе турында да әйтелә. «Известия» газетасы язуынча, мобилизация нәтиҗәсендә Киев инде йөзләрчә мең кешене җәлеп иткән. Шуның белән бергә, сугыш кораллары белән тәэмин ителеш ягыннан Украинаның әлегә күпкә калышуы да мәгълүм. Шуңа күрә аның югалтулары да көн саен 100-200 кешегә җитүе турында да әйтелә.

Ә вакыйгаларның күплеге җәһәтеннән бу атна да кайнар булыр кебек. Мәгәр, Көнбатыш та Украина турында кайгыртуын туктатмый. Алмания, Италия һәм Франция лидерларының анда күмәк сәфәре, шулай ук Украинага ярдәм буенча коалиция илләре саклану министрларының «Рамштайн-3» очрашуы шул хакта сөйли.

Фоат УРАЗАЙ.

«Үз халкыма ярдәм итә

Психолог, психотерапевт Рамил Гарифуллинны республикабызда белмәгән кеше юктыр. Чөнки ул телевидение экраннарында еш күренә, 90 нчы елларда зур залларга халык җыеп сеанслар үткәргәнен дә хәтерләүчеләр бардыр. Күпләр аны алкоголизмнан, наркоманиядән дәвалаучы психотерапевт буларак белә. Ә Рамил әфәнде исә үзен күбрәк фән кешесе дип саный. Моның өчен нигез дә бар – ул күпчелеге Мәскәү нәшриятларында басылып чыккан дистәләрчә фәнни китап авторы. Рамил Гарифуллин – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булган бердәнбер психиатрдыр. Бүген аның белән иркенләп әңгәмә корырга да форсат чыкты – каһарманыбыз шушы көннәрдә 60 яшен тутырды.

– Рамил әфәнде, Сез 1984 елда КФУны физик белгечлеге белән тәмамлап чыккансыз, ә 1991 елда шушы ук вузны икенче тапкыр тәмамлап, психолог дипломы алгансыз. Юнәлешегезне үзгәртергә нәрсә сәбәп булды?

– Физика факультетында уку мине үстерде, шәхес буларак өлгертте. Анда мин молекуляр физика белән мавыгып киттем, аннары шушы юнәлештә диссертация дә яздым. Ләкин ул диссертация якланмыйча калды, чөнки ул чакта бездә мин мөкиббән булган чылбырлы молекулалар, бигрәк тә ДНК һәм аксымнарны өйрәнүче юнәлеш буенча биофизика кафедрасы юк иде. Ләкин кайчандыр бу өлкәдә эзләнүләрем миңа бүгенгә кадәр ярдәм итә. 80 нче еллар ахыры иде, катлаулы чорлар. Өйләндем, гаиләне алып барырга кирәк. Минем әти (Рәмзи Гарифуллин – **ред.**) театр училищесының беренче чыгарылышыннан булган актер иде. Ул белем җәмгыятендә эшли, лекцияләр укый, профессионал иллюзионист, психологик тәҗрибәләр күрсәтә иде. Әти 1982 елда вафат, ә мин аның юлын дәвам итәргә булдым, шул ук җәмгыять кысаларында психология буенча лекцияләр белән чыгыш ясый башладым. Бу вакытта әле илдә психология турында белемнәр аз, халык арасында тиз популярлашып та киттем. Тиздән лекцияләрем зур залларда үтә башлады, хәтта Казан циркы бинасында да чыгыш ясарга туры килде. Ләкин мин психологиягә тирәннән кереп киткәнче, башта философия белән мавыктым, аннары психология буенча укырга кердем. Кандидатлык диссертациям наркотикларга бәйлелектәге шәхеснең психологиясе темасына язылды. Гомеремнең күп өлешен фәнни эшчәнлеккә багышладым, дип әйтә алам. Бүгенге көндә КФУның психология институты доцентымын.

– Нинди яңалык ачтыгыз?

– Мин һәрвакыт яңалыкка омтылдым, моңа хәтле беркем дә эшләмәгәнне эшләргә тырыштым. Әйтик, манипуляция психологиясе. Бу юнәлеш безнең илдә бөтенләй өйрәнелмәгән иде. Шулай ук беренчеләрдән булып төрле бәйлелекләрне: алкоголизм, наркомания, игроманияне психологик-теоретик яссылыкларда өйрәнә башладым. Кеше нindидер бәйлелектә булганда, аның белән нинди үзгәрешләр барлыкка килә? Аның максатлары, кыйммәтләре, яшәү мәгънәсе ничек үзгәрә, моны кирәкле юнәлешкә борып җибәреп буламы? Кандидатлык диссертациям белән мин бу темаларны башлап җибәрдем.

Илнең гомуми куркынычсызлыгы темасы белән дә профессиональ шөгыльләндем дип әйтә алам. 90 нчы елларда мин беренчеләрдән булып чиновникларның, зур җитәкчеләрнең эчкечелеге илнең милли куркынычсызлыгына ни дәрәҗәдә тәэсир итүе хакында уйлана башладым, эчкечелек һәм наркомания нәтиҗәсендәге деградация аркасында җәмгыятебезнең үзенә үзе куркыныч тудырачагын аңладым. Бу фаразларым, өйрәнүләрем белән Россия президенты администрациясенә дә мөрәҗәгать иттем. Соңрак мин ришвәтчелеккә бәйлелек (взяткомания) концепциясен дә эшләдем. Өйрәнә торгач, күп кенә түрәләрнең әлеге бәйлелектән «газап чигүләре» ачыкланды. Һәрбер ришвәт алучы моның белән чирли дигән сүз түгел бу, ләкин кайберләре чыннан да ришвәтне баер өчен дип алмый, ә ришвәт алмаса, газап чигә башлаганга, бу адымга бара икән бит. Бу өлкәләрдәге ачышларыма өстәгеләр дә колак салды, әйтик, РТ президентының коррупциягә каршы сәясәт идарәсе җитәкчесе Марс Сарымович Бәдертдинов миңа даими рәвештә эксперт сыйфатында мөрәҗәгать итә.

– Рамил әфәнде, Сез Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дә бит.

– Галим булган хәлдә, бөтен тормышым телевидение, кино, мәдәният белән тыгыз бәйләнештә узды. Мин беренче булып күренекле кешеләр белән психоаналитик тикшеренүләргә корылган телевизион проект эшләдем, ике ел буе әлеге проектны атналык «Аргументы недели» федераль тапшыруы кысаларында алып бардым. Бу проектта күренекле сәясәтчеләр, артистлар катнашты, ахыр чиктә минем идеяне Беренче каналда урладылар. Мин аларны судка бирдем һәм урланган программаны эфирдан алдылар.

Басма матбугатта да гел басылып тордым. Публицистик һәм язучылык эшчәнлегем өчен мине журналистлар берлеге әлеге мактаулы исемгә тәкъдим итте дә инде. «Психотерапевтические этюды в стихах», «Телеигра в ничто», «Полет над людьми психушки» әсәрләрен, Казан турындагы хикәяләремне укучылар яратып кабул итте. Мин бит Бауман урамында туып-үскән кеше, балачагым шунда үтте.

– Кинематография өлкәсенә дә мәхәббәтегезне беләбез…

– 15 ел буе Мәдәният һәм сәнгать университетында психология укыттым, соңгы өч елда телевидение һәм кино кафедрасында доцент булып эшләдем. Башта кино белән мавыгу хобби гына булса, аннары кызып китеп дүрт кыска метражлы фильм төшердем. Аннары башка сценарийлар язылды, яңа фильм төшерелде. Хәтта «Режиссер мозга» дигән тулы метражлы фильмда төп рольне – психиатрны үзем уйнадым да. Башка фильмнарда да рольләрем бар. Фәндә дә, сәнгатьтә дә иҗат белән бердәй тәм табып шөгыльләнәм. Кино төшерү, киногa төшү – минем шәхси психотерапиям дияргә дә була. Ләкин хәзер кино төшерү бик авыр, бик кыйммәткә төшә.

– Күпләр психотерапевт булгач, Сезне көннәр буе авырулар кабул итә дип күз алдына китерә. Ә Сез күпчелек вакытыгызны имән өстәл янында язып үткәрәсез икән бит.

– Әйе, чыннан да шулай. Авыруларны мин атнага бер көн генә кабул итәм. Бу 35 ел буе шулай. Ләкин мин үземә килгән кешеләрне бик яратам. Миңа күбрәк үзебезнең Татарстан кешеләре мөрәҗәгать итә. Кабинетымда үзебезнең татар авылларыннан килгән кеше пәйда булса, шатланам, күңелем нечкәрә. Үз халкыма үз телемдә ярдәм итә алуыма бик шат. Эчкечелектән тыш, депрессия, неврозлар, төрле башка бәйлелекләр проблемалары белән киләләр. Бу бәйлелекләр кешегә яшәргә комачаулык итә. Кешенең тормышында ниндидер кыйммәт барлыкка килә һәм ул аннан башка яши алмый башлый. Әйтик, тәмәке кыйммәте. Әгәр кеше тартмый икән, аның өянәге башлана. Әгәр ул азартлы уен уйнамый икән, аның өянәге башлана… Үз милләттәшләремә бу зәхмәтләрдән котылырга ярдәм итә алуым белән аеруча горурланам. Нәкъ менә алар мине хәзерге дәрәҗәмә күтәрде. Безнең милләт бик матур, үзенчәлекләргә бай милләт. Миңа эчкечелектән дәваланырга килгән кешеләр – бай күңелле, матур кешеләр, бары тик аларга алкоголь бәхетле булырга, яхшырак яшәргә комачаулаган. «Ул сәрхушләр белән ничек

алуыма бәхетлемен»

● Кызы Энҗе (сулда) һәм хатыны Резида белән.

эшләргә була?» – ди кемнәрдер. Юк, киресенчә, алар бик бай рухлы, нечкә күңелле кешеләр, алар башкалардан бер яклары белән дә ким түгел. Татарның хәмергә карата табигатьтән килгән биологик саклагыч механизмнары юк, шуңа күрә татарлар эчкечелеккә руска караганда җиңелрәк бирелә. Эчкечелек – безнең милләтнең кыйммәте түгел ул. Без аннан баш тартырга тиеш.

– Гади кешеләргә, халыкка психиатрлар, психологлар ни дәрәҗәдә кирәк соң?

– Һичшиксез кирәк. Нәкъ менә гади кешеләр еш кына шулкадәр эш белән басылган ки, аларның туктап уйланырга, хатыны белән чын күңелдән сөйләшеп утырырга, аны җылы итеп кочакларга да вакыты юк. Күңел ачып алырга, каядыр йөреп кайтырга…Үземә приемга килгән кешеләрдән: «Хатының белән кайчан соңгы тапкыр берәр җиргә бардың, сөйләшеп утырдың, бергәләп ял оештырдың», – дип һәрвакыт сорыйм. Гел авыр эш белән басылган халык, бердәнбер туарылу чарасы итеп, аннары аракыны сайлый. Ә бит вакытында туктап ял итәргә, үзеңнең эчке тавышыңны тыңларга, якын кешеләрең белән аралашырга кирәк. Ләкин хәзер эчкечелек нык кимеде. Эчкән кешене эштә дә тотмыйлар, күбесе үлеп бетте, минем өлешем дә бардыр дип өметләнәм (*елмая*). Халыктагы психологик наданлыкны бетерергә кирәк. Алар белән җиңел идарә итә алмасыннар, үз кирәкләренә файдалана алмасыннар өчен зарур бу. Эчкечелек проблемасы – ул тормышның, гомернең мәгънәсе проблемасы. Мин үземә килгән кешедән беренче итеп: «Сез тормышыгызны үзгәртергә телисезме?» – дип сорыйм. Юк икән, алга таба эшләп булмый. Мин кешене: «Эчәсең икән, үләсең», дигән примитив куркыту аша дәваламыйм. Иң мөһиме – кешегә тормыш мәгънәсе хакында мәгълүмат кертү, аның тормышындагы хәмер эчү кыйммәтен башка кыйммәтләр алыштырырга тиеш. Күпләрнең тормышы, минем кабинетка килеп кергәннән соң, тамырдан үзгәрә.

– Хәзер яшьләр арасында депрессиядән газап чигүчеләр күп, шуның аркасында үз-үзләренә кул салучылар да шактый. Алар авыр тормышта интегеп яшәүчеләр түгел…

– Яшьләргә хәзер эмоциональ-ихтыярый үсеш өчен шартлар юк. Шатлык – ул нindiдер киртәне үтеп чыкканга бүләк, ихтыяр көчен сарыф итеп нидер эшләгәндә генә шатлык хисе барлыкка килә. Яшьләрнең ихтыяр сыйфатлары үсми, шуңа күрә алар шатлык хисе кичерүдән мәхрүм. Һавасыз торганнан соң, һава сулый башлыйсың – бәхет. Яшьләрдә ихтыяр көче җитлекми, алар хезмәтнең ни икәнен белми, эштә киеренкелек хис итү юк. Хәзер шундый заман, эшләмичә дә ачка үлмәскә була. Күпләр паразит тормышын сайлый. Әйтик, шул ук Европада күпме халык паразитларча дотацияләрдә утыра. Яшьләр, ихтыяр көче куеп, нәрсә беләндер шөгыльләнү һәм шуны эшли алуга шатлык хисе кичерүдән мәхрүм. Күпләр ни спорт, ни хезмәт белән мәшгуль түгел. Гап-гади нәрсәләрне бәхет буларак бәяләүдән мәхрүмнәр. Әйтик, эштән арып кайткан кеше өчен диванга утырып ял итү дә шатлык. Шуңа күрә яшьләр шатлык тойгысы кичерү өчен башка юллар эзли башлый. Ихтыяр көчен кулланмый гына, чиста кайф алырга омтылалар. Тормыш кыйммәтләре калмый, алар өчен гомернең мәгънәсе югала, ягъни депрессия башлана. Шундый чакта алар сукыр була, үзләренә кул сала. Күбесе өчен тормыш мәгънәсе эчкәч яки наркотик кабул иткәч кенә ачыла башлый. Депрессияне кешенең ихтыярын тәрбияләү юлы белән дәвалап була. Вакыт кирәк.

– Әсәрләрегез үз юлыгызда очраган кешеләр, үзегез кайчандыр дәвалаган пациентлар турында да. Кайсысының язмышы Сезгә нык тәэсир итте?

– Балтач районының Арбор дигән авылында фаҗигале хәлләр булган иде. Эчкече шешәдәшләр бер-берсенең поминкаларыннан соң эстафета тәртибендә асылынып үлә баралар. Асылынучылар саны 8гә җитә. Иң соңгысы берүзе калгач, минем кабинетка килде, бу традицияне дәвам итәргә теләмим, мине дәвалагыз, бу капкыннан чыгарга телим, диде. Авылда бөтен халык нидер көткән кебек хәзер миңа карый, ди. Бу вакыйгалар турында мин ахырдан «Соңгы» дигән хикәямне яздым. Ул исән калды.

– Рамил әфәнде, күптән түгел 60 яшегезне билгеләп үттегез. Ниндидер нәтиҗәләр чыгару чоры бу. Киләчәккә планнар бармы?

– Мин көнлек, атналык, айлык, еллык планнар төзеп куям да шулар буенча яшим. Ваграк максатлар атналык планга, зурлары еллык планга языла. Хәзер мин яңа романымны язып ятам, ул «Озак яшәү коды» дип атала. Әсәр картлар йортындагы тормыш турында. Бу үлем алдындагы карт кешеләр белән аралашу тәҗрибәсеннән туган әсәр, уку өчен дә катлаулы булачак. «Казань-ностальжи» китабы дөньяга 9 яшьлек бала күзлегеннән язылган булса, монысында вакыйгалар карт кеше карашы аша бирелә. Мин хәзер шушы әсәр белән яшим. Башта мин үз күзәтүләремнән аерым этюдлар язып барам, аннан шушы кисәкләрне зур әсәр итеп оештырам. Картлар йорты турында зур әсәр язармын дип уйламадым да, бары тик этюдлар язып баруымны дәвам иттем. Аннары үзеннән-үзе алар бербөтен булып тезелде… «Казан ностальжи» ничек язылды? Һәр таңны компьютер каршына утырам да, күзләремне йомам һәм балачакка кайтам. Бауман урамы, 36 йорт… Балачакны күз алдына китерәм дә шул аерым картиналарны тасвирлап язып куям. Башта Фейсбуктагы «Казань ностальжи» сайтына яздым. Укучылар яратты. Ә анда бик таләпчән, усал укучылар утыра. Нәрсәдер ошамаса, чагып кына алалар. Бу бер ел һәр иртәне шулай дәвам итте. Иртәнге 6дан 9га хәтле утырам. Соңыннан бу хикәяләр китап булып басылып чыкты. Гомумән, иҗат һәм фән – минем тормышымның ике төп чишмәсе.

● «Режиссёр мозга» фильмыннан бер күренеш.

– Кызыгыз да Сезнең юлны сайлаган дип беләм.

– Әйе, бердәнбер кызым Энҗе Гарифуллина – минем коллегам, ул КФУның психология институтын тәмамлады, психолог, нумерология белән дә шөгыльләнә. Кинода да төшә. Хәзер ул Ирландиядә университетта эшли, кияүдә.

Эльмира СИРАҖИ.

Уфа каласында очрашулар

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

2013 елның көзендә Орскига барып, анда яшәүче татарлар ярдәмендә Ф.Бәйрәмова Дәрдемәнд үлгән йортны эзләп таба. Ул шәһәрнең иске өлешендә урнашкан, мәчеттән ерак түгел. Бер катлы таш йорт Дәрдемәнднең хатынының туганнарыныкы була. Йорт хәзер ташландык хәлдә, чүп-чарга күмелеп ята...

Бүген Орскида Дәрдемәнд истәлегенә бернәрсә дә – урам да, истәлек билгесе дә, хәтта шәһәр музеенда бер почмак та юк... Шул нисбәттән, урындагы татар милли оешмалары менә инде ун елдан артык Орскида Дәрдемәнд истәлегенә стела куярга тели, әмма калада хакимият алышынган саен, эшне яңадан башларга туры килә. Ниһаять, истәлек билгесе куярга җир биргәннәр, әмма ул шәһәр читендәге мөселман зираты янында һәм Орскида яшәп һәм эшләп киткән өч татар язучысына – Муса Җәлилгә, Дәрдемәндкә, Мирхәйдәр Фәйзигә куелырга тиеш була. Дәрдемәндкә иске шәһәрдә дә аерым истәлек билгесе куярга телиләр, әмма хәзергә ул сүздә генә...

Уфа белән саубуллашу шәһәрнең мөселман зиратында булды, 26 май көнне биредә күренекле дин галиме Ризаэддин Фәхреддин истәлегенә мемориаль комплекс ачылды. Риза хәзрәт һәм улларының яңартылган кабер ташларын ачу мәрасимендә мөфтиләр Тәлгать Таҗетдин һәм Камил Сәмигуллин да катнашты, биредә Татарстаннан язучылар Р.Зәйдулла, Ф.Бәйрәмова һәм Г. Морат та булды. Кабер ташларын яңарту чыгымнарын "Татнефть" үз өстенә алган. Мәрасимдә Әлмәттән берләшмәнең рәис урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев һәм Кичүчат авылыннан Р.Фәхреддин исемендәге музей директоры Диләра Гыймранова да катнашты. Дини мәрасимдә Риза хәзрәтнең нәсел дәвамчылары да бар иде.

Әмма ziratta, кабер өстендә дә татар-башкорт мәсьәләсе күтәрелми калмады, аны дини мәрасимдә чыгыш ясаган башкорт конгрессы вәкиле башлады. «Р.Фәхреддин документларда үзен башкорт дип язган», диде ул, Америка ачкандай. Аның сөйләп бетергәнен тыныч кына тыңлап торган мөфти Т.Таҗетдин, «Тегендә баргач, син татармы, башкортмы дип сорамаслар, динеңне сорарлар, – дип җавап бирде. – Элек ыру исеме белән йөртмәгәннәр, кешеләр үзләрен мөселман дип атаган. Шушыларны бутамыйк!» Мәрасимгә җыелган халыкта да сорау туды – Р.Фәхреддиннең чүп баскан, чардуганнары кыйшайган, ташлары җимерелгән каберен өстеннән еллар буе таптап йөргәндә, башкортлар нигә аның «башкорт»лыгын хәтерләп, каберен рәткә китермәгән икән соң? Татарстаннан килеп, Риза хәзрәтнең һәм улларының каберен гөлләргә күмгәч, мәрмәргә төргәч, ташларын яңарткач, керү юлларына кадәр салгач, аның «башкорт»лыгын искә төшерделәр…

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

УЕН ЭШ ТҮГЕЛ

«Каршы таулар» повестеннан

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН

Гомер буе иген игеп, мал асрап, авылдан юньләп чыкмыйча яшәгән татар агайлары өчен мылтык күтәреп, аңардан тере кешеләрне атып, аларны үтерергә тырышу сәер дә һәм аларның табигатьләренә каршы да килә иде. Немец булмагае әллә кем булсын, барыбер адәм баласы бит инде. Ничек итеп күзең белән күрмәгән, үзең белмәгән кешегә кул күтәрмәк кирәк тә, ничек итеп аңарга төзәп атмак, аны үтермәк кирәк? Шул ук вакытта башка бүтән төрлерәк уй да килә. Әгәр ул сине үтерсә?! Авылдан чыгып киткәннән алып, баштарак сирәк–мирәк кенә, ә аннан соң ешрак итеп немецлар белән сугыш кырларында очрашу күз алдына килә башлады.

Инде менә алар фронтка килеп җиттеләр һәм командирлар күрсәткән җирдә окоплар, блиндажлар казыйлар. Сугышырга хәзерлек алып баралар, тик алларындагы аркылыга сузылган озын аланда бер генә немец та күренми. Туңа башлаган җирне этләшә–этләшә чоку кемгә кирәктер инде, шайтан белсен.

– Кая ул немец дигәннәре? Нигә һаман юк ул? Җир эшен без гомер буе өйрәнеп, чигенә чыккан халык инде. Күпме казырга була?

Миңлебайның зарлануыннан Сәйфулла көлеп куйды:

– Немецның разведкасы белгән ди инде монда Капар Миңлебаен китереп окоп казытканнарын. Күп ашый торган кеше, аның белән бәйләнмәгәнең хәерле, дип әйткән ди Гитлер үзе.

– Нәселегез белән юньле сүз сөйли белмәдегез инде сез, Гитлер мине каян белсен ди инде ул...

Миңлебайның уен сүзне аңлап бетермәгәненнән көлешеп алдылар. Шул чакта алар янына лейтенант Прохоров килеп җитте. Килү уңаена ук кычкырырга тотынды:

– Тагын татарча мыгырдаумы? Ә? Хәзер үк урысчага күчегез! Бәлки сез немецларга чыгу турында сөйләшәсездер? Ә? Урысча гына!

Аңарга башкаларга якынрак булган Гыйният күзен яшерергә тырышып җаваплады:

– Наша твая не панимай. Урысча плохо знай. Не панимай!

Прохоров бүртенеп кызарды:

– Мол-лчаать!!! Копа-аа-ать!!!

– Капай, капай. Өч көн инде капать иткәнгә. Ашайт плуха. Кушайть нада мнуга. Хлиб давай. Даже чучка нит бит...

Прохоров ачулы күзләре белән Гыйниятне тишәрлек итеп, куркытып карады. Аннан соң борын астыннан гына урысчалап сүгенеп китеп барды.

– Тагын килеп сүгенә башласа, казы әйдә дип, көрәк тоттырам әле мин аңарга.

Дәшми генә балчык ыргыткан Басыйр абзый кинәш бирде:

– Букка тисәң сасысы чыга, ди. Үртәмә син аны, бик начар кешегә охшаган. Күзе үлгән эт күзе кебек...

Килгәннәренә дүрт көн дигәндә алар окопларны казып, үзләре яшәргә тиешле блиндажларны ясап бетерделәр. Ике Су Арасы Гаяз алты блиндажның һәркайсына мич чыгарды. Аңарга бу эшендә Миңлебай, Сәйфулла һәм Сәләх ярдәм иттеләр. Кечкенә сапер көрәкләре белән балчык казыдылар. Үзләре ясап алган агач калыпларда кирпеч суктылар.

Урнашып бетеп, окопларга пулеметлар утыртылгач, берничә көн немецның килгәнен көтеп үтте. Миңлебай башкаларны көлдереп тә алды:

– Болай булгач, сугышта да яшәп була икән лә. Ашау байдан, үлем ходайдан, дигәндәй, нимес килергә дә уйламый ахрысы бу якка. Сугыш бетүгә симереп тә кайтырбыз әле...

Землянканың караңгы почмагыннан Гыйният өстәп куйды:

– Симерербез, Алла кушса, симерербез. Тик башны гына гәүдәдән аермасын. Шуны телик, егетләр!

Тагын ике көн узгач, аларның позициясен немецларның өч самолеты бомбага тотты. Алар очып килгәнче әллә нинди килбәтсез бер немец самолеты берничә тапкыр окоплар өстеннән, биектән очып әйләнгәләде. Солдатларның берсе, андый самолетны күргәне бар икән, аңлатма бирде:

– Рама, диләр аны. Разведчик самолет ул. Летчиклары икәү була. Эче тулы фотоаппаратлар, ди. Иртәгә көт тә тор бомбежканы.

Чыннан да, икенче көнне иртәнге ун-нар тирәсендә бомбага тоту башланды. Әллә каян, урман артыннан килеп чыккан өч самолет, кара тәреләр төшкән канатларын җәеп, окоплар өстеннән очып үтеп китте дә нәрсәдер онытткан кебек кире борылды. Очып, берсе артына берсе тезелеп окопларга якынлаштылар. Алдан барганы үкереп окопларга карап түбән ыргылды:

– Чукынды ахрысы бу нәрсә. Егылып төшә ахрысы, – диде окоп чигендә аякларын салындырып тәмәке төреп утырган Хаҗи Балак. – Безнең янга килеп кадала күрмәсен тагын.

Хаҗи янында, окоп эчендә басып торган Калиновка чуашы чукына ук башлады. Гыйният аңардан көлмичә булдыра алмады:

– Син, пелеш, чукынып котыла алмассың, дип уйлыйм мин. Бер дә булмаса, бисмилла әйтеп кара, ярдәме тиячәк.

Чуаш аңарга тиз генә карап алды да, чукынуын туктатмыйча, «бисмилланы» китереп өстәде:

– Әй, Христос Аллакайгынам! Писмилла иракман ираким гынам! Акүзе минашайтаным, писмиллам иракма-ным мине-ем...

Чуаш укып бетерә алмады, һавадан текә итеп төшеп килгән самолетның корсак астыннан тамчы кебек кенә бер нәрсә аерылды. Самолет коточкыч гүләп кинәт кенә борылып кире һавага югарырак күтәрелде. Шуны гына көткәндәй, аның артыннан икенче самолет аска ыргылды. Беренче самолет ташлаган тамчы зурайганнан-зурая барып, окоптагыларга якынлаша иде.

– Нәрсә ыргытты икән бу, әй? Теге немец пралитарларыннан безгә берәр бүләк микән әллә?

Шулчак окоп борылышыннан Габдрахман Акмалов йөгереп килеп чыкты:

– Ятыгыз тизрәк окоп төбенә. Бомба ыргыта бит алар.

Кабаланмый гына ята башладылар. Сәләх Учак, шинелен пычратудан куркып, ятканнар янында таптана башлады да нәрсәдер әйтергә дип авызын ачты... Шул мизгелдә аяк астындагы җир әллә кая читкә ыргылды, Сәләх мәтәлеп барып, окоп төбенә тәгәрәде...

Беренче самолет пикедән чыгуга аның урынына икенчесе килеп җитте, анысы китүгә – өченчесе. Төшкән берсе бер генә бомба ыргытып, тагын әйләнә тордылар. Җир күтәрелеп бәрелдә, окоп диварлары җимерелде, каты һава дулкыны колакларга китереп бәрде. Акырган, ыңгырашкан тавышлар күбәйде. Бомба шартлау күк күкрәүдән һәм яшен яшьнәүдән дә яман икән. Инде җир йөзендә синең гәүдәңә урын беткән. Тәннең һәрбер сөяге сыкрый һәм сөяк урыныннан чыгып ычкыныр кебек. Сулыш алырга һава җитми. Үзеннән-үзе, белгән, әллә нинди белеп тә бетермәгән, малай чакта өйрәнеп бетелмәгән, инде онытылып бетә язган догалар башка килә. Алар «бисмилла» белән катыштырылып укыла. Аллаһы Тәгаләдән ярлыкагыл сорала, башкача бер генә тамчы да гөнаһ эшләмәскә сүзләр бирелә. Җиргә сыенганнан-сыена барып, изгелек эшләргә мең төрле нәзерләр әйтелә. Уй-хисләр арасында тик изгелеккә юнәлгәннәре генә торып кала икән бомбалар шартлаганда.

Ярты сәгатькә якын дәвам иткән бомба ташлау аны беренче тапкыр күргән солдатларга мәңгелек булып тоелды. Самолетлар очып киткәч тә окоп эчләре тып-тын торды. Башта кузгалган кешеләр күренмәде. Аннан соң аз-маз тавышлар, ыңгырашулар ишетелә башлады. Тынлык булмаган, тик колаклар тонган икән...

Беренче тапкыр сугышта үтерелгәннәрне шул бомбага тотудан соң күрделәр зиреклебашлар. Унике кешенең өзгәләнгән канлы гәүдәләрен, төрле урыннарда яткан аяк-кулларын, ит кисәкләрен, балчык-комга буялган эчәк-бавырларын бер урынга җыйнап, бомба шартлаудан барлыкка килгән түгәрәк чокыр төбенә тутырдылар. Шуннан төрле шинель, брезент кисәкләре белән өсләрен яптылар да күмеп куйдылар. Кабер төбенә салынган гәүдәләр арасында күрше Хәлекәй авылының зур гәүдәле ике мишәре дә бар иде. Татарлар арасыннан яшькә иң өлкәне булган Гыймади Басыйры, кабер күмелеп бетеп, мылтыклардан атып салют биргәч, мөселманнарга калырга кушты. Куркынган сарыклар кебек бер урынга җыйналган якташларына моңсу гына карап алды:

– Шәһит киткән якташларыбызга ясин чыгып, дога кылыйк. Аллаһы Тәгалә чукынган урыс кулы астында сугышып вафат булган мөэмин мөселманнарыбызны җәннәткә кертсен.

Ул алгарак чыкты да моңлы мәкам белән укырга керешге:

– Әгүзү бил-ләһи минәш-шайтан ир–рәҗим, бисмил-ләһир-ахманир-рахим...

Каберлекне уратып алган дини тынлыкны бозып урысча сүгенү һәм аның артыннан ук яңгыратып акыру ишетелде:

– Туктатыгыз улавыгызны! Кем рөхсәт итте? Басыйр туктамыйча укуын дәвам итте.

– Прекрати-ить!..

Татарлар төркеменнән Гыйният белән Габдрахман Акмалов аерылып чыгып лейтенантка табан атладылар. Аларның кискен атлаулары күреп, Прохоров акырудан туктады да нигәдер артына борылып карады. Анда бер кеше дә юк иде.

Икәүләшеп лейтенантка якын ук килделәр. Урысчаны яхшы белгән Акмалов, эчке януын сиздермәскә тырышып, Прохоровка әйтте:

– Син кит инде моннан. Кабер өстендә кычкыру яхшы түгел.

– Бога нет. Прекратить!

– Сезнең Бог бәлки юктыр да, ә татар Алласы бар. Тизрәк кит исән чагында!

– Бу нәрсә, янаумы?

– Янау!

Лейтенант тагын авызын ача башлаган иде, Гыйният алга атлады:

– Иди атсуда, сабака два нага...

(Ахыры киләсе санда).

Муса Җәлил - чыганакларда

Халыкның зыялылыгын, үткән тарихының байлыгын, киләчәгенең төп таянычын шәхесләре аркылы таныйбыз. Шәхес – халык язмышының барометры. Менә инде озак еллар дәвамында халкыбызның затлы зыялыларын киң катлау укучыларга ирештерүне максат иткән «Шәхесләребез» сериясе шул изге бурычларын үтәп килә. Филология фәннәре докторы Рәмил Исламов әзерләгән «Муса Җәлил – документларда» фәнни популяр басмасы – «Җыен» фондының чираттагы тупланмасы.

Җыентыктагы төп дәлил: Бөек Ватан сугышына кадәрге документлар. Алар, нигездә, рәсми һәм шәхси хатлар, телеграммалар, гаризалар, финанс документларын, автографларын эченә ала. Икенче бүлектә әсирлек чоры документлары, өченче бүлектә аклау һәм хәзерге чор документлары, дүртенче бүлектә шагыйрьнең шәхси тормышына бәйле документлар тәкъдим ителгән. Болардан тыш китапның эчтәлеген баетуда М.Җәлилнең тормышы һәм эшчәнлеге хроникасы, 1968 елдан башлап тапшырылган Татарстан комсомолының Җәлил исемендәге дәүләт бүләге иясләрен (1990-1997 елларда әлеге бүләк бирелмичә тора) исемлеге һәм шагыйрьнең шактый тулы библиографиясе дә зур өлеш керткән. Төзүче-автор бу хезмәтләрне җентекләп барлаган һәм укучыга җиткерә алган. Гомумән, документларның кайсына гына мөрәҗәгать итсәк тә, без XX гасырның 20-30 нчы еллар вакыйгалары, әдәбият-сәнгатьнең торышы, анда барган процесска, шәхеснең формалашуына, эшчәнлегенә, мәдәни мохитнең эволюциясенә игътибар итми булдыра алмыйбыз. Җыентыкта урын алган беренчел чыганаклар шул яклары белән дә әһәмиятле.

М.Җәлилнең 1950-2006 еллар эчендә 3, 4, 5 томлыклары басылды. Истәлек-хатирәләр һәм башка җыентыклар, дөньяның бик күп телләренә тәрҗемә ителгән шигъри иҗаты дөнья күргән, фәнни хезмәтләр язылган, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланган. Бер караганда шагыйрь иҗаты төрле аспектта өйрәнелгән, тупланасы материаллар тупланган сыман. Ләкин без М.Җәлил иҗатын никадәр генә беләбез дисәк тә, әле һаман чыганаклар тикшерелеп, фәнни әйләнешкә кереп бетмәгән икән. Безгә заманында М.Җәлилнең 5 томлык басмасын әзерләүдә катнашырга туры килгән иде. Ашыгып эшләү, дөресрәге, шуңа мәҗбүр итү нәтиҗәсендә томнарны төзүчеләргә барлык чыганакларны барлау, томнарга кертү мөмкинчелеге чикле булды. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендәге материалларны барысын да карап чыгу, башка оешмалар белән эшләү өчен бик аз вакыт бирелгән иде шул. Төзүче-автор без эшли алмаганны тәэзтәкән. Ул Татарстан дәүләт архивына, Татарстан Милли музеена, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына, М.Җәлилнең Казандагы музей-йортына, М.Горький һәм Ф.Шаляпин музеена, Татарстан Милли китапханәсенә мөрәҗәгать итеп фәнни-популяр басма өчен шактый чыганак туплаган, аларны фәнни әйләнешкә керткән.

Рәмил әфәнде шагыйрьнең бренды исәпләнгән «Җырларым» шигыренең элеккеге СССРның 15 союздаш республикасы һәм Россиянең автономияле республикалары халыкларының 25 теленә тәрҗемәсен урнаштыруы да бик уңышлы гамәл.

Җыентыкка барлыгы 403 берәмлек документ тупланган. Аларның 265е беренче тапкыр тәкъдим ителгән. 41 чыганак төп нөсхәләре белән чагыштырылып, элекке басмаларда киткән хаталар, җитешсезлекләр төзәтелгән. Кызганыч, китапны күзәткәндә, күп кенә документларның төп нөсхәләре табылмау сәбәпле элеккечә кыскартылган вариантларда калган. Киләчәктә ул чыганаклар да табылыр, Җәлил иҗатын тикшерүчеләр аларны төзәтер, дип өметләник. Шагыйрь иҗаты үлемсез, ул татар халкының милли патриотизм символы. Нинди генә чыганак табылса да, М.Җәлилнең шәхесен дә, иҗатын да киңрәк, тирәнрәк аңларга, дөнья мәдәниятендә танытырга ярдәм итәр.

Чыганакларга күз салганда, рәсми документларның күпчелеге Татарстан дәүләт архивыннан алынган. Чынлыкта, документлар М.Җәлилнең 1939-1941 елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләгәндә язылып, шагыйрь имзасы белән төрле дәүләт оешмаларына җибәрелгән, яисә оешма җитәкчеләреннән М.Җәлил исеменә килгән рәсми хатлардан һәм башка эчтәлектәге документлардан гыйбарәт. Алар төрле: яшәү урыннарын яхшыртуны сораганнары, берлек эшен чагылдырганнары, шәхси төстә язылганнары, үтенеч белдергән язмалары һ.б.ларны эченә ала. Дөрес, чыганакларның һәммәсенә күзәтү ясау мөмкин түгел. Монда бер-ике документны гына искә алыйк. Мәсәлән, 1939 елның 29 июлендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 9 нчы санлы беркетмәнең күчермәсе нигезендә И.Сталинның 60 еллык юбилее уңаеннан әзерләнәчәк җыентык, аның ничә өлештән торачагы, нинди әсәрләр һәм кемнәр керәчәге хакында сүз бара. 1939 елның 11 августында М.Җәлилнең Татарстан өлкә комитеты секретаре Долотказин (Гали Гомәр улы



Долотказин (1901–1987) һәм Татарстан Халык комиссарлар Советы рәисе урынбасары Сөләймановка (Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллин (1905–1983) язган хатыннан, Г.Тукайның 25 еллык юбилеен уздыру, шагыйрь исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе, хөкүмәттән шул чараларны оештыруда ярдәм соравын күрәбез. Хәтта шагыйрь нинди генә авыр еллар, репрессияләр, милли кадрларга тискәре мөнәсәбәт сакланган бер дәвердә, язылу вакыты билгесез хатта (хаттан аңлашылганча, 1939 елга туры килә) партиянең Үзәк Комитеты, Сталинга милли язучыларны үстерү, аларга матди ярдәм күрсәтү, басылган әсәрләре өчен гонорар түләү, торак мәсьәләләрен яхшыртуны сорап язган рәсми хаты шул заман өчен зур батырлык үрнәге. Бу документлар барысы да укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителгән.

Җыентыкта М. Җәлилнең шәхси хатлары да шактый урын алган. Хатлар, нигездә, 1923 елның 11 июненнән 1942 елның 3 июненә кадәр чорда язылган. Эчтәлеге, максаты ягыннан хатларны ике төргә: шәхси һәм эшлекле хатларга бүләргә мөмкин. Хатларның күпчелеге Җәлил томлыкларында нәшер ителде, әлбәттә. Төзүче-автор аңлатмаларда чыганакларны җентекләп күрсәтеп барган. Җыентык шул ягы белән дә фәнни.

Хатлар – шәхеснең күңел көзгесе. Ул кешенең уен, җанын, хыялларын, теләк-омтылышларын, гомумән, эчке дөньясын ачып сала. Шагыйрьнең дә хатлары – күңел көзгесе. Алар, шәхси яисә эшлеклеме, чын күңелдән язылган. Шунысы ачык: шагыйрь хатлары никадәр генә садә язылмасын, аларда, үзе искә алганча, барыбер эш-гамәлләрен тасвирлауга кайтып кала, эчке кичерешләрен, уй-хисләрен бик күрсәтергә тырышмый. Күпчелек хатлар шундыйлар. Шагыйрьнең мәхәббәт хатлары сирәк очрый.

Хатлар аерым шәхесләрнең архивларында сакланган материаллар нигезендә тупланган. Шагыйрьнең якын дусларыннан берсе Гази Кашшаф, М.Җәлилнең васыяте буенча, шәхси архивны Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсенә тапшыра. М.Җәлилнең 3 томлык китабы шагыйрьнең шәхси архивы нигезендә төзелә. Г.Кашшафның шагыйрь хатыны Әминәгә язган хатыннан күренгәнчә, 3 нче томны төзегәндә хатларның аз булуы сәбәпле, китапның басылмау куркынычы туган. Шул мәсьәләнең кискен торуын әйтеп, Г.Кашшаф хатында «Для III тома не хватает писем Мусы. Здесь я гонюсь за Шамовым, Тинчуриным и др[угими], которые ищут без успеха. Ведь письма Мусы должны быть у Мухамедовой (Насима если сохранила их). Ее я разыщу. Жиганов все еще ничего не дал. Обещал Файзи – но пока ко мне не поступило. Вы побеспокойте его и Махмуда Максуда (он будет в Москве числа 10-го, обещал обязательно разыскать письма). Срок договора истек, а том не готов. По-видимому, кроме меня никто не сохранил письма Мусы», – дип яза. Бу аңлашыла да кебек: әле Сталин репрессияләренең аяныч нәтиҗәләре кеше аңыннан югалмавы, Мусаның фашист тоткыны булуы һәм аңа тискәре мөнәсәбәтнең саклануы - ул хатларны матбугатта чыгаруга киртә дә булгандыр. Җәлилнең соңгы томлыклары шәхси хатлары белән шактый тулыланып нәшер ителде.

М.Җәлил иҗаты, нигездә барланган кебек. Бары иҗаты... Ә шәхси документлары, барлык чыганаклар тикшерелгән дип әйтеп булмый. Югарыда кителгән Г.Кашшаф хатыннан өзек тә, җыентыкны төзүче Р.Исламовның кереш мәкаләсе дә бу фикерне раслый сыман. Ни өчен? Төзүче-автор кереш язмасында Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан бары егерме сигез хатның гына җыентыкка керүен һәм киләчәктә тупланманың тагын да тулыландырылган басмасы дөнья күрәчәгенә ышанычын белдерә. Ә аларны барлау өчен Мәскәү архивларында сакланган татар газета-журнал редакцияләренең документларына, шагыйрьнең Оренбург дәвере чыганакларына һ.б. оешмаларның материалларына мөрәҗәгать итү сорала. Шул очракта гына М.Җәлил шәхесен һәм иҗатын ачарлык документлар табылырга, фәнни әйләнешкә керә алуга мөмкин булачак. Димәк, киләчәктә М.Җәлил иҗатын тирәнрәк өйрәнергә теләүчеләргә әле юллар ачык.

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН.

Коркачыклар Сабан туена чакыра

Оныкларым үсмер чакларыннан башлап һәр җәйдә Иске Казанга барып кайта иде. Минем моңа кадәр әлеге урынны күргәнем булмады. Быел оныгым Зөләйха үзенең гаиләсе белән тагын шул тарихи җиргә барып кайтырга ниятләде. Бу сәяхәткә алар мине дә чакырды.

Көн аяз, җылы, җыендык та киттек. Андагы табигатьнең матурлыгына сокланып, шаккатым дисәм дә арттыру булмас, тау башында озак уйланып утырдым. Белгәннәр икән борынгы бабаларыбыз башкаланы кайда салырга! Андагы тәртипкә исең китәр – монда чүп-чар калдыру юк. Уңайлы тимер баскычтан Изге Камай мулласы чишмәсенә төшеп, шешәләргә су тутырып алдык, беседкага кереп тамак та ялгадык.

Камай авылында гаҗәеп очрашу булды: бер төркем яшьләр, бала-чага шау-гөр килеп, озын колгаларга сөлгеләр бәйләп, бизәкле чиләкләр тотып, Сабан туе бәйрәме өчен халыктан әйбер җыеп йөри. Без туктадык, машинадан төшеп, исәнләштек. Яшьләр урап алды. «Сабан туена килегез», – дип чакыралар, көлешәләр. Безнең кемнәр булуыбызны, кайсы авылдан икәнебезне сорашалар.

– Кая килергә, Сабан туе Камайда буламы? – дибез.

– Юк, Камайда түгел, Коркачыкта булачак, килегез, кунак булырсыз, – диләр.

Минем мондый тамашаны спектакльләрдә генә күргәнем бар иде. Оныгым белән кияүнең дә мондый бәйрәмне беренче күрүедер дип беләм. Кызганыч, Коркачык яшьләренең исемнәрен дә сорамаганбыз. Ярый әле оныгым фотога төшереп алган булып чыкты.

Кайсыдыр газетада: «Быел сабантуйлар өчен бюджетта акча каралмаган», – дигән сүзләр күзгә чалынган иде. Безнең татар үзенең традицион бәйрәмен үткәрми каламы соң?!

Рәхмәт сезгә, Коркачык милләттәшләрем! Барыгызны да олы бәйрәм белән тәбрик итәм!

Руфина ФӘТТАХОВА,
Татарстанның атказанган табибе.

●Байсар авылы «капкасы».

●Байсар урамы.

Удмурт иленең Кыяс районында да Байсар авылы бар, дигән хәбәрне ишеткәч тә, күңелдә ут кабынды. Үзем Актанышның Иске Байсарыннан бит, игезәк авылны барып күрмичә, тарихын ачыкламыйча ничек түзим инде?

УДМУРТИЯДӘГЕ

●«Бурт»ка бәрәңге салу. 1960 еллар.

●Байсар авылы үзешчәннәре. Уңнан беренче – Мәсхүдә Бәхтиева.

Кыяс кул сузымында гына булып чыкмады, аңа Кече Пурга аша урап барасы бар. Яган авылында елга аша күперне ремонтлыйлар, юллары да Татарстанныкы түгел, бара-бара шактый интегәсе. Байсар авылы Карамас-Пельга җирлегенә буйсынып яши икән, анысына Кыястан соң гомумән асфальт юл юк. Әле Пельганың үзендә дә күпер торгызалар, авыл тыкрыклары аша урап үтми булмый. Әмма юл буена күңелгә салып бардым: удмуртлар ягы булса да, бу тарафта Байҗегет, Көчек, Аксар, Атабай, Килдебай кебек татар исемнәрен йөртүче авыллар байтак кына икән...

Күңел сизүедер: гравий түшәлгән юлдан тузан туздырып барышлый ук Байсар авылын шундук танып алдым. Һәрбер ихатасы саен шау чәчәккә күмелгән алма, чия, шомырт агачлары, һәр хуҗалык артында кибән-кибән итеп өелгән каен утыннары. Койма-капкалар кичә генә төзегәндәй таза, тәрәзә йөзлекләре, фронтон челтәрләре килен төшерергә әзерләнгән кияү йорты сыман, җете төстәге буяулар белән матурланган. Юк, күпме генә күкрәк сукмасыннар, без – ил төзүче халык, дип тамак ярмасыннар, өлкән агай болай җиткелекле, болай чиста итеп яши белми инде!..

Авылның нәкъ уртасындагы бер йорт бакчасында сөйкемле, ачык йөзле ханым чәчәк түтәлләренә су сибеп йөри. Коймага якынаеп сәлам бирүемә үк, ул коелып төште:

– Аһ, бигрәк килешсез чагымны туры китердегез, кешечә яулык ябып каршыларга да өлгерә алмый калдым!..

Бик тиз аңлашылды. Әле юлга чыкканчы ук, бу Байсарның авыл клубы мөдире Мәсхүдә ханым Бәхтиева белән бәйләнешкә кергән идем, ә татарда сер юк, минем киләчәкне авылның һәр кешесе белеп тора икән!..

Бакчачы хуҗабикә: «Сезне Мәсхүдә клубта көтә», – дигәч тә, шул якка юнәлдем. Кай арададыр тагын бер «авылдаш» ханым иярде. Ишек ачып керсәк, клуб эченә коймак исе таралган: Мәсхүдә белән тагын бер иптәше мөсафирны чәй өстәле белән көтеп тора икән!..

Клубның кечкенә бер бүлмәсендә музей шикеллерәк мирасханә ясалган, аңа өлкән авылдашлары калдырган хатирә һәм истәлек язмалары тупланган. Берникадәр актарынуга һәм «авылдашлар» хатирәсен тыңлауга ук, Байсар авылының тарихы күз алдына басты.

Авыл 1929 елда Әгерҗе районындагы Акхуҗа авылыннан бүленеп чыккан. Акхуҗа ирләренең әле революциягә кадәр үк Карамас-Пельга белән Унур-Кыясово (татарлар аңа «Очкыр» атлы үз исемен кушкан) авыллары янәшәсендә дә имана җирләре булган икән, барып йөрергә ерак дигән сылтау белән генә аңа тимәгәннәр. Әмма инде атлар, сыер-сарыкларыңны талап, колхозга куып кертү, каршы төшәсең икән, кулакка чыгарып, Себергә олактыру дигән хәвеф-дәһшәт өргән замана бит. Әнә шул Себергә сөрелүдән котылу һәм имана җирен дә саклап калу өчен, Акхуҗаның Нуретдин, Хөснетдин, Фәрахша, бертуган Шакир һәм Нури Бакировлар, Бәхти Җәмилев, Хаҗиәхмәт, Фәерша, Галләм Габдрахманов, Лотфулла атлы 10 ире җигүле атлары белән Очкыр янындагы басуга күчеп килә. Эшне, әлбәттә, тирәлекне агачлардан арындырып, ышна җире ачудан башлыйлар. Булачак авылга терәлеп торган чишмә белән буаны үз кулларына эләктерү өчен, Очкыр крестьяннарына түбәнлеккә урнашкан кырны биреп килешәләр. Бүрәнәләрдән тәүге йортлар тергезү, ат һәм сыерлар өчен күмәк лапаслар төзү башлана. Бераздан инде Акхуҗада калган хатыннарын һәм балаларын да монда күчерәләр. Авылның гына һаман бер исеме дә юк. Әртилләр төзү, чәчүлек орлык табу турында сүз башлангач, араларындагы Галләм агайны Сөн елгасы буена сәфәргә озаталар. Ә ул волость үзәге булып торган Иске Байсарга килеп җитә дә дүрт мәчетле авылның төзеклеген, матурлыгын күреп шакката. Кайткач, шушы Галләм агай тәкъдиме буенча, яңа авылга да Байсар дип исем кушалар. Ике республикада урнашкан ике Байсар авылының элемтәсе менә шушы гына...

Ә ил кузласына утырган Сталинның үз чыбыркысы. Әлеге байсарлылар да 1932 елда Карамас-Пельга белән Мушак авыллары уртасында әртил төзеп куя, аны «Кызыл Байрак» дип исемлиләр. Акхуҗадан Нургали, Фазлетдин агайлар, Җәмилев һәм Тимершин фамилияле ике Миннәхмәт гаиләләре килеп өстәлә, әртилчеләр саны 16 га җитә. Әүвәл Фатыйх атлы крестьянны рәис итеп сайлыйлар, ләкин бер кешене генә райком кыздырган утлы таба өстендә шактый куркыткандыр, бераздан аны Нури, Сәлимулла, Хаҗиәхмәт агай алыштыра. 1935 елда сабыйлар өчен мәктәп бинасы да ачып

●Авылга нигез салучы гаиләләрнең берсе – Бәхти Җәмилев һәм Зарифә.

●Авыл хатыннары кибет янында. 1950 еллар.

ТАТАР АВЫЛЛАРЫ

●Авылның «аяклы тарихлары» Канифә Мәрдәнова, Әнисә Хәйбуллина һәм «Ак әби» Сания Хаҗиева.



●Тауҗамал авылы мәчете.

җибәрәләр, аңа хуҗа булып Гарифулла Рәхмәтуллин атлы ир-ат килә. Шул елда ук бәләкәй генә булса да кибет ачыла. Элеккечә, әле барысы да Әгерҗе районына буйсынып, «тулы хокуклы» татар булып яшиләр бит, 1936 елгы сайлауларда да Көчек авылына барып тавыш бирәләр. Ләкин 1939 ел кергәндә, нинди галәмәттәндер ике республика чикләрен өр-яңадан билгелиләр дә, Байсар белән Тауҗамал атлы ике татар авылын Удмуртиягә бүлеп калдыралар...

1941 елда бәләкәй генә шушы Байсар Бөек Ватан сугышына 25 ир-егет озата, яртысы диярлек яу кырыннан әйләнеп кайта алмый. Ә ирсез торып калган авыл хатыннары һәм яшүсмер кызлар Балезино станциясендәге тимер юл төзелешенә йә Пижел станциясе янындагы урманга, самолетлар төзү өчен яраклы карагай-нарат агачларын кисәргә йөри. Агач тачкалар белән балчык ташып тимер юл платформасын төзегән яки салкын, юеш babаракларда төн куна-куна йөзьяшәр наратлар аударган кызларга атнасына 3-4 килограмм чамасы он өләшәләр. Чәчүлек орлыкны көзен Әгерҗе йә Кыяска, язын аннан ташып интеккән хатыннарга өч кило чамасы яртылаш черек бәрәңге эләгә. Әле шул мәсәргән он белән черек бәрәңгене дә үзең ашый алмыйсың, туган йортта сабый балалар, эне-сеңелләр көтә... Чигенерлек, үкереп еларлык та түгел: ирләре фронтка киткән Тайфә, Минҗамал апалар гаиләсендә – бишәр, Бәдриҗамал, Шәмсенур, Минҗамал, Фатыйма, Шәмсеҗамал атлы хатыннар өендә өчәр ярым ятим үсә... Ни кызганыч, ул сабыйларның байтагы Касыйм, Сәетгәрәй, Кәрами, Мөсәвир... атлы әтиләрен көтеп җиткерә алмый. Күпчелек сабыйларны укырга-язарга өйрәткән мөгаллимнәре Гарифулла Рәхмәтуллин да сугышта байсарлылардан иң соңгы кеше булып, 1945 елның 4 маенда һәлак була...

Тик... яшәргә кирәк! Яу кырында исән калган ирләр кайтып өстәлгәч, Байсар хуҗалыгында ат, сыер, сарык, тавык фермалары ачып җибәрәләр. 1950 еллар башында Байсарны, аерым бригада итеп, Петропавловский, Калиновский, Зайчиково, Унур-Кыясово авылларыннан хасил «Победа» колхозына кушып куялар. 1958 елда инде Байсар бригадасы, беркемнән дә сорап тормыйча гына, Карамас-Пельгадагы «40 лет Октября» колхозына күчерелә, ярый әле, шул чакта авыл читендә алма бакчасы утыртып өлгерәләр. 1963 елда Байсар инде «Ленинец» колхозы составында йөри... Аңлашыла булыр, бай өстәленнән читтәгегә сынык-санак кына кала...

Ходайга мең шөкер, байсарлылар сынмаган, бирешмәгән. 1946 елда авылда 120 кеше гомер итсә, бүген барыбер 28 хуҗалыкта 64 кеше яшәп ята әле. Депутатларны якасыннан эләктереп булса да, соңгы елларда йортларына газ һәм су кертүгә ирешкәннәр. Хуҗалыклары хәтта Татарстандагы байтак авылларны да көнләштерерлек дәрәҗәдә иркен һәм бай. Иң мөһиме: алар үз басуларына бернинди инвестор-талаучы да кертмәгән (Республика җитәкчеләре тарафыннан Марий Элнең Звенигово ит комбинатына сатып җибәрелгән бөек (!) Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмәнең ачы язмышы белән чагыштырып карагыз).

Мөгаен, бүген әлеге Байсар үзеннән 7-8 чакрымдагы Тауҗамал авылы хәерхаклыгы белән дә көн күрәдер. Тауҗамал үзе – тарихта бик күптәннән билгеле һәм данлыклы авыл. Аның 1 нче «башкорт» кантонының 24 нче йортына кергән ирләре әле 1812 елгы Ватан сугышы чорында ук барча Европа буенча яу йөргән, Әгерҗедәге Исәнбай авылы есаулы Габделлатыйф Карабай улы Тутаев кул астында Парижны алуда катнашкан. Тауҗамал Әби патша – Екатерина II проектлары буенча төзелгән авылдыр, янгын йорттан-йортка сикерә алмасын өчен, аның урамнары гаҗәеп киң, ә авылны берничә урында киң тыкрыклар кишәрлеккә бүлә. Авыл бүген дә зур, матур, төзек. Мәчете – күз явын алып, үзенә тартып тора. Тауҗамалның болай күркәм сакланышында шушы авылның уңган ир-егете Фердинанд Мәҗитовның да зур өлеше бардыр. Күмәк хуҗалыклар 90 нчы елларда ук таралып бетсә дә, шушы Ф.Мәҗитов зур агрофирма оештыруга ирешкән, аның савымчылык фермалары Тауҗамал, Мушак һәм Байсар авыллары буйлап таралган, бүген шулар авыл халкын эш урыны һәм хезмәт хакы белән тәэмин итә. Фердинандның меңәрләгән гектар чәчүлекләре дә, ашлык складлары, комбикорм әзерләүче цехлары да бар. Бүген Сабантуй бәйрәмнәрен дә нәкъ шул оештыра. Тауҗамал һәм Байсар яшьләренең күңел ачуын тамаша кылу теләге белән барсам да, ни кызганыч, таң алдыннан кузгалган дәһшәтле яңгыр халык бәйрәмен уздырырга мөмкинлек бирмәде, мондый хыял киләчәккә калды.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Безнең хәтер

Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә өч көн дәвамында Идел буе Болгарында рәсми рәвештә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу һәм Касыйм шәһәренең – 870, Касыйм ханлыгына нигез салынуның 570 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан “Безнең хәтер нурдан тукылган” дигән зур чара булып узды. Аның беренче көнендә Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшли торган “Татарстан төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте”нең мөселман дөньясында бердәнбер хатын-кыз казыя булган Мөхлисә Бубый истәлегенә багышланган фәнни-гамәли конференциясе узды. Икенче көнне исә татар халкы өчен гаять зур вакыйгага булды – шәһәрнең Хан мәчете каршында, Шаһгали хан төрбәсе белән янәшә диярлек урнашкан, Сөембикә исеме белән аталган шәһәр бакчасы янындагы мәйданда Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл куелды.

Гыйльми җыен Мөхлисә Бубый истәлегенә багышланса да, конференциядә нигездә чыгышлар Россия мөселманнарының, аерым алганда татарларның тарихи хәтерен саклау мәсьәләләре күтәрелде. Шуңа да сүзне Касыйм ханлыгы тарихыннан башлау кирәктер.

Язучы, тарихчы-галим Нурулла Гариф бәян иткәнчә, Касыйм (Касыйм ханлыгының беренче ханы) һәм Мәхмүт (Казан ханы) – Олуг Мөхәммәднең уллары. Алар икесе дә Казан ханлыгына нигез салучылар булып исәпләнә. Олуг Мөхәммәд Белев шәһәре янында рус патшасы Василийның 40 меңлек армиясен үзенең өч мең хәрбидән торган гаскәре белән җиңә һәм аның үзен дә әсирлеккә төшерә. Шуннан соң руслар үз патшаларын 200 мең алтын тәңкәгә сатып алырга мәҗбүр була. Шул ук вакытта Алтын Урда чорында татарлар яшәгән җирләрне – Мещера шәһәрлеге буларак мәгълүм төбәкне Олуг Мөхәммәднең улы Касыймга тапшыралар. “Касыймның алга киткән сәясәтче булуы билгеле. Руслар исә Касыйм ханлыгы аша Казанга йогынты ясарга ниятли”, – ди Н.Гариф. Алар моның өчен Урда ханы тәхетендә утырган чыңгызыйларны йөгәндә тотып, үз тәрбияләрендә үскән чыңгызыйларны башка татар дәүләтләренә күчерү хәйләсен планлаштыра һәм уйлаганнарына ирешә дә. Әйтик, алар күп тапкыр Касыйм ханнарын һәм аларның балаларын, оныкларын Казан ханлыгына куя. Әйтик, Шаһгали Казан ханлыгы тәхетенә өч тапкыр утыра. Шул сәбәпле Казанда ике партия барлыкка килә. Аның берсе – Мәскәү, икенчесе Кырым яклы була. Бу тарафта – Сафагәрәйләр династиясе, шулай ук нугай бәкләре. Ике як та үз йогынтысын көчәйтү өчен көрәшә. Шунысы аяныч: Казан ханлыгы нибары 100 ел гына яши. Шул вакыт эчендә анда 13 хан алмашына, алар арасында тәхеттә – бер-ике, өч-дүрт ел, күп дигәндә, ун ел утыручылар бар. Ә Мәскәүдә бу елларда нибары өч падишаһның идарә итүе мәгълүм. Казанныкында ханнар алмашынган саен вәзгыять тә үзгәрә. Аларның һәркайсы тәхеткә үз кешеләрен алып килә. Ә аларга туенырга җир кирәк. Моның өчен кемнедер читкә этәрәләр, җирләрен хан яраннарына бирәләр. Биләмәләре тартып алынганнарда ачу-нәфрәт куба. Шуңа Казан ханлыгында низаглар бик еш кабатлана башлый. Ул вакытта Исмәгыйль бәкнең үзенә зур бүләкләр белән килгән руслар белән әшнәләнүе, Мәскәүгә тугрылыгы, Казан вә Әстерхан ханлыкларын бәладә калдыруы, бертуган агасының да җанын кыеп, тәхеткә утыруы да зур канәгатьсезлек тудыра, гомуми тотрыксызлыкка сәбәп була.

Нугай бәге Йосыф морзаның кызы Сөембикә Казан тәхетендә утырган Җангалигә (Касыйм ханы Шаһгалинең энесе), аннары аның вафатыннан соң Сафагәрәйгә кияүгә бирелә. Ул 1549 елда бик сәер рәвештә бу дөньядан үтә. Аннан Сөембикә белән Сафагәрәйнең олы шатлыгы булып дөньяга килгән ике яшьлек Үтәмешгәрәй кала. Ул әле бик яшь булганга, аның урынына әнисе Сөембикә идарә итә. Казанлылар ханбикәне ярата. Ә ул, белгәнебезчә, Кырым партиясеннән. Руслар үз кешеләрен урнаштырырга теләп, монда яу белән килә һәм тау ягын яулап алуга ирешә. Казан ханлыгына куркыныч яный, әмма ул әле сугышка әзер түгел, көче җитми, ирексездән солых төзергә мәҗбүр була. Сөембикә, шәһәрдә җимерүләр һәм кан коюлар булмасын өчен, дүрт яшьлек улы Үтәмешгәрәй белән Явыз Иван гаскәрләре камап алган Казаннан Мәскәүгә әсирлеккә китәргә дигән капитуляция шартларын кабул итәргә мәҗбүр була. Шуның белән Казан ханлыгының гомере ике-өч елга озынайтыла.

Сөембикәне улы Үтәмешгәрәй белән көймәгә утыртып Мәскәүгә алып китәләр. Аның шул вакытта, миңа кечкенә генә бер олыс бирсәләр, тыныч кына яшәр идем, нишләп алар мине шундый хәлгә төшерәләр икән, дип ачырганалып елавы документта да теркәлеп калган. Ханбикәне Казансу елгасының ике ярына чыгып тезелешеп баскан халык та елап озата.Сөембикә Мәскәүдә Иван IV нең шәхси дошманына әверелә, патша аны ике ел буе беркая да чыгармыйча тота, аннары 1553 елда Касыйм ханы Шаһгалигә – беренче ире Җангалинең бертуганына ирексезләп кияүгә бирә. Сөембикә кыска аяклы, хатын-кыз чырайлы, тәрбиясез, руслар кушканны гына үти торган бу ирне яратмый. Ханбикәнең Касыймда ничек гомер итүе турында мәгълүматлар бик аз. Чыганаклардан күренгәнчә: биредә дә аңа халык хәерхаһлы булган. Әмма аның Мәскәүдә калган бердәнбер улы Үтәмешгәрәе өчен өзгәләнеп яшәвен, аның чукындырылганы, Александр дип исем кушулары турында хәбәр килеп ирешкәч, ничек сыкранганын, әрнегәнен күз алдына китерүе авыр түгел. Әмма Сөембикә буйсынмый. Ул горур булып, әмма сулып-саргаеп 1557 елда бу дөньядан үтә. Аңа ул вакытта әле 40 яшь тә тулмаган була. Ханбикәнең вафатыннан соң да аңардан үч алу дәвам итә, исемен дә оныттырырга телиләр. Бүген Сөембикәнең кабере дә билгеле түгеллеген башкача аңлатып булмый. Әмма аның исемен гасырлар тузаны күмә алмый, халкыбыз аны онытмый.

Сөембикәнең кабере Касыйм шәһәрендә Шаһгали җирләнгән тәкыядә (мавзолей) булырга мөмкин, дип уйланыла. Элеккерәк елларда Хан мәчетеннән ерак түгел урнашкан тәкыянең эченә кереп караган галимнәр аның ике катлы икәнлеген, аскысында сигез кабер барлыгын, берсе исемсез булуын әйтәләр. Тәкыянең өске ягына куелган кабер ташлары, гасырлар узган саен, ватыла, уала, аларны яңарталар. Хәтта Шаһгали каберенең плитәсен ачканда, ул төшеп китә, ханның сөякләрен дә вата. Моны махсус эшләгәннәр дип, судка да бирмәкче булалар. “Әлбәттә, без Сөембикәнең монда икәнлеген тәгаен генә белмибез. Чөнки ул сигез кабергә ДНК анализы ясалмаган”, – диде Н.Гариф. Сөембикәнең улы Александр Сафагәрәй улы исә Мәскәү зиратында явыз Иван белән янәшә ята.

Касыйм шәһәрендә ханбикәбез Сөембикәгә һәйкәлне ачу тантанасы җомга көнгә туры китерелгән иде. Шулай да күңелдә сораулар туа тора. Проектын мәшһүр сынчы Камил Муллашев эшләгән Сөембикә сыны нигә Казанда урын тапмады соң? Күңелләребезгә хуш килерлек, Сөембикә образын тулы чагылдырган һәйкәл булырга тиеш иде ул. Аннары мөселман кешесенә һәйкәл кую дөресме икән? Сыннарның ислам динендә ярамаган эш икәнен искәртеп торучылар хәтсез ләбаса. Соңгы соравыма җавап та тиз табылды. Россия Диния нәзарәте рәисе

● А.Борһанов төбәк тарихын өйрәнүчеләр – Минзифа Әхмәтшина һәм Энже Даутованы бүләкләде.

нурдан тукылган

урынбасары, Мәскәү Ислам университеты ректоры Дамир Мөхетдинов ул кешеләрнең Каһирәдәге “Әл-Әзһәр” университеты галимнәренең фәтваларын белмәвен әйтте. Алар күренекле шәхесләргә һәйкәлләр куюны күптән рөхсәт иткән. Бәйрәм тантанасы барышында Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин дә Сөембикә һәйкәле – зур батырлык, намуслылык символы, фән һәм сәнгать яклы хатын-кызга, шулай ук ул үз халкына тугрылыкка, аның киләчәге өчен үз тормышын корбан итәргә әзер торуга куелган һәйкәл икәнлеген ассызыклап үтте.

Бәйрәм тантанасы Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Коръән сүрәләрен укуы белән ачылды. Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев Касыйм шәһәрендә Сөембикәгә һәйкәл ачу халыкның күптәнге хыялы булуын, сынның бердәмлек билгесен гәүдәләндерүен әйтте. Камил хәзрәт Сәмигуллин да ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулу илнең барлык мөселманнарын берләштерүгә сәбәп булырына өметләнүен белдерде.

●Касыймдагы Ханнар мәчете.

Ука (Ока) елгасы буендагы Касыйм җирендә Сөембикәгә һәйкәл кую мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдин җитәкчелегендә оештырылган. Төп тәкъдим исә Рязань өлкәсе һәм Касыйм шәһәре татарларының милли-мәдәни төбәк автономиясе рәисе, үз туган ягын, халкын ихластан яратучы, Касыймда яшәгән татарларны берләштерүче Илдар Бикуев тарафыннан ясалган. Ул фикердәшләр табып, халыкның фатихасы һәм Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән бу эшне 7 ел элек башлап җибәргән. «Илдар Бикуев булдыклы, иҗади, кешеләр белән һәрвакыт уртак тел табып эшли алуына карамастан, тыйнак булып кала», – диде В.Шәйхразиев һәм аны көчле алкышлар астында һәйкәл янына, мөхтәрәм кунаклар янәшәсенә чакырып чыгарды. Һәйкәл ачу тантанасында кунакларны шулай ук РФ Дәүләт Думасы депутаты, Россия Герое Андрей Красов, Рязань өлкәсе хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары Анна Рослякова, РФ Дәүләт Думасы депутаты, «Татар федераль милли-мәдәни автономиясе» советы рәисе Илдар Гыйльметдинов сәламләде.

Тәбрикләү чыгышларыннан соң һәйкәл өстендәге япма тантаналы рәвештә ачылды. Бер кулын күкрәгенә куйган ханбикә йөзендә горурлык та, сагыш та, борчылу да һәм үз халкын ярату да чагыла. Өч метр биеклектәге һәм 1,5 тонна авырлыктагы Сөембикә сыны Петербург остаханәләрендә бронзадан коелган. Һәйкәл 5 метр биеклектә: гранит постаменттан һәм 3 метрлы бронза сыннан гыйбарәт. Һәйкәл скверның үзәгендә сигез почмаклы йолдыз рәвешендә ясалган ике катлы пьедесталга, аның өстендәге ике метрлы гранит постаментка куелган. Һәйкәл әйләнәсенә яшькелт-сары таштан ярымай эшләнгән. Сын – Әлфия Рәхмәтуллина, Вениамин Сидоренко, Андрей Губкодан торган иҗат төркеменең хезмәте.

Һәйкәл ачу тантанасыннан соң дин әһелләре һәм мөхтәрәм кунаклар Хан мәчетенә юнәлде, биредә Сөембикә рухына Коръән сүрәләре багышланды. Равил хәзрәт Гайнетдин җомга вәгазен сөйләгәннән соң, намаз укылды.

Сөембикә сыны куелган Касыйм шәһәре беркайчан да, милли һәм дини карашлардан чыгып, яулап алулар, капма-каршылыклы хәлләр кичермәгән. Шәһәр тарихы исә нәкъ менә ике диннең үзара аңлашып яшәвенең шаһиты. Касыйм һәм Казан арасында һәрвакыт үзенчәлекле мөнәсәбәтләр булган, ул хәзер дә шулай. Чөнки бу шәһәр ул озак вакытлар дәвамында татарларны, мөселманнарны Россия дәүләте эчендә күрсәткән. Кайчандыр шәһәрдә, әлбәттә, мөселман тормышы кайнап торгандыр. Бүген инде Касыймда ул көннәрдән Кадыйргали бәк тарафыннан XVI гасыр урталарында салынган Хан мәчетенең бары тик таш манарасы гына сакланып калган, аны яңартканнар. Шәһәрдә хәзерге вакытта ике мәчет эшләп тора.1808 елда нигез салынган Кастров мәдрәсәсе бинасында төбәкне өйрәнүче Әхмәт Ишимбаев исемендәге Татар мәдәният һәм сәнгать үзәге урнашкан. Аның иркен бүлмәләрендә татар мәдәниятенә кагылышлы ядкәрләр дә шактый. Бүген 32 меңләп кеше яши торган шәһәрдә нибары 1-2 мең генә татар гомер кичерә. Әлбәттә, катнаш никахлар шактый. Элек биредә татар тормышы гөрләп торуын шәһәрдәге Татар урамы, Татар тавы атамалары гына искә төшерә. Касыйм шәһәреннән ерак түгел урында чиста татар авыллары бар. Күп кенә милли-дини бәйрәмнәребез Әхмәт, Подлипки авылларында үтә. “Монда татарлар, руслар һәрвакыт дустанә мөнәсәбәтләрдә яшәдек, беркайчан да низаглар чыкканын хәтерләмибез”, – дип сөйләде Наталья Черенкова.

●Шаһгали тәкыясе.

Шәһәрнең Туган якны өйрәнү музеенда кунаклар игътибарына “ Касыйм татарларының рухи тормышы” дигән күргәзмә әзерләнгән иде. Татар мәдәнияте, мәгарифе турында мәгълүмат бирә торган экспозициядә бу якларда яшәгән милләттәшләребез тарихына бәйле ядкәрләр – Коръән савытлары, хаҗ кылучы жетоны, чапан, Касыйм патшабикәсе Фатыйма солтанның агачтан кәнәфигә охшатып эшләнгән урындыгы һ.б. куелган.

Тарихчы-археолог Альберт Борһанов Касыйм элекке Мещера шәһәрчегенең шул заман атамаларын йөрткән кала буларак кызыклы булуын искәртте. “Бу исә этнотуризмны үстерергә мөмкинлек ача, Касыймны «Татар-тур» маршрутына да кертергә булыр иде», – диде ул.

Профессор шулай ук Касыймдагы археология, архитектура һәйкәлләрен, кабер ташларын өйрәнүне көчәйтергә тәкъдим итте. Бу эшкә дәүләт структуралары һәм җәмәгатьчелек тә кушылуы мөһим. Күренекле шәхесләрне өйрәнү дә туризмны үстерүдә роль уйный, дип исәпли тарихчы.

Кичке якта Касыйм шәһәре мәдәният сараенда “Безнең хәтер нурдан тукылган” проектын концерт программасы дәвам итте. Кунаклар биредә дә иң әүвәл Алабуга дәүләт-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы фондларыннан “Безне гасырлар аша Сөембикә дәшә” темасына ядкәрләр, рәссам-каллиграф Гөлназ-Исмәгыйлева-Гатиятуллинаның “Мирас көче” дигән шәмаилләр күргәзмәләре белән таныштты.

Һәйкәлне ачу тантанасы һәм концерт программасы “Казан нуры” халык уен кораллары оркестры, Бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреатлары Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Илнар Шәрәфетдинов, Татарстанның атказанган артисты Алинә Шәрипҗанова башкаруындагы Сөембикәгә багышланган җырлар, мөнәҗәтләр, Даһстан республикасының “Айланай” дәүләт нугай фольклор-этнография ансамбле чыгышлары белән үрелеп барды. Әмма, гадәттә, мондый чараларның ахырында күмәкләп башкарылган “Туган тел” җыры яңгыравына күнеккән тамашачы концертның русча җыр белән тәмамлануына гаҗәпләнде.

Концертны Айзилә Батырханова һәм Илдар Кыямов алып барды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Гаяз ИСХАКЫЙ:
Зәки Вәлиди кемдер?

(Дәвамы. Башы 22 нче санда).

Оренбург губерна шәһәрен мәркәз ясарга теләгәннәреннән, Оренбургтагы берлек тарафдарлары төрек-татарлар бәхәсләшергә башлады. Оренбургның җәмәгать хезмәтчеләрен һәм Идел буеның бөек мөхәррирләрен – «Вакыт» гәзитәсенең баш мөхәррире Фатих әфәнде Кәримине вә аның туганы, Милли Идарә әгъзасы Гариф Кәримине [Гариф Мөхәммәдгариф Гыйльман улы Кәрими (Кәримев) (1892 –1934), җәмәгать эшлеклесе, публицист, татар милли хәрәкәтендә актив катнаша. Г.Исхакый бу урында Г.Кәриминең большевиклар тарафыннан кулга алынуын искә төшерә. Чынлыкта Г.Кәрими, 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң Төркестан якларына китеп, Бохарада Идел-Урал һәм Төркестан милли берлеге багланышын төзи. Большевиклар хөкүмәт башына килгәч, яшерен «Төркестан милли мәркәзе»ндә эшли. Бу милли мәркәз 1919 елда гомум төрек-татар, башкорт берлеге хәрәкәте исемен ала. 1921 елда большевиклар Гарифны кулга алып, үлем җәзасына хөкем итсәләр дә, ул кача, яңадан басмачылар хәрәкәтенә кушыла] җәзага хөкем иттеләр. Фәкать бу хәбәрне [ишеткәч] Оренбургның берлек тарафында булган гаскәри идарә (төрек-татар гаскәри шурасы) Зәки Вәлидине кулга алды (Г.Исхакый бу урында З.Вәлиди һәм аның җиде иптәшенең 1918 елның 3 февралендә Оренбургта большевиклар тарафыннан кулга алыну вакыйгасын искә ала кебек. З.Вәлидинең «Хатирәләр» дигән китабында Г.Исхакыйның фикерен раслаган түбәндәге юллар бар. Ул «Каладагы мөселман хәрби комитетының таләбе буенча алар тарафыннан кулга алынган башкортларны совет төрмәсенә бикләргә рөхсәт бирелде» дигән язу бирүен әйтә. Кулга алучылар татар солдатлары булуын да искәртә). Һәм аның туплаган биш-ун кызыл гаскәре таратылды. Шәриф Манатов Петербургка качты…

Бу дәвердә большевиклар Мәскәү һәм Петербургта Россиянең идарәсе кулына күчкәннән Шәриф Манатов рәсми яктан большевиклар белән эшли башлады. Фәкать Идел буе төрек-татар полклары, большевик тарафыннан чыкканнан соң, үзләренең бабаларының мәмләкәте – Казан, Әстерхан ханлыкларында автономияле бер төрек-татар идарәсе төзү белән мәшгуль булганлыктан, Идел буена сузылган бер дәвер большевик афәтеннән бәйсез калды. 1917 елның ахырында Уфа шәһәрендә бөтен Идел буе (Идел-Урал) төрек-татарының Милләт Мәҗлесе тупланыу (1917 елның 20 ноябрендә Уфа шәһәрендә Милләт Мәҗлесенең җыелышы башлана. Иске стиль белән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр дәвам итә) һәм монда милли-мәдәни мохтариятның кануннарын эшләр өчен автономияле Идел-Урал җөмһүрияте тәшкил итәчәк (Г.Исхакый бу урында Милләт Мәҗлесенең 1918 елгы 2 гыйнвар утырышында каралган Идел-Урал Штатының икенче проекты турында сүз алып бара) махсус нигезгә корылган бер комиссия аерылды. З.Вәлиди, төрмәдән чыкканнан соң, Оренбургта икенче бер корылтай туплау ниятенә кереште (1917 елның 20 декабреннән 1918 елның 4 гыйнварына кадәр Оренбургта Башкортстан автономиясенең икенче корылтае эшли). Фәкать корылтайга килгәннәрнең шактый өлеше, корылтайны ташлап, Уфада сөйләшүләр белән мәшгуль булган Милләт Мәҗлесенә чакырылды вә үзләренең һичбер мөнәсәбәттә аерылу фикерендә булмаганлыкларын сөйләде. Һәм аерым хәрәкәтләргә дошманлык күрсәтте. Боларның аркасында З.Вәлиди әфәнде үзе дә, Уфага килеп: «Минем башкортларны аерырга ниятем юктыр. Фәкать башкортларның күпчелеге бер төркем [мөрәҗәгать] укыды. Һәм үзен Милләт Мәҗлесенә кабул иттерде. Милләт Мәҗлесе күңеле белән бу иптәшкә каршы бөек бер нәфрәт хисен нығыткан хәлдә булганга, явыз нияте булмасын дип, З.Вәлиди әфәндегә Милләт Мәҗлесенең карарыннан чыкмаячагы шартын кабул итәчәген сөйләде. Фәкать аны һичбер җаваплы урынга сайламады. Бу дәвердә Оренбургта Урал казачийлары, Россиядә патша чоры идарәсен үзенә кайтарыр өчен, хәрәкәт итәргә башлады. Боларның рәисләре генерал Дутов исемендә (Александр Ильич Дутов (1879 – 1922), Оренбург казаклары атаманы, 1919 елдан генерал-лейтенант. 1917 елның мартыннан Бөтенроссия казак гаскәрләренең рәисе итеп сайлана. Шул ук елның сентябреннән Оренбург казаклары һәм гаскәри дәүләтенең башлыгы итеп сайлана. Ул Оренбургта большевик хөкүмәтен танымаган боерык чыгара) казачий атаманы иде. Казачий атаманның җәяүле гаскәре юк иде. З.Вәлиди аның белән сөйләшүгә кереште вә үзен башкортлар рәисе сыйфатында таныту шарты белән вә атлы гаскәри куәте белән башкорт җәяүле гаскәре туплаячагы хакында сүз бирде. Генерал Дутов моңа риза булды. З.Вәлиди әфәндененең сафына берничә йөз атлы казак бирәчәк [дип вәгъдә иткәч] китеп, З.Вәлиди башкорт гаскәре тупларга тотынды һәм, көчләп, берничә мең гаскәр туплады вә аларны генерал Дутовның ихтыярына биреп, бу монархист генерал белән уртак хезмәттәшлеккә кереште. Фәкать бу монархист хәрәкәтләре Россиянең һәрбер тарафында булган хәлдә куәтле бер хәрәкәт булмады. Хосусән Идел буе халкы гайре рус булганы өчен монда самодержавие фикере күк таралыш тапмады. Киресенчә, большевикларга каршы хәрәкәт итүдән демократиясе сүнде вә Самара шәһәрендә Россиядә демократ бер җөмһүрият ясау ниятендә булганнар (1918 елның 8 июнендә Бөтенроссия Учредительное собрание комитеты әгъзалары большевикларга каршы үз хөкүмәтен төзи. Бу комитет чехословак гаскәрләре күтәрелеше вакытында, ягъни 23 сентябреннән генә берникадәр эшчәнлек күрсәтә ала. 1918 елның декабрендә исә Бөтенроссия Учредительное собрание комитеты әгъзаларының (КОМУЧ) структурасы тулысы белән дип әйтерлек туктатыла), аерым бер хөкүмәт төзер өчен, большевиклар белән гаскәри бәхәсләргә кереште. Бу хөкүмәт Идел буе төрек-татарының бөтен милли хокукларын хөрмәт итәчәген вәгъдә итте вә аерым төрек-татар полклары оешмасы һәм җирле белән җирле төрек-татарлар белән уртак идарә ясау инициативасына кереште, вә мәркәз хөкүмәтендә берничә урынны төрек-татарларга бирәчәген вәгъдә итте. З.Вәлиди үзенең монархист генерал белән хәрәкәттән коры калганын күрер-күрмәс җөмһүриятче демократлар белән аралары киселде вә үзенә полковник дәрәҗәсен бирү шарты белән Самара хөкүмәтенең әмере булганын сөйләде. Һәм җөмһүриятчеләрдән торган бу хәрәкәт, Уфада бер корылтай эшләп, уртак бер хөкүмәт ясарга теләде. Һәм бер нигездә булган вакыйга [нигезендә] җаваплы оешмалар белән сөйләшүгә кереште, вә өлешчә хөкүмәт төзеде. Ялгыз Себериядә Омск шәһәрендә төзелгән җирле хөкүмәттә күпчелек монархистлар тарафында булынган вотякдар Россиядә самодержавиене кайтаруда тырышканнардан бу карарны ихлас белән кабул итмәде. Вә карардан баш тартканнарны соңрак уртак хөкүмәтенең хәрби министры, адмирал Колчак (Александр Васильевич Колчак (1874–1920), Омск шәһәренә килеп, 1918 елның 4 ноябрендә Директория хөкүмәте Министрлар Советының хәрби һәм диңгез министры итеп билгеләнә) иптәшләрен кулга алдылар. Ул үзен диктатор дип игълан итте вә, патшалыкның кайтарылуына тырышуын белдереп, большевиклар белән сугышка керде. З.Вәлиди әфәнде шул вакытта Колчак тарафына күчте. Вә хәзер ки монархистлык фикере өчен эшләргә тотынды. Фәкать Колчакның гайре рус милләтләргә каршы эшләячәге, деспотлык сәясәтен Идел буена кайтаруны юк иттерүләреннән Колчак гаскәре акрын-акрын чигенә башлады. З.Вәлиди әфәнде, башкортлар большевиклар белән сөйләшүгә керешеп, большевиклар тарафына күчте. 1919 елның уртасында булган бу вакытта Зәки әфәнденең Россиядә калган иптәше Шәриф Манатов булды, ул большевиклар белән хезмәттәшлек итәргә тотынды. З.Вәлиди коммунист фиркасенә язылды (З.Вәлидинең «Хатирәләр» китабында аның коммунистлар фиркасенә керүе хакында сүз юк. З.Вәлиди истәлеге раслаганча, ул башта эсерлар партиясенә керергә гариза яза, әмма эсерлар һәм большевиклар белән сөйләшүләр һәм бәхәсләрдән соң гаризаны кире ала, «Төркестан социалистик партиясе» төзергә теләге барлыгын белдерә). Вә хәзер төрек-татар илләрендә коммунизм принципларын берләштерү әмәлен башлады.

Бохара әмире паркында. 1921 ел.

Бу дәвердә төрек-татар коммунистлары арасында милләт фикере күпкә көчле иде. Күбесе, ихластан милләтче булганнары хәлдә, мәслихәт белән коммунист фиркасенә язылды. Вә коммунист байрагы астында берләштеләр. Милли хәрәкәтләрне дәвам иттерү ниятендә иделәр. Боларның Идел буенда булганнары, Идел-Урал өлкәсендә һичбер кабиләчелек хәрәкәте ясап, бер автономия җөмһүрияте төзү ниятендә иде. Вә бу хәбәр тагын да алга китәр өчен, Төркестанны да берләштереп, Идел буена кадәр казах-кыргыз илләрен дә эченә алды. Егерме биш миллионлы төрек халкы, берләшеп, бер Совет төрек-татар җөмһүрияте барлыкка китерү ниятендә иде. Бу максаттан 1919 елда Ташкент шәһәрендә төрек-татар коммунист фиркасенең корылтаен ясадылар (Г.Исхакый искә алганча, төрек-татар коммунистларының Беренче корылтае 1919 елда Ташкентта уза. Солтангалиев эшен караган РКП Үзәк комитеты беркетмәләреннән күренгәнчә, шул ук елда Икенче корылтай Мәскәүдә үткәрелә). Монда уртак бер төрек-татар Совет җөмһүрияте төзү карары һәм бер әдәби телдә мәктәп-мәдрәсәләре, матбугатын идарә итүләре кирәклеге карары, төрек-татар большевикларының бу карары Мәскәүнең хушына килгән эшләрдән түгел иде. Алар бер [халыкны] икенчесеннән аерырга кереште. Коммунист корылтаеның карарын [үтәп] башкортлар Мәскәүдән Совет Башкортстанны игълан иттеләр (Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы 1919 елның 23 мартында төзелә) вә моның белән Идел-Урал һәм Ташкент корылтаеның карарын байрак иттеләр. Мәскәү [өлгермәгәнгә күрә] моннан соңрак Төркестан үзенең төрекмән, кыргыз, каракалпак [җөмһүриятләрен төзи] башлады. Мәскәү хөкүмәтенең иске дәверләрдән бирле Европа төрек-татар илләренә каршы кабул иткән бер ысулы бардыр. Ул да төрек-татар милләтенә яраклы бер ханзадәгә үзен яклавына алдырырга, аның исеменнән төрек илләренең эчке сәясәтләренә каршы килеп, төрек илләренә каршы эшләргә теләгән таләбе, бу ханзадәләр исеменнән ясалган һәм төзелгән Казан ханлыгын, руслар Касыйм шәһәрендә ясалма рәвештә яшәтеп, татар Касыйм ханлыгы исеменнән йөртеп (Касыйм татар ханлыгы 1450 елда Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II тарафыннан Казан ханзадәсе Касыймга бүлеп бирелгән биләмә җирлегендә оештырыла, үзәге – Касыйм шәһәре) һәм Казан ханлыгын юк итү сәясәтләрен, ике нәселнең бәхәсләшүе рәвешенә керүен теләделәр. Кырым вә Төркестанның тарафында да шул йолага керешүләренә вә ханзадәләр арасында каршылыклардан файдаландылар. Большевиклар да Мәскәүнең бик тә чыгымлы булган традициясенең элеккеге ысулын кабул итми. Вә төрек-татар илләрендә үзенең теләкләренә хезмәткә әзер булган мондый үз файдасын кайгыртучылар табыладыр вә З.Вәлиди әфәнде дә шул Касыйм ханнары Шаһгали ханның (Шаһгали (Шаех Гали) хан (1505–1568), 1516–1519, 1535–1546, 1546–1551, 1552–1567 елларда Касыйм ханы) мәгънә ягыннан баласы буларак, З.Вәлидине үзләренең төрек илләренә каршы вә башка Россиядән аерыларга теләгән милләтләргә каршы корал иттерделәр. Совет Башкортстанына З.Вәлидине рәис ясадылар. Вә аннан ирексездән башкорт-татар өлкәсендә мобилизация ясаттылар һәм бу яшьләрне гаскәри хезмәткә алып, боларны Россиянең бөтен әтрафында дәвам иткән эчке сугышларга кулландылар.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 13 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013. 244 б.

(Дәвамы киләсе санда).

Ачлык-ялангачлык онытылмый

Бөек Ватан сугышы Татарстан территориясе аша үтмәсә дә, республиканың һәр гаиләсенә дә ул кайгы-хәсрәт китерде. Һәркемнең планнарын пыран-заран китереп ташлады. Болай да кечкенә туган авылым Иске йорт (Арча районы) бөтенләй бушап калды. Ирләр фронтка китте, хатын-кызларны сугыш – кирәк-яраклары өчен урман кисәргә, торф чыгарырга, саклык корылмалары, юллар төзергә, үсмерләрне Казан предприятиеләренә эшкә җибәрделәр.

Сугыш алдыннан туган бала буларак, мин әтисез үстем. Колхоз рәисе булып эшләгәнлектән аңа бронь бирелгән булса да, ул үзе теләп фронтка китә. Башта аны берничә ай мари урманындагы Суслонгер лагеренда ачка интектерәләр. Аннан соң гына, Мәскәүгә фашистлар һөҗүмен туктату өчен, нигездә Казан тирәсендәге районнардан тупланган дивизияләрен Калуга өлкәсенә җибәрәләр.

Әтиебез беренче сугышта ук һәлак була. Башта «Хәбәрсез югалды», бераздан «Ватан азатлыгы өчен батырларча һәлак булды», – дигән хәбәр генә килә. Ул чорда фронт кырында вафат булучылар гаиләсенә җибәрелә торган гадәти хат!

Статистика мәгълүматларына караганда Татарстаннан сугышка 700 меңгә якын кеше киткән, аларның 435 меңе кире әйләнеп кайтмаган. Димәк, сугышчыларның яртысыннан артыгы.

Көз көне Татарстанда хәрби хәл режимы кертелә. Һава тревогасы үткәрелә. Утларны томалау таләп ителә. Октябрьдә йөз меңнән артыграк кеше Казанны әйләндереп алачак саклык корылмасы төзелешенә җибәрелә.

Тылда сугышның алгы сызыгыннан соңгы хәбәрләрне түземсезлек белән көтәләр. Урамнарга зур репродукторлар куела. Бик күпләр өчен ул матбугат чыганагы булып тора. Аны урамнан үтеп баручылар да туктап тыңлый.

Шактый авылларда ул вакытта радио булмый әле. Анда яшәүчеләр хәрби хәрәкәтләр турындагы мәгълүматларны газеталардан һәм фронт хатларыннан ала. Китапханәләр, клублар газета-журналлар белән тәэмин ителә.

Сугышның беренче көннәреннән үк телеграмма һәм хатлар агымы нык арта. Күп кенә элемтәчеләр атналар буе өйләренә кайта алмый. Почтада алар өстәлгә яки урындыкларга ятып йоклый. Элемтәчеләр ял көннәре турында бөтенләй оныталар. 1941 елның азагында хөкүмәт фронтовикларга җибәрелгән бүләкләрдән тыш барлык посылкаларны тыю турында карар чыгара.

Районнарга һәм авылларга почтаны гадәттә атларда илтәләр. Элемтәчеләргә бирелгән 47 автомашинаның күбесе эшләми. Бензин, запчастьләр җитми. 48 почтальон рәсми рәвештә велосипедларда йөри.

Сугыш башында Казан дистәләрчә мең эвакуацияләнүчеләрне кабул итә. Шәһәр халкы 401 меңнән 515 меңгә кадәр арта. 1943 елда шәһәрдә яшәүче бер кешегә 3,3 квадрат метр торак мәйдан туры килә. Клубларда, кинотеатрларда, складларда да кешеләр яши. Һәр фатирга диярлек квартирантлар кертелә.

Гадәттә бер коммуналь бүлмәдә ике гаилә яши. Ашарга гомуми кухняда керосинка белән пешерәләр. Керосин кытлыгы үзен нык сиздерә. Җәй көне аш-суны урамда ут ягып әзерлиләр. Кыш көне мичкә якканда шунда әзерләргә тырышалар. Әмма мичкә ягарга утын табу бик авыр була. Капка-коймаларны сүтеп-ягып бетерәләр.

Ничек кер юулары турында да язмалар сакланган. Авыллардан базарга сыек сабын китергәннәр. Шуңа көл өстәгәннәр, ул суны йомшарткан. Сөлгеләрне, ак киемнәрне мичләрдә парландырганнар. Керләрне Кабан күленә төшеп чайкаганнар.

Авырулардан саклый дип кешеләр шундый ук су белән юынганнар да. Кайбер предприятиеләр эшчеләрен хуҗалык сабыны белән тәэмин иткән. Ул чорда Казан мунчалары өзлексез эшләгән.

Кич җитүгә урамнар кап-караңгы булган. Фонарьлар яндырылмаган. Һәр тәрәзәгә яктылык үткәрми торган кара материаллар элгәннәр. Кварталдагы хәлне күзәтеп тору өчен чират буенча шушы тирәдә яшәүчеләр билгеләнгән.

1941 елның 1 сентябреннән Татарстанда ипигә карточка системасы кертелә. Сәнәгать предприятиесендә эшләүчегә көнгә – 800, хезмәткәргә – 500, 12 яшькә кадәрге балаларга 400 грамм икмәк бирелә. Ноябрьдә ит, балык, май, ярма, макарон, яшелчә кебек продуктлар да карточка буенча сатыла. Һәр гаилә кайсы да булса кибеткә беркетелә.

Продуктлар алу өчен, чиратта бик озак торырга туры килә. Чернышевский урамындагы кибеткә чират иртәнге икеләрдә үк тезелә башлый. Кибет ачылганда, чиратның ахыры Болакка җиткән була. Карточканы күрсәтелгән көнендә файдаланмасаң, бүтәнчә аңа товар бирмиләр. Достоевский урамында кешеләр чиратка кичтән үк баса.

Сугыш чорында Казанда һәр буш җир кишәрлеген кешеләргә тараталар. Иске аэропорт, Әмәт станциясе, Дәрвишләр бистәсе, хәтта өлешчә Ботаника бакчасыннан да кешеләргә бәрәңге, яшелчә утырту өчен җир бирелә. Язын кешеләр табигый азык белән туклана башлый. Язгы «хәрби» меню кычыткан яки кузгалактан тора. Кишер яфрагыннан һәм чөгендер сабакларыннан, бәрәңге салып аш пешерәләр. Күптөрле азык әзерләгәндә, алабутадан файдаланалар. Ат кузгалагы һәм бераз он кушып, алабутадан ипи дә пешерәләр.

Продукцияне үзләре җитештергәнлектән ул чорда авылда тормыш җиңелрәк булган дип сөйләүчеләр бар. Әмма бу һич тә алай түгел. Авыл нәрсә җитештерә – тулы күләмдә фронтка китеп барган. Колхозчыга хәтта карточка системасы да кертелмәгән, алар ачлыктан интеккән.

Авылда ачлыктан атлар да үлеп бетә яза. Хатын-кызлар алар урынына тырма-сукаларны, чәчкечләрне үзләре тартып йөриләр.

Сугыш чорында мәктәпләр дә бик салкын була. Ягарга утын җитми. Балалар чишенмичә, бүрекләр, бияләйләр киеп утыра. Дәфтәрләр бетә. Әйбер төрә торган кәгазьләргә язалар, сугыш чорында укучыларга каникуллар бирелми. Уку тәмамлангач, алар колхозчыларга ярдәмгә җибәрелә.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

18 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 19 нчы көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 23.52 сәгатьтә калка, 7.48 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, әчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Крыжовник

Остеохондрозны, артритны дәвалау өчен, 20 крыжовник яфрагын 1 стакан кайнар суда 2 сәгать төнәтеп, көненә 3 тапкыр чирегешәр стакан эчәләр. Эч кипкәндә, 2 аш кашыгы җиләкне 300 мл суда кайнатып чыгарып, суынганчы төнәтәләр, сөзеп, һәр 3 сәгать саен 100 әр мл эчәләр. Салкын тигәндә, крыжовник согын сыгып, көненә 2 тапкыр яртышар стакан эчәләр, шул сок белән тамакны да чайкыйлар.

19 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 20 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 8.52 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

20 июнь (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 21 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 0.04 сәгатьтә калка, 10.22 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Кан тамырларын киңәйтә

Уртача зурлыктагы сарымсакны чистартып, изәләр, пыяла банкага салып, өстенә 1 стакан чистартылмаган көнбагыш мае агызалар да, яхшылап болгатып, суыткычның аскы киштәсенә куялар. 1 атнадан дәвалана башларга була. Көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 чәй кашыгы сарымсак маена 1 чәй кашыгы яңа сыгылган лимон согы кушып эчәләр. Дәва курсы - 1 ай, аннары 1 ай ял итәләр һәм курсны кабатлыйлар.

21 июнь (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 22 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 0.13 сәгатьтә калка, 11.46 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

Очкылыкны басу

Диафрагма янындагы эчке әгъзаларның ярсуы нәтиҗәсендә, күп ашаудан, коры ризыктан, кысып торган киемнән баш миенә сигнал китә, диафрагма кыскара һәм кешене очкылык тота башлый. Озакка сузылган очкылык тоту яки аның еш кабатлануы үпкә яман шеше, инфаркт, кан тамырлары чирләре барлыгын күрсәтергә мөмкин. Очкылыкны басу өчен 1 стакан суны вак кына йотымнар ясап эчәргә яки лимон телеме суырырга була. Кайвакытта тирән сулыш алып, һава йоту да ярдәм итә. Гиппократ исә төчкереп карарга киңәш итә. Тиз-тиз итеп нинди дә булса тизәйткечне берничә тапкыр кабатлау да булышырга мөмкин.

22 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 0.21 сәгатьтә калка, 13.07 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Тамак авыртканда

Аңкау бизләре (гландалар) ялкынсынса, кабыгы белән йомырка пешереп, яулыкка төрәләр дә, 10 минут буе авырткан урынга куеп торалар. 1 стакан кайнар суга 1 чәй кашыгы тоз, ярты чәй кашыгы сода салалар, 5 тамчы йод тамызалар, җылымса килеш әледән-әле тамакны чайкыйлар.

23 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 0.29 сәгатьтә калка, 14.27 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

24 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,0.37 сәгатьтә калка, 15.46 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Баллы торт

3 йомыркага 1 стакан шикәр кушып туглыйлар. Кечкенә савытта 2 аш кашыгы балга 1 чәй кашыгы сода кушып, яхшылап болгаталар. Аннары ике массаны бергә кушалар да, 200 г йомшартылган атланмай, 3-4 стакан он өстәп, бик куе булмаган камыр басалар. 20-30 минут суыткычта тоткач, ул кулга алып әвәләрлек була. 8-9 өлешкә бүлеп, пешерәсе табага кул белән җәяләр, 3-4 мм калынлыкта булырга тиеш. Чәнечке белән тишкәләп, газ мичендә тиз генә пешереп алалар. Берсен пешергән арада, калган камыр суыткычта торырга тиеш. Ярты литр куе каймакка (сметана) ярты стакан шикәр кушып, крем ясыйлар, җәймәләргә сылап, өяләр, 2-3 сәгатькә суыткычка куялар. Өстен шоколад, мәк, чикләвек белән бизәргә була.

Җәлилнең иң якын дусты

Казан дәүләт университетында татар халык авыз иҗатын (фольклор) күренекле галим, тәнкыйтьче Гази Кашшаф укытты. Аның документларда теркәлгән тулы исеме Миргази Солтан улы Кашафетдинов иде.

Гаҗәеп ягымлы кеше иде Гази ага. Без дә, аның студентлары, остазыбызны искиткеч хөрмәт иттек. Шунсыз булмагандыр да. Ул култык астына калын гына папка кыстырып елмаеп аудиториягә килеп керә. Исәнләшкәннән соң, язучылар тормышының соңгы вакыйгаларыннан берәр мәзәк сөйләп ала.

Гази ага бераз аксаклап йөрде. Еш кына ул таякка таянып та килә иде. Г.Кашшафның улы Казан университетын безнең белән бер елны тәмамлады. Әмма ул физика-математика факультетында укыды.

Гази ага 1907 елның 15 апрелендә Башкортстанның Туймазы районы Яңа Арсланбәк (Новоарсланбеково) авылында туа. Әтисе авыл мулласы һәм мөгаллиме була. Революциядән соң мәчетләр ябылгач, колхозда умартачы булып хезмәт итә.

Бәләбәй педагогика техникумын тәмамлагач, Миргази Кашафетдинов 1925 елда Казан шәһәренең көнчыгыш педагогика институтына укырга керә. Студент елларында ук Миргази әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен актив язарга керешә. Алар төрле матбугат басмаларында дөнья күрә. Татар язучылары әсәрләрен тикшерүләрдә дә катнаша, чыгышлар ясый.

Институтны тәмамлаганнан соң Миргази Кашафетдинов Казан мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында укыта. 1937 елдан Г.Кашшаф Татарстан китап нәшриятында. Бераз нәфис әдәбият секторын җитәкли, 1939 елда нәшриятның баш мөхәррире итеп билгеләнә. 1942 елны, Бөек Ватан сугышының иң кызган чорында аны «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире итеп раслыйлар. Г.Кашшаф актив эшли, күп яза. Иҗатының башлангыч чорында ул нигездә хикәяләр, повестьлар иҗат итә.

1940 елда авторның совет чик сакчылары батырлыгына багышланган «Чүл комлыгында» повесте аерым китап булып басылып чыга.

Шәриф Камал, татар халкының беренче актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжская иҗаты турында тикшеренүләре дөнья күрә. Г.Кашшаф тәнкыйть мәкаләләреннән торган берничә җыентык чыгара. Белгечләр аның тарафыннан өч йөздән артык тәнкыйть мәкаләсе язылган дип исәплиләр. Кашшаф шулай ук рецензияләр, әдәби портретлар һәм театр спектакльләренә күзәтүләр дә яза. Аерым алганда ул – Ш.Камал, Г.Камал, Г.Тукай, Ә.Фәйзи, К.Нәҗми, М.Галәү һәм башка язучылар иҗатларына багышланган аналитик мәкаләләр авторы. Тәнкыйтьче шулай ук урта мәктәпләрнең, өлкән классләры өчен дәреслекләр, хрестоматияләр чыгаруда да катнаша.

Гази ага Казан дәүләт университетында әүвәл татар әдәбияты кафедрасында укыта, аннары 1964 елда журналистика кафедрасы ачылгач, шунда күчә. Һәм үлгәнче – 1975 елның декабренә кадәр ул биредә.

Гази ага Бөек Ватан сугышы чорында фронтта хезмәт итүче язучыларыбызның барысы белән диярлек языша тора. Әмма ул якын дусты – Муса Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын тикшерүгә бигрәк тә зур әһәмият бирә. Кашшафны Җәлилнең төп библиографы, тормыш юлын өйрәнүче дип тә атарга мөмкин. Гази ага Җәлилнең фашист тоткынлыгындагы эшчәнлеген, ролен, биредәге коммунистлар тормышын җентекләп өйрәнә.

Муса Җәлил үзенең мирасын да Кашшафка ышанып тапшыра. Җәлилнең аңа хаты да сакланып калган. Анда шундый сүзләр бар: «Кадерлем минем, Кашшаф! Син минем иң якын, кайгыртучан, кадерле дустым идең һәм шулай булып каласың да. Минем өчен иң авыр мизгелләрдә син миңа үзеңнең чын йөрәктән язылган хатларың белән ярдәм иттең. Минем иҗади китабым һәм гаиләм турында кайгырттың. Мин чын йөрәктән сиңа рәхмәтемне белдерәм. Хәзер дә мине онытмаячагыңа ышанам. Минем поэзиямне дә, гаиләмне дә җылылыгың белән әйләндереп алырсың. Миңа шуңа күрә мин бөтен иҗатымны тулысы белән сиңа ышанып тапшырам. Исән чагымда минем язган васыятем шундый. Гомерем буе язган әйберләремнең барысы да синең карамагыңа, синең кайгыртуга күчә. Мин поэзиямнең ышанычлы кулга тапшырылуына шатмын».

Шагыйрь мондый адымы белән ялгышмый. Сугыштан соң Гази ага беренчеләрдән булып шагыйрь язмышын ачыкларга керешә. Ул беренче буларак Җәлилнең Моабит дәфтәрләренә фәнни аңлатмалар төзи, Җәлил сайланма әсәрләренең татар телендә өч томлыгын, рус телендә бер томлыгын әзерли. М.Җәлил турында истәлекләрне җыеп бастыра. Гази ага гомере буе герой шагыйрьнең ышанычлы дусты булып калды, аның васыятен тулы күләмдә үтәде.

Муса Җәлил бу васыятен дустына 1942 елның җәендә җибәргән була. Хат Волхов фронтыннан килә. Конвертта кыска гына хат белән бергә васыять тексты да була.

1976 елда Гази Кашшафка Татарстан комсомолының Муса Җәлил премиясе тапшырыла. Бу бүләккә галим Җәлил тормышын һәм иҗатын тикшерергә багышланган хезмәтләре циклы өчен лаек була.

Гази ага үзенең туган ягында да еш булырга тырыша. Ул Башкортстанның күп кенә язучылары, галимнәре, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре белән элемтәдә яши. Бигрәк тә халык шагыйре Мостай Кәрим белән дуслыгы нык була.

Күренекле галим Г.Кашшаф 1975 елда 68 яшендә безнең арадан китеп барды. Тууына 115 ел тулу ничектер игътибарсызрак үтеп китте кебек.

Дөрес, хезмәттәшләре, шәкертләре күренекле әдәбият белгече Гази ага Кашшафны онытмыйлар. Мәсәлән, Л.Бәдретдинованың күп кенә журналларда, җыентыкларда аның әдәби тәнкыйть эшчәнлеге турындагы хезмәтләренә багышланган язмалары чыкты.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

МК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

17 июнь – Ф.Г.Волков исемендәге драма театрының «Страх» спектакле (А.Афиногенов).
18 июнь – 18.00 – Ф.Г.Волков исемендәге драма театрының «Неаполитанские каникулы» спектакле (Э.Скарпетта). 19.00 – «Белый квадрат» спектакле (Я.Реза).
19 июнь – Ф.Г.Волков исемендәге драма театрының «Неаполитанские каникулы» спектакле (Э.Скарпетта).
21 июнь – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
22 июнь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
23 июнь – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
24 июнь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

17, 18 июнь – «Кармен» (Ж.Бизе).
22 июнь – «Җәлил» (Н.Җиһанов).
24 июнь – «Дама с камелиями» (Дж.Верди).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

18 июнь – 11.00, 13.00, 15.00 – Премьера. «Русалочка» (Г.-Х. Андерсен). 12.00 – «Камыр батыр» (С.Хөсни).
19 июнь – 11.00, 13.00 – «Идет коза рогатая» (М.Протасова). 12.00, 14.00 – «Теремок» (С.Маршак).

Дин һәм заман таләбе

Алга таба, татар исламы организмы үскән саен, «гарип»лектән арынырга теләмәүче кадими исламнан ераграк аерыла барыр һәм үзе сайлаган кайту юлында бер «ялгыз»ы калыр. Искелекне яклаучы мөселман дөньясы мондый яңа «кардәш»ен танырга теләмәс, аны «бидгать» дип игълан итәр һәм, ана организмында тулгак башланып, баланы кысрыклап-этеп чыгарган шикелле, татар исламын үз сафларыннан «куар». Шулай итеп, Рәсүлебез өммәтендәге «революцион» вә «контрреволюцион» көчләр көрәше нәтиҗәсендә инкярне инкяр итү законы реальләшер – исламның заманга яраклашкан камил аңлы (борылышны тәмамлаган), югары культуралы (мөшриклектән арынган) яшь буыны дөньяга килер һәм адәми затның яңа цивилизациясен башлап җибәрер. Әлеге цивилизациянең максаты кешелек эволюциясендә ахырзаман программасын тиешенчә башкаруны, ягъни кайту юлының Җирдәге өлешен уңышлы үтүне күздә тота. Димәк, аның нигезе бердәнбер хак дин булган исламга корыла. Иншалла, шулай булыр!

Ихтимал, киләчәгебезгә карата мондый юраулар татарга бик үк ошап бетмәстер, иманнары ныгып җитмәгән кайбер наданнарны алар куркуга салырга да мөмкин. Әмма нишләмәк кирәк, чынлап та, кайту юлы сикәлтәле һәм андагы мөсафирларның юламаны вазифасын башкару исраил токымына йөкләнгән, ә татар (кызганычкамы, әллә сөенечкәме – анысы һәркемнең иманы ныклыгына карап) – аның бүгенге варисы – димәк, моны, өлешебезгә төшкән көмешебез, дип кабул итү мәслихәт.

Хәер, бирегә пошаманга төшәрлек бернәрсә дә юк – цикллар алмашынуы һәрчак охшаш вариантта барган. Коръән аның тәртибен Муса пәйгамбәр мисалында күрсәтә. Әлеге үрнәк ике аспектта бирелә: Муса пәйгамбәр, бер яктан, Үгезбозау эрасы дине традицияләренә каршы көрәшүче һәм Кучкарныкына – иудаизмга нигез салучы рәсүл, икенче яктан, аны (иудаизмы) Балык чоры конфессиясенә – нәсарага тоташтыручы мистерия (исраил токымы) вәкиле. Риваятьләрдә, Муса пәйгамбәр Үрдүн (Иордан) елгасын кичә алмаган, үлгән, диелә. Үрдүн – Иисус Христосны чукындырган елга (цикллар әйләнешендә Гайсә Мәсих дине башланган урын яки вакыт), ягъни христианлыкка күчкәч, Муса пәйгамбәр чоры тәмамланган. Хәзер дә охшаш вәзгыять күзәтебез: дини эралар алмашынуы башланган чакларда яшибез.

Татар исламы дигәнебез кешелекнең нәсарадан исламга күчү чорында үзебезгә йөкләнгән тарихи вазифаны – әлеге эралар тәгълиматларын үзара ялгау миссиясен тануыбызны аңлата.

Югарыда «татар исламы организмы» дигән гыйбарә кулланган идек. Әйтергә кирәк, бу очраклы түгел. Ислам бит дин генә түгел, ул яшәү рәвеше. Димәк, әлеге организм җәмгыять тормышы өчен әһәмиятле булган күп кенә мәдәни һ.б. аспектларны да үз эченә ала. Шулар арасында, иң мөһиме, мөгаен, тел мәсьәләседер. Чөнки, фикерләү һәм аралашу коралы буларак, ул диннең үзенә дә (мәсәлән, Изге Китапларны дөрес аңлау вә аңлату, халыклар арасында ислам тәгълиматының таралуы кебек юнәлешләрдә) зур йогынты ясый.

Халыкның бер организм булып яшәвен һәм үсеш алуын теләсәк, ул зур динамизм белән үзгәрүчән хәзерге заманга һәрдаим яраклашып торырга, аның дөньяга карашы вә ният-гамәлләре Аллаһ тәкъдиренә тәңгәл килергә тиешлеген дә кире какмабыздыр. Моңа кайчан ирешеп була? Әгәр милләтнең бөтен катламнары да иҗтимагый фикерләүдә максатчан уртак корал кулланса, ягъни уй-теләкләре һәм телләре бер булса. Бездә ничек соң? Милләтпәрвәр язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, зыялылар туган телебездә яза, аны үстерү өчен дә эшләргә тырыша кебек. Ә менә дин әһелләре әлегрәк ярым татарча, ярым гарәпчә сөйләсә, хәзер күпләре гарәпчә-русчага күчте. Галимнәребезнең үзләрен «уважать иткән» өлеше (ягъни күпчелеге) русча иҗат итә. Гавам исә яртылаш рус сүзләре һәм алынмалары белән тулган «татар халык телен»дә яки «өлкән агай»ча аралаша. Кыскасы, милли бердәмлек тәрбияләү коралы иман таләбенчә (Аллаһ кушканча) эшләмәгәч, таркаулыкны җиңеп, тулы канлы организмга әверелдек, дип мактана алмыйбыз.

Шулай да, гайре табигый шартларда (империя коллыгында) яшәп, иманы какшаган, теле күңелен иркәләми, моңы җанын жылытмый башлаган татар соңгы елларда үзенең тышкы чикләрен ныгытуга (шәригатьчә яшәү тәртибен кайтаруга) керешкән иде. Мәгәр, язмыштан узмыш юк, дигәндәй, Аллаһ яңа сынаулар җибәрә безгә. Сүз рус телле ислам турында бара. «Исламда милләтләр юк» шигарен кулланып, мәчет-мәдрәсәләребездә «россияннар теле»ндә сөйләшү гадәте урнашып килә. Ни гаҗәп, бу татар руханилары фатихасы белән башкарыла. Мондый күренешнең сәбәбе дә, асылы да сер түгел: тәүгесе әлеге дин әһелләренең тар карашлылыгына бәйле булса, икенчесе мескеннәрнең иманнары ныгып җитмәгәнлеген күрсәтә. Алар байлык, хакимият, җәмгыяви статус кебек фани кыйммәтләргә бакыйлыкны-кыннан (рухи хәзинәләрдән) өстен күреп, динне илдәге империячел сәясәткә буйсындырмакчы. Югыйсә, акылын җуймаган кешегә, гыйбадәтнең-гарәпчә, вәгазь һәм дингә өйрәтүнең русча башкарылуы телебезне бетерүгә илтеп кенә калмый, бәлки милләттәшләребезнең иманын да какшата, икәнлеге көн кебек ачык сыман...

Хәер, бар нәрсә дә – Аллаһтан, дигәнне искә төшерсәк, Аның әлеге сынавында (гарәпләшкән динебезнең руслаша да баруында) хикмәтле гыйбрәт эзләргә кирәктер: ихтимал, Ул, моның белән күңелләрдә борчу тудырып, динебез теле татарча булырга тиешлегенә игътибар итү зарурлыгын искәртәдер. Бу уңайдан танырга кирәк, бездә дөньяны чын исламча (тәүхиди-иҗтиһади шаһәдәткә таянып) кабул итү тәҗрибәсе җуелган. Югыйсә, аның әйрәтүенчә, Аллаһ – Кеше багланышларында арадашчы юклыгын да беләбез сыман. Димәк, Хак Тәгалә белән татар арасында беркем дә, бернәрсә дә: рус та, гарәп яки төрек тә, дин яисә Изге Китаплар да (җөмләдән, Коръән дә), Кәгъбә һәм Рәсүл дә юк. Абсолют – бары тик Бер Аллаһ Үзе, Аңа тиңләрдәй (һәм мәңгеләштерердәй) бер генә зат яки әйбер вә күренеш тә юк, шул исәптән ислам үзе дә.

Алайса боларның барысыннан баш тартырга һәм аларны инкяр итәргәме? Юк, әлбәттә. Ләкин һичкайсысын мотлаклаштырмаска, Хак Тәгалә биргән акыл белән ни кимәлдә Кешене Аллаһка якынайтуларын «үлчәп», аларга үз мөнәсәбәтеңне билгеләргә. Бу дин тоту нинди телдә булырга тиешлеге мәсьәләсенә дә кагыла – гыйбадәт бит Аллаһ белән аралашу чарасы. Бу җәһәттән, гарәп теленә мөнәсәбәттә дә иске карашны мәңгеләштермәскә, ә вакыт – җирлек таләпләренә тәңгәл рәвештә, догаларны әкренләп туган телебезгә күчерергә кирәк.

Мондый фикернең беркайчан да гамәлгә ашмаячагына иблисләрчә инанган һәм аны көферлек дип игълан итәргә әзер торучы «чын мөселман»нар (хәзерге кадимчеләр үзләрен шулай атый бугай) барлыгы билгеле. Аларга Аллаһ кисәтүен онытырга ярамаганлыгын искәртәсе килә: «Без һәр өммәткә үзләренә кулай булганча, гыйбадәт тәртипләдек. Шулай булгач, алар бу мәсьәләдә синең белән чәкәләшмәсеннәр» (Коръән, 22:67).

Әлеге фикернең күп кенә дин тотучылар тарафыннан кабул ителмәве сәбәбенә килгәндә, анысы исламның асылын, бигрәк тә «иман» төшенчәсен аңлап җиткермәүгә бәйле. Янәсе, Рәсүлебез гарәп булгач, Коръән гарәпчә иңдерелгәч, иманлы булу өчен гарәпләрчә яшәргә (сөйләшергә, киенергә, ашарга-эчәргә һ.б.) кирәк; әлеге «изге» халык бездән өстен, димәк, аңа иярү – саваплы гамәл. Мондый карашның формалашуында Коръәннең татарчага тәрҗемә ителмәве дә зур роль уйнаган. Ә бу гарәп һәм төрек империяләре тарафыннан махсус эшләнгән: буйсындырылган халыклар Изге Китапны үзлегеннән укый алмасын, исламның асылы турында уйланмасын, иман хакында мөстәкыйль фикерләре тумасын; ә руханиларны хакимияткә кирәкле юнәлештә үзебез әзерләрбез.

(Дәвамы киләсе санда).

Рашат САФИН.

«Татар инануы» китабыннан.

МАНТЫЙК КИРӘК

Илдә болай да тынычлык булмаган вакытта, аңа яңаларын өстәргә тырышучылар табылып тора. Хәзерге вакытта, илдәге хәлләрнең килеп чыгуына китергән, гадел булмаган гамәлләр аркасында булуы күренеп тора.

ЛДПР депутатларының Казанда Жириновскийга урам исеме бирү турында хыялланулары матбугатта бастырылгач, башка күсәк белән томырган кебек булып китте. Гадәттә, андый исемнәргә монда туып-үскән, республика, халкы өчен изгелекләр эшләгән, аңлы, белемле, булдыклылыгы белән аерылып торган, күренекле шәхесләр лаек булалар. Казан урамына аның исемен бирергә теләүчеләр аның кыланмышларын, явыз ниятле фикерләрен, татар-башкорт халкын Монголиягә куарга, “пусть они там подыхают от голода” дигән сүзләрен белмиләр микән әллә? Аның Дәүләт Думасында нәфрәтләнеп, коточкыч явызлык, бернинди кысаларга сыймый торган әдәпсезлек белән, милләтара ызгышлар чыгара торган чыгышлары илгә берәр төрле файда китердеме әллә? Ул - милли республикаларны юкка чыгарып, анда яшәүче халыкның телен бетереп, илдә бер тел генә калдыру, җитәкче урыннарда өлкән ага милләтеннән булган кешеләрне генә куярга чакырган зат, Казан урамына аның исемен бирү мантыйклыкка туры киләме?

Илдәге төп халыкны яклаган булып кыланса да, гомумән, ул беркемне дә яратмады кебек. Хәзерге бик хәтәр бәрелешләрне булдыру өчен зур тырышлык күрсәтеп китте ул. Кыскача әйткәндә, Казанда гына түгел, гомумән, ил буенча андый дәрәҗәле исемнәргә лаеклылыгы булмады бу адәмнең.

Безнең дәүләтчелегебезне юкка чыгарып, биш гасыр буе интегеп яшәргә мәҗбүр иткән Явыз Иван белән Петр беренчегә дә Казанда һәйкәл куярга тырышып караучылар булды бит. Һәйкәлләр андый явызлыклар өчен түгел, изгелек эшләүчеләргә куела бит ул. Андыйларга куелганда да, үз вакыты җиткәч, аларны ничек өстерәп төшергәннәрен күреп торабыз бит.

Республикага һәм халкыбызга күптөрле изгелекләр эшләгән күренекле шәхесләребезнең һәйкәле түгел, урам исемнәре дә булмавын ничек аңларга? Хөкүмәт карары чыкканнан соң, дистә ел үтүгә карамастан, Сара ханым Садыйкова һәйкәл куелмавы белән ничек килешергә?

Казан Кремлендәге төп урам “Шейнкман” урамы дип атала. Аның кем икәнен белүче булса да, санаулы гынадыр. Безнең халыкка берәр төрле изгелек эшләгәне булганмы?

Казан шәһәре топонимика бүлегенең эшчәнлегенә карата зарлар еш ишетелә, үзгәреш кенә күренми.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

124 елан белән яшәгән

Американың Мэриленд штатында 48 яшьлек ир-атны өендә елан чагып үтергән. Берничә көн күренмәгәч, күршесе хафалана башлаган һәм тәрәзәсеннән караган. Ирнең идәндә ятуын күргәч, коткару хезмәтләрен чакырган. Полиция әлеге йортта 124 рептилия, шул исәптән дүрт метр озынлыктагы буй-буйлы буар елан тапкан. Алар барысы да үзенең махсус читлегендә яшәгән, тик көннәрдән бер көнне кайсыдыр хуҗасын чаккан. Араларында кайберләре бик агулы булып, өйдә асрау бөтенләй тыелган еланнар да бар. Агусыз сөйрәлүчеләрне Вирджиния штатындагы террариумга урнаштырганнар, агулыларын, шул исәптән берничә кобра һәм кара мамбаны Төньяк Каролина штатындагы белгечкә илтеп биргәннәр.

(“NBC Washington”).

Җиһаз... үстерә

Британиядәге Full Grown фирмасы хуҗасы дизайнер Генри Манро җиһазлар җитештерүнең уникаль технологиясен уйлап тапкан һәм гамәлгә ашырган. Өстәл-урындык, торшерларны ул үзенең җиһаз “бакчасында” үстерә. Әлеге фабрика, дөресрәге, түшәмсез һәм диварсыз ферма, Дербишир графлыгы Уирксворт шәһәрендәге 1 гектарлы мәйданда урнашкан. Түтәлләрдә дүрт йөзләп өстәл, урындык, люстра үсә. Бер елда фирмада иллеләп җиһаз җитештерелә. Технологиясе шактый гади: яшь агачны махсус пластик конструкцияләрнең формасын алырлык итеп урнаштыралар, кирәкле формага кергәч, аның кәүсәсе һәм ботаклары юанаюын көтәләр. Катлаулылык дәрәҗәсенә һәм үзагач төренә карап, бер җиһазны “ясауга” дүрттән алып сигез елга кадәр вакыт китәргә мөмкин. Күбесенчә тиз үсә торган тал кулланыла. Хәзер комод һәм китап киштәсе дә үстерергә өйрәнмәкчеләр. Экологик чиста һәм бер кадаксыз ясалган җиһазларның бәясе кыйммәт – 11 мең евродан башлана, әмма инде “уңышка” 2030 елга кадәр чиратка язылганнар һәм сабыр гына көтәләр.

(“Die Presse”).

Йөрәккә бәрә

АКШ кардиологлары, йокысызлык китергән зыянны өйрәнеп, озак вакыт буе туйганчы йоклый алмаган кешеләрдә инсульт, тулы аритмия, йөрәк җиткелексезлеге килеп чыгу куркынычының артуын ачыклаган. Мичиган университеты галимнәре раславынча, аз һәм тынычсыз йоклау, төнлә әллә ничә тапкыр йокыга китеп, әллә ничә тапкыр уяну кан басымын күтәрә, симертә, болар исә йөрәк-кан тамырлары авыруларының төп сәбәбе булып тора. Хроник йокысызлыктан интегүчедә тулы аритмия башлану ихтималы туйганчы йоклаучы белән чагыштырганда 29 процентка артыграк була.

(“The Times”).

Тормышын җиңеләйткән

Америкада Матильда Каль исемле кыз һәр иртә саен эшкә нәрсә кияргә дип баш ватудан туйган. Бу күп вакыт таләп итә һәм канәгатьләнүгә караганда күбрәк ризасызлык хисе тудыра башлаган. Матильда нәкъ бер төрле 15 ефәк блузка һәм 6 пар кара чалбар сатып алган. Нәрсә киясен төгәл белгәч, иртән эшкә соңга калудан туктаган, нервлары тәртипкә килгән. Хезмәттәшләре генә баштарак аптырашта калган. Бер ай буена гел бер киемнән йөргән Матильданы йә кем белән булса да бәхәсләшкәндер, йә ниндидер сектага эләккәндер, дип хафаланганнар, җитәкчелек исә, аның кием алырга акчасы җитмидер дип, эш хакын күтәрергә җыенган. Кызның үзеннән сорагач, барысы да ачыкланган, һәм Матильда менә инде биш ел буе эшкә көн саен шулай киенеп йөри. Ял көннәрендә исә ул бик матур киенә, үзенә төрле төстәге, модалы кием-салым сатып алудан да туктамаган, бары тик эш киеме генә үзгәрешсез калган.

(“Лента.ру”).

Хәйләкәр кытай

Кытайда самолетта беренче класс белән очучы пассажирларны һавага күтәрелгәнче бушлай ашаталар. Шәнси шәһәреннән Вонг Ва Ют По исемле бер кытай шуннан бик оста файдаланган. Ул China Eastern Airlines компаниясе очкычына билет алган да, көн саен аэропортка килеп, тәмләп сыйланган, аннары очышын иртәгәге көнгә күчерүне үтенгән. Һәм көн саен диярлек шулай эшләгән – елына 300 тапкырдан артык бушка ашап киткән. Бер елдан соң гына авиакомпания хезмәткәрләре үз билетын әллә ничә тапкыр башка көнгә күчергән сәер пассажирга игътибар иткән. Законга каршы килерлек бернәрсә дә эшләмәгәнгә, Вонг Ва Ют Поның билетын гына гамәлдән чыгарганнар, әле аның бәясен дә үзенә кире кайтарып биргәннәр!

(“Синьхуа”).

Балык урынына – бүрәнә

Гонконгта балыкчы Мин Квок диңгездән зур балык урынына бүрәнә өстерәп чыгарган. Җенләнеп, кире суга атмакчы булганда, агачның хуш исен тойган. Балыкчы агачның кайрысын куптаргач, аннан сары май агып чыккан, шунда гына ир-ат үзенә бәхет елмайганын аңлаган. Әлеге диаметры өч метрлы бүрәнә алоэ яки оҗмах агачы кисәге булып чыккан, ул медицинада һәм парфюмериядә кулланыла. Кытай халык медицинасында алоэ агачы үсемлекләр арасында “бриллиант” санала. Балыкчы тапкан пүләннең якынча бәясе – бер миллиард Гонконг доллары (130 миллион АКШ доллары)! Мин Квок агачны сатканнан соң берникадәр акчасын хәйриячелеккә тоткан, үзенә шәп йорт сатып алган.

(“Интересно.cc”).



Шешә “почтасы” сынатмаган

Бразилиядә алты балыкчы елгада бата язган һәм кеше яшәми торган утрауда 17 көн буе ярдәм килүен көткән. Судно 24 мартта Сантарен шәһәреннән юлга кузгалган. Көньяк Американың көнчыгыш ярында Амазонка тамагында урнашкан Шавис шәһәренә экипаж ун көндә барып җитәргә ниятләгән. Әмма өч көннән соң алар белән элемтә югалган, туганнары флотка аларның югалуы хакында хәбәр иткән. Кораб давылга очраган һәм яна башлаган икән, запасларның күп өлеше юкка чыккан. Шулай да экипаж утрауга барып җитә һәм судноны ярга өстерәп чыгара алган. Ике атна буе ачлы-туклы яшәгәннәр. Өметләрен өзмичә, үзләренең координаталарын һәм туганнарының телефоннарын күрсәтеп: “Ярдәм итегез! Безгә ярдәм кирәк! Корабыбыз янды, кешесез утрауда 13 төн кундык инде. Безнең гаиләләребезгә хәбәр итсәгез иде. Без биредә алты кеше”, – дип хат язып, аны шешәгә салып, елгага ташлаганнар. Хатны тапкан балыкчылар шул мизгелдә үк флот вәкилләренә хәбәр иткән. Вертолет килеп тә җиткән.

(“Brazilian”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

20 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Уроки истории». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

4.00 Спектакль «Әлепле әртистләре». 12+
6.00 «Син һәм мин». Салават Миңнеханов һәм Гүзәлем концерты. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Молодая наука». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «1812-1815. Заграничный поход». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Беггров.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 Цвет времени. Ар-деко.
8.35 «ЩЕДРОЕ ЛЕТО».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Не верь разлукам, старина. Юрий Визбор».
12.30 Вспоминая Анатолия Лысенко. Линия жизни.
13.25 «Гатчина. Свершилось».
14.15 «Долгое эхо Роберта Рождественского».
15.05 «Екатеринбург. Особняк Тупиковых».
15.35 Острова. Светлана Крючкова.
16.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ БУДУЛАЯ».
17.40 Мастера исполнительского искусства. Государственный квартет им. А.П.Бородина.
18.45 «Маргарита Лаврова. Принцесса оперетты».
19.45 Главная роль.
20.05 Великие реки России. «Чусовая».
20.50 85 лет Николаю Дроздову. Линия жизни.
21.45 «ИЮЛЬСКИЙ ДОЖДЬ».
23.30 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

21 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Җырларыбыз сезгә юлладым». Бәширә Насыйрова концерты. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Родная земля». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Яшәү- мизгел». Нәфкатъ Нигъмәтуллин концерты. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Мюнхенский сговор. Приглашение в ад». 12+
15.45 «Битва ставок». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
7.45 Великие реки России. «Чусовая».
8.40, 16.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ БУДУЛАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Кинопанорама. Мастера советского кино».
12.45, 21.45 «СОРОК ПЕРВЫЙ».
14.15 «Игра в бисер» «Гюстав Флобер. «Госпожа Бовари».
15.05 «Эрмитаж».
15.35 «Сати. Нескучная классика...»
17.40 Мастера исполнительского искусства. Дмитрий Маслеев.
18.40 «Николай Дупак. Судьба длиною в век».
19.45 Главная роль.
20.05 Великие реки России. «Северная Двина».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Белая студия».
23.10 «Ярославль. Замок Никиты Понизовкина».

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

22 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Таң атмады бүген...» 12+
7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Никто не забыт, ничто не забыто. Мазитов Назип Минхамидович. 1914 - 1943». 12+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.35 «Соотечественники». 12+
23.50 «Уроки истории». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Яңа сулыш». Айдар Галимов концерты. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Ватандашлар». 6+
12.40 «Айлы кичтә». Энҗе Шәйморзина концерты. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Татар халык җырлары». 6+
20.00 «Таң атмады бүген». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Молодая наука». 12+
15.00 «Концерт Победы на Мамаевом кургане».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+
22.45 «КРЕПОСТЬ». 16+

«РОССИЯ»

4.00, 0.00 «22 июня, ровно в четыре утра... Реквием Роберта Рождественского».
5.10, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Мальчики державы. Михаил Кульчицкий».
7.35 «Первые в мире».
7.50 Великие реки России. «Северная Двина».
8.40, 16.05 «ВОЗВРАЩЕНИЕ БУДУЛАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Путешествие по Москве».
12.20 «Мальчики державы. Сергей Орлов».
12.45, 22.10 «ЗАВТРА БЫЛА ВОЙНА».
14.15 «Мальчики державы. Михаил Луконин».
14.45 «Забытое ремесло».
15.05 «Библейский сюжет».
15.35 «Мальчики державы. Борис Слуцкий».
17.15 «Мальчики державы. Давид Самойлов».
17.45 К. Бодров. Реквием на стихи Р. Рождественского. Сергей Гармаш, Юрий Башмет и Всероссийский юношеский симфонический оркестр.
18.35 «Евгений Куропатков. Монолог о времени и о себе».
19.45 Главная роль.
20.05 Великие реки России. «Обь».
20.45 Юбилей Натальи Варлей. Линия жизни.
21.45 «Мальчики державы. Павел Коган».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ». 16+
23.25 «Квартирник НТВ у Маргулиса». 16+

Пәнҗешәмбе

23 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 0.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 12+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 12+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Габдрахман». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+

14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Молодая наука». 12+
15.00 «Меганаука». 12+
15.30 «Битва ставок». 12+
16.20 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+
22.45 «КРЕПОСТЬ». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 23.20 «Первые в мире».
7.50 Великие реки России. «Обь».
8.35 «Забытое ремесло».
8.50, 16.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ БУДУЛАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Веселые ребята».
12.10 «Ярославль. Замок Никиты Понизовкина».
12.40, 21.45 «ПЕЧКИ-ЛАВОЧКИ».
14.20 Абсолютный слух.
15.05 Моя любовь - Россия! «Традиции чаепития».
15.35 «Белая студия».
17.25 Цвет времени. Караваджо.
17.45 Мастера исполнительского искусства. Александр Бузлов и Андрей Гугнин.
18.45 «Николай Лебедев. Война без грима».
19.45 Главная роль.
20.05 Великие реки России. «Волга».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Энигма. Тина Кузнецова».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ». 16+
23.25 «ЧП. Расследование». 16+
23.55 «Поздняков». 16+

Җомга

24 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.00 «Башваткыч». 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 0.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00 «Юлчы». 6+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Күрешергә вакыт табыйк». Ил-Саф концерты. 12+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Абрек Абзгильдин турында телеочерк. 6+
13.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова концерты. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ТАЙНОЕ ОКНО». 12+
14.45 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Битва ставок». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 К 60-летию Виктора Цоя. Последний концерт. 12+
22.45 «Группа «Кино» - 2021». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 0.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.30 «ТАРАС БУЛЬБА». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.00 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
7.50 Великие реки России. «Волга».
8.35 «Забытое ремесло».
8.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ БУДУЛАЯ».
10.15 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО».
11.40 Острова. Сергей Филиппов.
12.20 «Первые в мире».
12.40 «ДНЕВНОЙ ПОЕЗД».
14.15 Острова. Арсений Тарковский.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Тина Кузнецова».
16.15 «Дом на гульваре».
17.10 «Марина Ладынина. Кинозвезда между серпом и молотом».
17.50 Мастера исполнительского искусства. Сергей Догадин и Филипп Копачевский.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «Алхимик из-под Калуги».
20.35 «ИДУ НА ГРОЗУ».
23.20 «ПОСЛЕДНЯЯ «МИЛАЯ БОЛГАРИЯ». 18+

«НТВ»
4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ». 16+
23.55 «Своя правда». 16+

Шимбә

25 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Синең Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Татар сүзе-2021». 6+
14.20 «Яңа татар җыры-2» конкурсының гала-концерты. 6+
18.00 Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ПОДКИДЫШ». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Моңга чорналган язмыш. Александр Ключарев». 6+
7.00, 15.00 «Синең Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Сихерче». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 6+
22.25 Спектакль «Тиле яшьлек». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Научные сенсации». 12+
5.45, 14.45 «Молодая наука». 12+
6.00 «Меганаука». 12+
6.30 «Один день в городе». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Эпидемия». 12+
8.30 «ЛЮТЫЙ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «НОВАЯ ЖИЗНЬ». 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
15.00 «Планета собак». 12+
15.30 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДЕЛО КОЛЛИНИ». 16+
23.10 «КЛАН КЕННЕДИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Парад побежденных». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
13.35 «Порезанное кино». 12+
14.35, 15.20 «СЕМЬ НЕВЕСТ ЕФРЕЙТОРА ЗБРУЕВА». 12+
16.50 «Наталья Варлей. Одна маленькая, но гордая птичка». 12+
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.00 Лига Бокса. Интерконтинентальный Кубок.

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.25 «Доктор Мясников». 12+
12.30 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕРТВА». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ЧУЖАЯ СЕМЬЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Бюро находок».
7.40 «ИДУ НА ГРОЗУ».
10.05 «Обыкновенный концерт».
10.35 «ЧЕРНАЯ КУРИЦА, ИЛИ ПОДЗЕМНЫЕ ЖИТЕЛИ».
11.45 «Эрмитаж».
12.15 Черные дыры. Белые пятна.
12.55 «На холстах лета».
13.35 Музыкальные усадьбы. «Великий сказочник. Николай Римский-Корсаков».
14.05 «Сын отечества».
14.40 «НЕ БОЛИТ ГОЛОВА У ДЯТЛА».
15.55 «Беларусь. Несвижский замок».
16.25 «Хрустальный бал «Хрустальной Турандот».
17.50 «Книга».
18.40 К 95-летию со дня рождения Владимира Мотыля. Острова.
19.20 «ЗВЕЗДА ПЛЕНИТЕЛЬНОГО СЧАСТЬЯ».
22.00 Маркус Миллер на фестивале Джаз во Вьенне.
23.00 «Кинескоп». «Новые имена».
23.40 «ДНЕВНОЙ ПОЕЗД».

«НТВ»
5.15 «ЧП. Расследование». 16+
5.40 «ДЕНЬ ОТЧАЯНИЯ». 16+
7.20 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Основано на реальных событиях». 16+

Якшәмбе

26 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Татар сүзе» бәйгесе җиңүчеләренең гала-конерты. 6+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.45 «Батырлар». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «МОЙ ДРУГ МИСТЕР ПЕРСИВАЛЬ». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Тимер борчак». 6+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Әхтәм Зарипов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.35 «Яңа татар җыры-2022». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Научные сенсации». 12+
5.45, 15.10 «Молодая наука». 12+
6.00 «Не факт». 12+
6.30 «Один день в городе». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Планета собак». 12+
8.30 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДЕЛО КОЛЛИНИ». 16+
15.30 «ЛЮТЫЙ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «НОВАЯ ЖИЗНЬ». 16+
22.30 «В ЛЕСАХ СИБИРИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.40, 6.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
7.45 «Играй, гармонь любимая!» 12+
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 К 85-летию Николая Дроздова. «Шесть мангустов, семь кобр и один полускорпион». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
13.20, 15.15 «ВОСКРЕСЕНСКИЙ». 16+
18.10 «Биологическое оружие лаборатории дьявола». 16+
19.15 «Большая игра». 16+
20.05 «Как развести Джонни Деппа». 16+
21.00 «Время».
22.35 «АНИМАТОР». 12+

«РОССИЯ»
5.30 «ЛЮБОВЬ ДЛЯ БЕДНЫХ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.25 «Доктор Мясников». 12+
12.30 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕРТВА». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Беларусь. Несвижский замок».
7.05 Мультфильмы.
8.00 «НЕ БОЛИТ ГОЛОВА У ДЯТЛА».
9.20 «Обыкновенный концерт».
9.45 «ЗВЕЗДА ПЛЕНИТЕЛЬНОГО СЧАСТЬЯ».
12.25 Письма из провинции.
12.55 Диалоги о животных.
13.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Абрам Ганнибал.
14.05 «Коллекция».
14.35 «ДЖУЗЕППЕ ВЕРДИ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.25 «Пешком...»
17.50 «Абрам Алиханов. Музыка космических ливней».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «РОДНАЯ КРОВЬ».
21.35 «Колон». «Моя аргентинская мечта».
22.40 «БАРБАРЕЛЛА».

«НТВ»
5.00 «ХОЛОДНОЕ БЛЮДО». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Звезды сошлись». 16+
22.55 «Секрет на миллион». 16+

ХАТЫН ИРЕН ҮТЕРГӘН

Рәсми мәгълүматларда мондый шомлы хәбәрләр күп. Әлбәттә, башлыча, сәрхушләр гаиләләрендә килеп чыккан аяныч хәлләр хакында алар. Арча, Кама Тамагы районнарында булган гыйбрәтле очраклар да шундыйлардан.

Арча якларында туып-үскән 1992 елгы Зәмирә Хәсәнова турында хәтта туганнары да юньле сүз әйтә алмый. Әнисе Саимә (кайбер исемнәр үзгәртелә) авыл баласының 9 яшеннән эчә, тәмәке тарта башлавын яшерми, наркотиклар кулланганын сизгәнем булмады, ди. Кәче мәктәбендә 9 сыйныфны тәгәлләгәч, укымаган, рәтләп эшләмәгән ул, аның каруы, бүтән өлкәдә «уңышлар»га ирешкән, ягъни өч бала тапкан, әнисе әйтмешли, бигүк яхшы булмаган тормыш рәвеше алып барганга күрә, аларга ана хокукыннан мәхрүм ителгән. Урлап тотылып мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән, әлеге җәзаны үтәмәгән өчен, 2019 елда япкынлыкта утырып кайткан. Сүз уңаеннан аның бер генә яшькә кечерәк энесенең дә, көчләгән өчен, узган ел бик озакка колониягә озатылуын искәртик.

Яшь хатын ир затларына кытлык кичерми. Өч-дүрт ел элек 1987 елгы Рамил Әхмәтҗанов белән тора башлый, тиздән дүртенче баласын да табып куя, күп тә үтми ошбу сабыена да хокукы чикләнә, чөнки юньле тәрбия күрсәтми. Туганнары уңай бәяләсә дә, Р.Әхмәтҗановны да мактап булмастыр. Тормышта лаеклы урын тапкан 30 яшьлек ир язмышын егылганчы эчә торган холыксыз һәм өч баласын ятим калдырган хатын белән бәйләр иде микән? Апасы һәм әнисе Рамилнең «сожительница»ны ташлап киткән чакларын да искә алалар, ләкин үзенә һәм сабыена бер-бер хәл кылу белән куркытып кире кайтара иде, диләр. Шулай ук аның исерек чакта иренә кул күтәрә, чәнечке, пычакка ябыша торган гадәте булуын һәм, гомумән, акыл ягыннан кимчелекле кеше кебек кылануын белдерәләр.

Р.Әхмәтҗанов туганнарының ошбу фикерләре нигезсез түгел, әлбәттә. Әмма боларга ир кешенең дә эчәргә хирыс икәнен өстәргә кирәк. Димәк, хәвеф-хәтәр чыгу мөмкинлеге дә зур була. Ызгышлы гаилә ике елдан артык Зәмирәнең әнисе, хәзер төрмәдә утыручы энесе белән авылда тора, 2021 елның февралендә Арчада түләүле фатирга урнаша, Рамилнең шәхси хуҗалыкларда эшләп тапкан акчасы хисабына көн күрә. Күченеп килүләренә ярты ел дигәндә, Арчада шаукымлы җинаять эшләнә.

2021 елның 18 августы ирле-хатынлыларның яшәү рәвешен күрсәтүче гадәти көн була үзе. Көндез аларга алдагы көнне бер яшь тулган малайга бүләкләр тотып, Рамилнең апасы Лениза килә. Шул арада гаилә башлыгына, шабашкада эшләгән өчен, 4 мең тәңкә хезмәт хакы кертеп чыгалар, димәк ки, кунак белән сыйлалырлык акчалы булалар. Ләкин сыраны күбрәк хуҗалар чөмерә. Ленизаның әйтүенчә, сәгать 4 нчедә ул чыгып киткәндә үк, сәрхушләр үзара әрләшеп кала. Әлбәттә, бер кызгач, эчүдән туктамый алар. Кичкә таба Зәмирә Ксения атлы дус кызын чакыра, анысы сөйгәне Айдар белән килә. Шактый исергән хуҗабикә бала карарга әнисен дәшә, икенче көнне бик мөһим эшләре булганга, төнлә ял итәргә ниятли, имеш.

Саимә ханым авылыннан, узгынчы машинага утырып тиз килеп җитә һәм оныгын карарга кереп китә. Ул килгәч, кунаклар да озак утырмый, әйтүләренчә, хуҗалар арасында ызгыш кызганнан кыза барганга, китү ягын карыйлар. Искәртеп үтик, алар лаякыл исерек хатын-кыз дулады, ир кеше аны тынычландырырга тырышты, диләр. Кухнядагы ике сәрхуш тавышы Саимәгә дә ишетелә, нәрсәдер дөбердәп төшкәч, якынрак килеп: «Балага йокларга бирмисез», – дип ачуланып эндәшә һәм идәнгә егылып төшкән кияүне күрә.

Рамил берникадәр вакыт аңында була, полиция килер дип, ашыгыч ярдәм дә чакырмаска куша, күкрәгендә кечкенә генә җәрәхәт була, аннан кан да акмый диярлек, ләкин хәле бик тиз начарая бара. Сәрхуш хатын иң элек әнисенең башка ирдән тапкан улы, ягъни абыйсына шалтыратып хәлне аңлатып бирә. Радмир табибләр чакырырга куша. Шул рәвешле, ир кеше үзенә үзе чәнчегән дигән хәбәр сырхауханәгә, аннан полициягә барып ирешә. Ярдәм килеп җиткәнче, Зәмирә авыр хәл эчендәге ирен билдән түбән чишендереп, аны һәм идәнне «биологик калдыклар»дан чистартып-юып куя.

Хуҗабикә өйдәге ыгы-зыгы вакытында берничә кешегә, шул исәптән, Рамилнең әнисенә дә шалтырата. Елена көч-хәл белән сөйләшүче исерекнең сүзләрен аңлап бетерми һәм бераздан килене белән үзе элемтәгә керә, анысы күкрәгендә кечкенә генә ярасы бар, тегәрләр дә, кайтарырлар дип кычкыра. Ә менә сырхауханәгә шалтыраткач, аңа улының хәле өметсез икәнен белдерәләр. Чыннан да, төнге сәгать икенчедә 34 яшьлек ир кеше соңгы сулышын ала.

З.Хәсәнова, исерек булса да, алдан ук гаепне үзеннән читкә этәрү җаен карый, ягъни Рамил үзенә үзе кадады дип сөйли. Ошбу фикер тикшерү органнарында гына түгел, мәрхүмнең туганнарында да шик уята. Лениза, мәсәлән, сәрхуш килен төнлә шалтыраткач та, Рамилне син үтердең, теләгеңә ирештең дип тозлап-борычлап җавап кайтара, рәсми күрсәтмәләрендә дә кабырганы зарарлап үпкә, йөрәккә кадәр барып җиткән җәрәхәтнең З.Хәсәнова кадау нәтиҗәсе икәнен бик кискен рәвештә белдерә.

Тикшерү эшләре мондый фаразларга гына нигезләнми, билгеле. Зәмирә үзе дә, иң алдан Радмирга шалтыраткач та, ирен чәнчүен әйткән була. Дөрес, абый кеше конституцион хокуклары нигезендә әлеге сөйләшүнең эчтәлеген әйтүдән баш тарта, күрәсең, моның сеңлесе файдасына түгел икәнен белә. Әмма әлеге хәбәрләшү «громкая связь» аша төп шаһит Саимә ханым алдында бара һәм әни кеше дөресен сөйләп, чынлыкта, кызын фаш иткән күрсәтмә бирә. Кыскасы, З.Хәсәнова күрсәтмәләрен кире кагучы дәлилләр шактый туплана.

Хәер, хокук саклау органнарында җинаятьнең шушы хатын эше икәне алдан ук шик уятмый. Шуңа күрә, икенче көнне үк тоткарлана, суд карары белән сак астына ябыла һәм өченче көнне тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Д.Д.Хаҗиев аңа аңлы рәвештә кеше үтерүдә беренчел гаепләү белдерә.

З.Хәсәнова үтерү максаты һәм пычак белән кадау нияте, теләге булуын кире кага. Шул ук вакытта Рамил үзенә үзе чәнчеде дигән фикерне дә телгә алмый башлый, ә бәлки очраклы рәвештә саксызлык белән кадау-кадалу хакында сөйли. Аның әйтүенчә, әрләшә торгач иренә тимер урындык белән кундырып алгач, кулына пычак тотып кухнядан бәдрәфкә керә һәм сул беләген ике җирдән җәрәхәтли. Кан тамырымны кисеп үз-үземә кул салу уе булмады, Рамилне куркытырга гына теләдем, ди ул. Алга таба булган хәлләрне төрлечәрәк бәян итә, берсендә, тарткалашканда, «көрәш» барышында ялгыш кададым, дисә, икенчесендә, тәгаен әйтә алмыйм, мөгаен, пычак белән эләктергәнмендер дип икеләнү белдерә. Хак булса, шуннан берни булмагандай кухняда сыра эчеп утыралар, ярты сәгать чамасы узгач кына, Рамил агарынып урындыгыннан егылып төшә.

Ошбу хәлләрне сөйләп кенә түгел, җинаять урынында күрсәтеп тә йөри ул. Ләкин эксперт әлеге күрсәтмәләрне дә шик астына ала. Ахыр чиктә, З.Хәсәнова кухняда пычак тотып иренә һөҗүм иткән, ягъни аны аңлы рәвештә үтергән дигән нәтиҗәгә киленә. Гаепләү ягы фикере судта да раслана, хөкемдар явыз хатынны 8 елга ирегеннән мәхрүм итәргә дигән хөкем чыгара. Аның дүртенче баласы опека буенча туганнар тәрбиясенә тапшырыла.

* * *

Кама Тамагы районының Куйбышев затоны бистәсендә гомер иткән В.Сафиуллина 69 яшендә алты елга ирегеннән мәхрүм ителде. Былтыр икенче иренең вафатына 14 ел тулган көнне 13 ел бергә яшәгән өченче тормыш иптәше Ю.Бакушинны үтерә ул.

1953 елгы Юрий Мәскәүдә туган кеше. 2005 елда беркайчан да гаилә кормаган карт буйдак Идел буендагы Антоновка авылындагы туганнан туган энесе Всеволод янына кайта, анда ике ел чамасы торганнан соң, Куйбышев Затонына күченә, бистәдә Валентина Сафиуллина белән танышып, никахсыз гаилә кора. Ошбу ханым яшь чагында медицина көллияте тәмамлап фельдшер булып эшләгән. Үзе Ульяновск өлкәсеннән ул, бу якларга телгә алынган икенче иренә кияүгә чыккач, кечкенә кызы белән килгән.

Пенсиядәге ханым – 2 нче төркем инвалид, өстәвенә, психиатрда исәптә дә тора, ләкин күптән түгел үткәрелгән экспертиза аның рухи кимчелекләре хәмергә хирыслык нәтиҗәсе дип, үз кыланмышларын аңламаслык хәлдә түгеллеген белдерә. Күрше-күлән дә аның исерек чакта гына тавышланып, сүгенеп йөрүен, ә ир кешенең тыныч, зыянсыз икәнен әйтәләр. Картлар пенсияләре хисабына очын-очка ялгап бара, әлбәттә, бергәләп эчәргә дә җай чыгаралар. Юрий аягын сындыру сәбәпле, бер ел чамасы култык таякларына таянып йөри.

Узган елның 19 декабрендә Валентина шул бистәдә яшәүче кызы Лидия йортына кереп чыга, кайтышлый 14 ел элек үлгән Валерийны искә алу ниятеннән кибеткә кагылып, 4 шешә «фанфурик» ала. Кич белән исә кышкы киемсез, оекчан карчык шактый ерак торучы кызы, кияве янына тагын килеп чыга һәм Ю.Бакушинны үтерүен әйтә. Өйдәгеләр ошбу шомлы хәбәргә ышанмыйлар, тәгәлрәге, психиатрда исәптә торучы һәм эчә торган әниләре ялгышып-буталып сөйли дип өметләнәләр. Ләкин фатир ишеген ачкач та, диванда яткан Юрийны күрәләр, әни карчык мәет янәшәсендәге урындыкта яткан пычакка күрсәтеп шул ук сүзләрне кабатлый.

Суд-медицина эксперты гәүдәнең башлыча корсак, күкрәк тирәсендә 14 тирән җәрәхәт булуын, муендагы тагын ике яраның кеше җан биргәч ясалуын белдерә. Тикшерү комитетының Югары Ослан районара бүлегеннән Андрей Россиевка әлеге эшне тикшерү әллә ни мәшәкатьле булмый. В.Сафиуллина барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп гаебен танып тора. 1953 елгы әби шунда ук тоткарланып полиция бүлекчәсенә алып кителә, аны озата барган Рөстәм Әкберов, күңеле күтәренке иде, ара-тирә җырлап та җибәргәләде, ди. Икенче көнне суд Валентинаны сак астына ябарга карар кыла.

Үзенә бернинди куркыныч янамаса да, чынлыкта, бернинди сәбәпсез озак еллар бер түбә астында яшәгән абзыйны тетеп ташлаган хатын-кызның акылга камиллеге икеләндерә, билгеле. Ләкин бик тә эзлекле күрсәтмәләр бирә, вакыйганы энәсеннән җебенә чаклы сурәтләп бирә ул. Кыскасы, теге шешәләрдәге спиртлы сыеклыкны икәүләп эчкәч тә черем итәргә ята алар. Валентинаның әйтүенчә, кичкә таба гомер бакый үзенә кул күтәрмәгән Юрийның култык таягы белән сугуына уянып китә дә, аксак ирне диванга төртеп ега, шул тирәдәге урындыкта яткан пычакны кулына алып кадарга керешә ул. Бакушин дәшми-тынмый үлеп китте ди хатын-кыз, ошбу явызлыгы сәбәбен дә атый алмый, аптыраганнан, кыйнар дип курыктым, ачуым килде дип сөйләнә.

Кама Тамагы район суды хөкеме үз көченә кермәгән әле. Ирен үтергән хатынның иреккә чыгу мөмкинлеге дә юк түгел. Моның өчен икенче суд өлкән яшьтәге инвалидның саулыгы иректән мәхрүм итү оешмаларында тотарлык түгел дип табарга тиеш.

Наил ВАХИТОВ.

«Апуш»ның тәүге җимеше

«Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Апуш» балалар театр студиясенең беренче спектакле күрсәтелде. Равил Бохараевның «Апушның тылсымлы төшләре» әсәре буенча куелган тамаша өчен музыканы – Зөлфәт Вәлиуллин, сәхнә бизәлешләре һәм костюмнарны театр рәссамы Сергей Скомороховның шәкерте Анна Новикова иҗат иткән.

«Апуш» студиясе Казан шәһәре хакимияте тарафыннан татар телен үстерү максатында быелның февралендә гамәлгә куелган иде. Кастингта Казан шәһәре, Арча, Лаеш, Балтач районнарыннан йөздән артык бала, яшүсмер катнашты. Нәтиҗәдә, 9 яшьтән 15 яшькәчә 30 бала сайлап алынды. Алар атнасына өчәр тапкыр бушлай театр дәресләре алды. Г.Камал театрының балетмейстеры Сәлимә Әминова яшь артистларны – биергә, Г.Кариев театрының вокал буенча мөгаллиме Лилия Зәйнуллина – җырларга, К.Тинчурин театры артисты Резидә Сәлахова – матур сөйләргә, иркен хәрәкәтләнергә һәм студиянең җитәкчесе, «Перспектива» гранты иясе, талантлы артистка Алия Фәйзрахманова актерлык осталыгына өйрәтте.

Беренче тамашада утыз бала да катнашты. Нәни артистларның шатлыгын уртаклашырга спектакльгә Татарстан Президенты каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Казан шәһәре хакиме Илсур Метшин, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Президентыбыз каршындагы мәдәниятне үстерү фонды җитәкчесе Нурия Хашимова килгән иде.

Сентябрьдә «Апуш» студиясенең «Апушның тылсымлы төшләре» спектаклен Г.Камал театры сәхнәсендә күрсәтергә ниятлиләр. Республикабыз районнарыннан гастрольдә йөреп кайту теләкләре дә бар. «Апуш»ны балалар театр фестивальләрендә дә күрсәтәселәре килә. Ә иң куандырганы – моның ише студияләрнең Казанның һәр район мәдәният сараенда барлыкка килүе. Беренче итеп Авиатөзелеш районында урнашкан Ленин исемендәге мәдәният сараенда балалар театр труппасы оештыру күздә тотыла. Августта кастинг игълан ителәчәк. Татарча сөйләшергә һәм иҗади мөмкинлекләрен үстерергә хыялланган балалар өчен бер дигән форсат бу.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.
Рәмис НӘҖМИЕВ, Денис ГОРДИЙКО фотолары.



Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 17.06.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2730 данә

Заказ 2757

16+